ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

№11 (370)
НОЯБРЬ 2022

УКЫТУЧЫНЫҢ АБРУЕ ЮГАРЫРАК БУЛЫРГА ТИЕШ!

4612750670011

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Олеся Бондаревская,
Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Троицкая
Авторлар: Илдус Заһидуллин, Жанна Сарымсакова,
Ольга Туманская
Фотографлар: Александр Ефремов, Илнар Өметбаев,
Ната Смирнова, Алсу Шакирова
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Игорь Глушков, Анастасия Хатыйпова
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: ТР мәгариф һәм фән министры Илдус Һадиуллин.
Алсу Шакирова фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек
буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы
ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри.
Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә
мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция
җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: О–3331
Басарга кул куелды: 11.11.2022
Басмадан чыкты: 17.11.2022

КЫҢГЫРАУДАН КЫҢГЫРАУГА... ИМТИХАННАН ИМТИХАНГА...

«Татарстан» журналы бөтен каникулны да бу юлы уздыргандай күңелле үткәрми. Мәктәп балалары, укытучылар, ата-аналар компаниясендә, ТР мәгариф һәм фән министрының үзе җитәкчелегендә без төп темасы мөнәсәбәтләр булган бу санныбызны эшләдек. Уку процессында катнашучы һәркем – укытучылар, укучылар, ата-аналар һәм хәтта министрлар арасындагы мөнәсәбәтләр хакында сөйләштек. Тормыш әйләнә буенча бара, һәм бу мәңгелек хәрәкәттә – кыңгыраудан кыңгырауга, имтиханнан имтиханга, каникулдан каникулга – аңлашып һәм тату яшисе килә, чөнки кыңгыраулы мәктәп еллары безгә башка беркайчан да кабатланмас рәхәт мизгелләр кичерер өчен бирелә. Һәм безнең мәктәп бергәнең кайбер категорияләре көзге каникулның артык кыска булуына кайгырса да, аларның яшь йөрәкләрен тынычландырырлык хәбәребез дә бар – алда безне дөньяда иң кыска икенче чирек көтә, димәк, – алга, яңа уңышларга!

Сезнең мәңге яшь редакциягез

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900
Коммерция директоры урынбасары:
Гөлназ Яруллина,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9655-826-037
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева, milyaushanb@tatmedia.com

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә
тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе: **963 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» журналына 101 яшь

ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре

бары тик ТАТАРСТАНДА

КИЛӘЧӘКТӘН ИҢГӘН «ТУЗГАНАК»

Күптән түгел Нурлатта тынычлык һәм шәфкатьлелек символы саналган «Тузганак» һәйкәле пәйда булды. Шәһәргә аны Халыкара игелеклелек академиясен оештыручы, танылган скульптор Григорий Потоцкий бүләк итте. Шунысы кызык: автор менә инде берничә ел рәттән үзенең «Тузганакларын» төрле илләрдә ача һәм бар очракта да – үз хисабына. Аның идеясе бик гади: «Без Җирдә шәфкатьлелекнең нейрон челтәрен төзергә һәм нәфис зәңгәр планетабызны уңай фикерләр, сүзләр, эшләр белән урап алырга карар кылдык», – ди автор. Бүген «Тузганак» дөньяның 32 илендә бар инде: Россия, АКШ, Филиппиннар, Мексика, Коста-Рика, Франция, Испания, Германия, Австриядә... Кырымда референдум үткәрелер алдыннан Севастопольгә дә шундый скульптура бүләк иткәннәр. «Игелек символы – тузганак» дип язылган нәфис һәйкәл нибары алты көн торып калган һәм, сынчы әйтүенчә, Украина хакимияте тарафыннан юкка чыгарылган.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

4. «Без бергә! Без булдырабыз!»
Татарстан Президенты Юлламасыннан өзекләр

18. Белем һәм татулыкка юл
«Адымнар» полилингваль мәктәпләре кайда эшли

12. Министр – һөнәри үсеш моделе турында,
яисә Укытучының абруен ничек күтәрергә

20. Җиде йозак артында
Мәктәпләребез иминлеге

28. Илсур Җиһаншинның педагогик поэмасы
«Ел укытучысы-2022» бәйгесе лауреаты

30. Яратмыйча сайланган һөнәр
Мәхәббәткә әйләнгән нәфрәт

32. Укытучы һәм блогер: кем кемне
Гаилә белән мәктәп диалогына нәрсә комачаулый

36. Яратканнарыбыз турында
Укытучы һәм укучыга бер-берсен ничек яхшырак аңларга

38. «500+» проекты
Начар мәктәпләрне ничек яхшы итәргә

игелекле эшләр

52. Редакция кухнясы
Урал пилмәннәре ничек ясала

58. Надежда Сәфәрова сабаклары
Укытучы өчен иң зур бүләк нәрсә

62. Казаннан Красноярскига кадәр
45 ел эчендә ничә чакрым юл салырга була

**64. Династиядән бер
эче**
Авылларга кем асфальт юллар сузган

66. Югала барган шөгыльләр
Киледә карабодай төю

мәңгелек кыйммәтләр

70. Тарих сәхифәләре
Газиз Гобәйдуллин – тарих буенча беренче татар профессоры

74. Кабан арты мәчете. Миф һәм легендалар
Аның язмышында Сталин нинди роль уйнаган

76. Татар авыллары
Яңа Кенәр – бай тарихлы авыл

88. Штирлиц хезмәттәше
Кайсы яшерен агент «Татарстан»ның баш мөхәррире язган китапның төп героена әйләнгән

Фото: tatar-inform.ru

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: protatarstan.ru

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

20.10

Айрат Фәррахов, Россия Федерациясе Дәүләт Думасында Татарстаннан депутат:

« – Балигълык яшенә җитмәгән өч һәм аннан да күбрәк бала атасы булган бер граждан да мобилизацияләнмәячәк. Дәүләт Думасы делегациясе белән әлеге мәсьәлә буенча фикер алышканнан соң, Оборона министрлыгы җитәкчелеге шундый карар кабул итте. Бу сайлаучылар үтенечe буенча эшләнгән депутат инициативасы иде. Элек мобилизацияләнгән күп балалы әтиләр өйләренә кайтарылачак.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

13.10

Константин ХАБЕНСКИЙ, А.П.Чехов исем. Мәскәү сәнгать театры директоры – сәнгать җитәкчесе, – Казанда гастрольләр вакытында:

« – Вакыт күрсәтте ки, Татарстанда үз эшләре белән шөгыльләнүче кешеләр – үз халкы өчен, беренче чиратта үз балалары өчен эшли торган кешеләр. Алар монда тормышның яхшы булуын тели. Моннан китәсе килми, без мәнә шушында яшәргә һәм иҗат итәргә телибез.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

6.10

Минтимер Шәймиев, ТР Дәүләт Киңәшчесе, – Казанда китап ядкәрләренең сакланышын тәэмин итү буенча бизнес, хакимият һәм җәмгыятьнең хезмәттәшлегенә багышланган фәнни-гамәли конференциядә:

« – Беләсезме, бездә хәйрияче ничәү? Миндә мәнә мондый сан бар – Татарстаннан 62 571 кеше. Андый эшләр башкарганда үзең дә үзгәрәсең, күңел тынычлана. Һәркемнән соң эз калырга тиеш. Алайса тормышның ни мәгънәсе бар? Аның кайтавазы булачак. Шунда ук түгел икән, берничә елдан соң. Без һәрнәрсәне ихлас күңелдән эшләргә тиеш. Шулчакта җаныбыз чистарак булыр, үз-үзебез белән горурлана алырбыз. Моны күреп-ишетеп – балаларыбыз, оныкларыбыз да... Яңарыш процессы әнә шул инде ул.

Фото: tatar-inform, «Татарстан» журналы архивы

игелекле эшләр

акыллы гамәлләр

мәңгелек кыйммәтләр /

Бу санда тәкъдим итәбез:

Татарстан яңа шартларга **ничек** җайлаша

Мобилизицияләнгән-нәргә һәм эшкуарларга **ничек** булышырга

Көзге каникул **ни өчен** бик кыска

Казанда мәктәпләрне **ничек** саклыйлар

Әти-әниләрне **ничек** яңадан тәрбияләргә

Нәфрәт **ничек** мәхәббәткә әйләнә

Начар мәктәпләрне **ничек** яхшыртырга

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ: «БЕЗ БЕРГӘ! БЕЗ БУЛДЫРАБЫЗ!»

2023 елга Татарстан Президентының ТР Дәүләт Советына Юлламасыннан

ЯҢА ТАЛӘПЛӘР ҺӘМ ӨЛЕШЧӘ МОБИЛИЗАЦИЯ ТУРЫНДА

Безнең сугышчыларга һәм аларның гаиләләренә адреслы ярдәм күрсәтү, алар турында кайгырту мөһим. Бик күпләргә җиңел түгел хәзер. Ярдәм итәргә теләгән предприятиеләрнең, иҗтимагый оешмаларның, татарстанлыларның саны арта баруын күрәбез. Мондый башлангычларны төрлечә хупларга кирәк. «Ярдәм янәшә! Ярдәм якында гына!» республика хәрәкәте кысаларында һәрьяклап ярдәм күрсәтелә. Башлыкларның бурычы – урыннарда һәртөрле ярдәм күрсәтү.

Россия Федерациясенең яңа субъектларында яшәүчеләргә гуманитар ярдәм күрсәтү эшен дәвам итәргә кирәк. Татарстан торгызу эшләрендә, мохтаҗларга ярдәм күрсәтүдә актив катнаша. Гомуми эшкә «КАМАЗ», «Татнефть», «Татхимфармпрепаратлы», «Нэфис», «Газпром трансгаз Казан», Яр Чаллы картон-кәгазь комбинаты, Казан авиация заводы, Казан вертолет заводы һәм башка предприятиеләр зур өлеш кертте.

Тәтеш районы башлыгы Рәмис Хатыйп улы Сафиулловны, шулай ук Мөслим районы эшкуары Илгиз Зәкиҗан улы Исламовны аерым билгеләп үтәсем килә. Республикада андый кешеләр күп. Ярдәмегез өчен һәрберегезгә рәхмәтемне җиткерәсем килә.

МИРАС ҺӘМ БУЫННАР ХӘТЕРЕ ТУРЫНДА

Дөньяда агымдагы катлаулы вазгыять барысын да үз урынына куйды, һәм иң гади тоелган әйберләр бүген беренче планга чыкты. Бу гаилә, балалар, Ватанга мәхәббәт, ватанпәрвәрлек, бабаларыбыз мирасы. Илебез тарихы батырлык һәм каһарманлык мисаллары белән тулы. Без җиңүчеләрнең ныклы, фидакарь буыны белән горурланабыз.

Республика Хөкүмәтенә, муниципаль берәмлекләр башлыкларына, махсус хәрби операциядә катнашучыларны да кертеп, Ватанны саклаучыларның хәтерен мәңгеләштерү эшен дәвам итәргә кирәк.

Җиңүнең данлы традицияләрен саклау үсеп килүче буынга патриотик тәрбия бирү ягыннан зур әһәмияткә ия. Моңа барлык мәгариф һәм мәдәният учреждениеләре эшчәнлеге юнәлтелергә тиеш. Әлеге эштә «Авангард» хәрби-патриотик тәрбия үзәкләре, хәрби-патриотик клублар, балалар һәм яшьләр берләшмәләренә аерым роль бирелә. Патриотик тәрбия бирү буенча республика координация советына бу эшчәнлекне методик яктан тәэмин итүне йөклим. Программа чараларын уздырганда, «Җиңү волонтерлары» корпусын киңәйтүгә һәм, гомумән, ирекләләр хәрәкәтен үстерүгә аеруча игътибар бирү зарур.

> Рухи хәзинәләребезне саклау һәм үстерүнең, милли традицияләрне торгызуның зур әһәмиятен исәпкә алып, шулай ук Россия халыклары мәдәни мирасы елының дәвамы буларак, 2023 ЕЛНЫ РЕСПУБЛИКАДА МИЛЛИ МӘДӘНИЯТЛӘР ҺӘМ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР ЕЛЫ ДИП ИГЪЛАН ИТӘМ.

ЯҢА ШАРТЛАРДА ХАЛЫКАРА ХЕЗМӘТТӘШЛЕК ТУРЫНДА

Халыкара һәм тышкы икътисадый эшчәнлек зур үзгәреш кичерә, аны хезмәттәшлек алып баруның яңа шартларына һәм рәвешләренә яраклаштыру зарур.

Республика «Россия – ислам дөньясы» Стратегик караш төркеме форматында актив эш алып бара. Аның кысаларында быел җәй Татарстан башкаласында KazanSummit 13 нче Халыкара икътисадый саммиты узды, ул дөньяның 64 иленнән һәм Россиянең 59 төбәгеннән 6,5 мең катнашучыны җыйды. Россия Федерациясе Президенты Владимир Владимирович Путин чараны үткәрүне югары бәяләде һәм форумга федераль статус бирү турындагы тәкъдимебезне хуплады. Петербург һәм Көнчыгыш икътисадый форумнары белән беррәттән, Казан тигез хокуклы һәм үзара файдалы халыкара хезмәттәшлек кысаларында Россиянең икътисадый мәнфәгатьләрен тәэмин итү буенча тагын бер зур мәйданга әверелә.

Финанс ресурсларыннан файдалануга чикләүләр кертелгән бүгенге көн шартларында ислам

Фото: president.tatarstan.ru

илләре финанслары институтын үстерү безнең өчен мөһим юнәлеш булып тора. **Хәзерге вакытта федераль дәрәҗәдә законнар базасын формалаштыру эшләре тәмамланып килә. Татарстан пилот төбәкләр арасында.**

НӘТИҖӘЛЕ ИКЪТИСАД ҺӘМ ИМПОРТНЫ АЛЫШТЫРУ ТУРЫНДА

Нефть, газ һәм химия комплексы республика икътисадының нигезен тәшкил итә. Без «Татнефть» компаниясенә нефть чыгаруда һәм эшкәртүдә чит ил товарларын алыштыру эше белән системалы шөгыльләнгәне, чит илләр тудырган кыенлыкларны җиңүдәге уңышлары өчен рәхмәтебезне белдерәбез. Бу – эшне илебез технологияләрен һәм җиһазларын файдаланып оештыруның бер мисалы.

«ТАНЕКО» комплексында нефть чималын кабул итү һәм эшкәртү буенча җиһазларның башлангыч куәтен елына 16,3 млн тоннага кадәр арттыру (мазут җитештерүдән тыш), быел дүрт яңа җайланманы файдалануга кертү юнәлешендә зур эш башкарыла. «ТАИФ-НК» шулай ук нәтиҗәле эшли. Болар һәммәсе чимал эшкәртүне 23 млн тоннага җиткерергә мөмкинлек тудырачак.

ПЕРСПЕКТИВАЛЫ ПРОЕКТЛАР ТУРЫНДА

«СИБУР» компаниясе «Түбән Кама Нефтехим» һәм «Казан Органик синтез» предприятиеләрендә этилен һәм поликарбонат заводларын яңартып кору, электр энергиясен җитештерү җайланмалары төзү кебек инвестицияле проектларны гамәлгә ашыруны дәвам итә. 2024 елда ЭП-600 олефиннарын җитештерү буенча яңа комплексны сафка кертү планлаштырыла.

«СИБУР» белән «Алабуга» МИЗ арасында Түбән Камада индустрия паркын ачу турында килешү төзелде. «Түбән Кама Нефтехим» чыгара торган продукциянең төрлелеге чиктәш тармакларда җитештерүне үстерү өчен киң мөмкинлекләр ача.

«Газпром» компаниясе – безнең стратегик партнерыбыз. Татарстанда газ куллану күләме узган елда 18,2 млрд куб. метрны тәшкил итте. Һәм бу күрсәткеч ел саен арта бара.

Газ-мотор ягулыгы базарын үстерү буенча уртак проектны гамәлгә ашыру уңышлы дәвам итә. Татарстанда 37 газ ягулыгы салу станциясе, 3 криоАЗС урнашкан, тагын 9 ягулык салу станциясен төзү эшләре алып барыла. Моннан тыш, быел газ сыекландыру буенча ике завод эшли башлады.

Көнкүреш химиясен җитештерүче зур чит ил компанияләренең илебездән китүе белән бәйле рәвештә «Нэфис» компаниясенә продукциясен сату базарын киңәйтү өчен яңа мөмкинлекләр ачыла.

«Алабуга» МИЗндагы «Данафлекс» компаниясе кабат эшкәртү өчен яраклы яңа төр пленка материаллары җитештерү буенча 2,5 млрд сумлык проектны гамәлгә ашыра.

KAMA TIRES компаниясе шиннар җитештерүне модернизацияләүне һәм продукцияне диверсификацияләүне дәвам итә. Агымдагы елда предприятие проектларына инвестицияләр 7 млрд сум тәшкил итәчәк.

КАМАЗ модель рәтен үстерүне дәвам итә – киләсе елның I кварталында автогигант К5 яңа буын йөк машиналарының тулы модель производствосын эшләтеп җибәрәчәк, импортны алыштыруны төгәлләргә.

Алабугада «Соллерс» компаниясе агымдагы ел ахырына кадәр яңа коммерцияле автомобильләр җитештерүне башлап җибәрәчәк.

«РИАТ» компаниясе яңа манипуляция краннарын чыгарырга әзерләнә.

Казан авиация заводы алдында гражданнар өчен Ту-214 очкычларын серияле рәвештә җитештерүне елына 20 очкычка җиткерү бурычы тора. Республика заказчысы белән 4 очкычка контракт төзелде инде.

Казан вертолет заводы киләсе елда «Ансат» вертолетларын җитештерүдә чит ил товарларын алмаштыру программасын тәмамлауны планлаштыра. Барлык модельләр буенча җитештерү күләмен елына 100 вертолеттан да кимрәк булмаслык итеп саклап калу мөһим.

Яшел Үзән заводы. А.М. Горький исемендәге заводы быел беренче «Метеор»ны куллануга тапшырды. Ул пассажирлар флотын торгызуны тәэмин итәргә тиеш. Республиканың судагы маршрутларында йөртү өчен тагын өч яңа көймә – ике «Метеор» һәм бер А-217 көймәләрен төзүгә заказ бирелде.

Ростех компаниясенең ярдәме белән «ПОЗиС» оешмасы дәүләт корпорациясенең барлык предприятиеләре өчен стандарт булмаган җиһаз җитештерү буенча бердәм үзәк итеп билгеләнде.

Гомумән алганда, Татарстанда Ростехның 15 предприятиесе уңышлы эшчәнлек алып бара, анда эшләүчеләр саны 50 мең кешедән артып китә. Чистайда «Бетар» компаниясе робот-манипуляторлар җитештерү буенча яңа мәйданчык ача, «Меттэм» компаниясе автомобильләр төзү тармагы өчен электр компонентларын җитештерүне башлап җибәрә, Бөгелмәдә «НТЭС» компаниясе мини-төягечләр чыгаруны җайга салды.

ОБОРОНА ЗАКАЗЫ ҺӘМ ТЕХНОЛОГИК СУВЕРЕНИТЕТ ТУРЫНДА

Илебез Президенты Владимир Владимирович Путин гаскәрләрне заманча яңа корал һәм техника белән тәэмин итүне кыска вакыт эчендә арттыру бурычын куйды.

Бүгенге көндә республиканың оборона-җитештерү комплексы предприятиеләре аны үтәүдә катнашалар һәм дәүләтебез иминлеген тәэмин итүгә зур өлеш кертәләр.

Шул ук вакытта файдаланылырга тиешле мөмкинлекләр тагын да бар әле. Булган җитештерү куәтләрен тулысынча эшләтергә, продукция эшләп чыгару күләмен арттырырга кирәк. Иң мө-

һиме – дәүләтнең оборона өлкәсендәге заказын вакытында үтәүгә ирешү.

Фәнни оешмаларның һәм югары уку йортларының икътисадның реаль секторы белән хезмәттәшлеген арттыру гаять мөһим. Бу юнәлештә эшчәнлек алып барганда КФУ, «Иннополис» университеты һәм КМТТУ (КХТИ) базасында булдырылган алдынгы инженерлык мәктәпләренә, КМТТУ-КАИ гамәлгә ашыра торган «Крылья Ростеха» махсус проектына, шулай ук республика югары уку йортлары базасында технологик эшкуарлык стартап-студияләренә таянырга кирәк.

Технологик бәйсезлеккә ирешү һәм икътисадның төп секторларының критик мәгълүмат инфраструктурасы куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен, республика предприятиеләренә илдә булдырылган программа тәэминатына һәм үзебезнең җиһазларга мөмкин булганча күбрәк күчәргә кирәк.

Исәпләү техникасын җитештерү буенча яңа производстволар булдыру актуаль. ICL компаниясе, «Иннополис» махсус икътисадый зонасы белән бергә, елына 1 млн эшләнмә җитештерә торган төп платалар заводын төзүгә керешә. Бу – илебезнең микроэлекторника җитештерү өлкәсе өчен зур вакыйга.

ИНВЕСТИЦИЯЛЕ АКТИВЛЫК ҺӘМ ЭШЛЕКЛЕ КЛИМАТ ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН ҖИТЕШТЕРҮЧЕЛӘРЕНӘ, ШУЛ ИСӘПТӘН МУНИЦИПАЛЬ СӘНӘГАТЬ ПАРКЛАРЫ МӨМКИНЛЕКЛӘРЕННӘН ДӘ ФАЙДАЛАНЫП, ЯРДӘМ КҮРСӘТҮ – БЕЗНЕҢ БУРЫЧЫБЫЗ. Бу – районнарда яңа эш урыннары булдыру, урта һәм кече эшкуарлыкны үстерү өчен төп мөмкинлек.

Республиканың Икътисад министрлыгына, муниципаль районнар башлыклары, нәтиҗәле эшләүче сәнәгать парклары идарәче компанияләре белән бергәләп, яхшы тәҗрибәне мөмкин булганча күбрәк таратырга, яңа инвесторлар җәлеп итүдә яңа шартлар булдыру өчен, сәнәгать паркларын үстерүгә киртә булган факторларны бетерү буенча эшне дәвам итәргә кирәк.

Яшь эшкуарларга грант ярдәме күрсәтү, шулай ук үзмәшгульләр институтын камилләштерү эшен дәвам итәргә кирәк.

Электрон сәүдәне үстерү программасыннан файдаланулары нәтиҗәсендә Татарстан эшкуарларына (шул исәптән республикадан читтә дә) үз продукцияләрен сату өчен мөмкинлекләр ачылды. Программаны гамәлгә ашыруны алдагы елларда да дәвам итәргә кирәк.

Товар сату базарын киңәйтү өчен тагын бер мөмкинлек – ул контейнерлы товар ташуны арттыру. Республиканың Транспорт министрлыгына һәм Сәнәгать министрлыгына базарның төп катнашучыларын җәлеп итү һәм тиешле инфраструктура булдыру өчен комплекслы чаралар күрергә кирәк.

АГРОСӘНӘГАТЬ ӨЛКӘСЕ ТУРЫНДА

Терлекчелек продукциясе җитештерү ягыннан алдынгы урыныбызны ышанычлы төстә саклау мөһим: сөт җитештерү буенча – 2 млн тонна, ит җитештерү буенча 550 мең тонна күрсәткеченә ирешергә бурычлыбыз.

Тулаем алганда, терлекчелектә заманча технологияләр кулланып фермаларны яңартып кору, терлек азыгы үзәкләрен төзү эшен дәвам итәргә кирәк. Терлек азыгы үзәкләре һәр районда булырга тиеш.

Авыл хуҗалыгы тармагында алынган чималны эшкәртү системасын җайга салу таләп ителә. Бу өлкәдә сөт эшкәртүгә бәйле уңышлы мисал бар: әле 5 ел элек кенә республика предприятиеләре төбәктә савып алына торган сөтнең нибары 50 процентын эшкәртсәләр, бүген бу күрсәткеч 91 процентны тәшкил итә.

Хуҗалык алып баруның кече формаларына ярдәм итү өчен без ел саен 2 млрд сум бүлеп бирәбез. Моңа 20 гә якын төрле чаралар керә. **Без киләчәктә дә авыл хуҗалыгы предприятиеләребезгә, фермерларыбызга, шәхси хуҗалыкларга ярдәм күрсәтүне дәвам итәчәкбез.**

ИТ-ӨЛКӘНЕ ҮСТЕРҮ ТУРЫНДА

Ел ахырына кадәр республика гражданнарына барлык 325 дәүләт һәм муниципаль хезмәттән электрон рәвештә файдалану мөмкинлеге тудырылачак.

Төп тармакларны цифрлаштыру эше дәвам иттереләчәк: мәгариф өлкәсендә «Мин – укучы» – укучының цифрлы ярдәмчесе сервисы эшли, сәламәтлек саклау өлкәсендә Республика клиник хастаханәсе базасында Россиядә беренче буларак халыкара стандартларга туры китереп медицина ярдәме күрсәтү тәртибе цифрлы нигезгә корылачак, торак-коммуналь хезмәтләрне цифрлаштыру өчен бер платформада гражданнарны, урта һәм кече бизнесны һәм идарәче компанияләрне берләштерәчәк яңа «Локоло» сервисы гамәлгә куелды.

«Имин шәһәр» видеокүзәтүенең хокук саклау сегменты үз нәтиҗәлелеген раслады. Ул җинаятьчелекнең кимүенә китерде һәм хокук тәртибен тәэмин итәргә мөмкинлек бирде.

Югары тизлекле интернетка тоташтыруны киңәйтү буенча актив эш алып баруны дәвам итәбез. Федераль программа кысаларында 3,5 меңнән артык социаль объект югары тизлекле интернет белән тәэмин ителде, элемтәнең югары тизлекле каналларына беренче тапкыр 300 дән артык авыл тоташтырылды.

Республиканың барлык социаль объектларын (бу исә якынча 4,5 мең объект) интернетка тоташтыру – якындагы елларда хәл ителергә тиешле бурычыбыз.

Моннан тыш, «Таттелеком» компаниясе быел авылдагы 100 меңнән артык хуҗалыкка югары тизлекле интернет кертергә ниятли.

Республика башкаласында Бәшир Рәмиев исемендәге яңа технопарк ачу бу елның тагын

бер мөһим проекты булачак. Монда югары технологияле компанияләр үсеше өчен шартлар тудырылган 50 мең квадрат метрлы заманча мәйдан эшләячәк, анда 4 мең яңа эш урыны булдырылачак. Бу объект Татарстанда ИТ-индустрия үсешенә яңа этәргеч бирәчәк.

Республика Хөкүмәтенә мониторинг чаралары һәм киберкуркынычка каршы көрәшүне оештыру өчен чаралар белән тәэмин итү, дәүләт секторын илдә җитештерелгән программа тәэминаты һәм җиһазларына күчерү эшен дәвам итәргә кирәк.

СОЦИАЛЬ ПРОЕКТЛАР ТУРЫНДА

Без тормыш сыйфатын яхшыртуга юнәлтелгән милли проектларны һәм республика программаларын тулы күләмдә үтәүне дәвам итәбез. Быел аларның саны 44 кә җитә. Татарстан бюджетыннан 46 млрд сумнан артык акча бүлеп бирелде.

Әлеге эшкә комплекслы карарга кирәк. Торак төзү белән генә чикләнмичә, социаль, транспорт, инженерлык, бизнес инфраструктурасы объектларын төзүгә, шулай ук тулаем территорияне төзекләндерүгә игътибар бирү шарт. Моның өчен шул исәптән яңа төзелгән Киңлекләрне планлаштыру институты һәм Киңлек мәгълүматлары фонды җаваплы.

Россия Федерациясе Президенты йөкләмәсе буенча федераль дәрәҗәдә Торак-коммуналь хуҗалыкны яңарту комплекслы программасы әзерләнә.

ЮЛЛАР ТӨЗҮ ТУРЫНДА

Республикада юл хуҗалыгы тармагында киң колачлы проектлар тормышка ашырыла. Бу – М-12 трассасын төзү, М-7 трассасын реконструкцияләү.

Шулай ук Шәле–Баулы трассасы проекты кысаларында Алексеевское–Әлмәт автомобиль юлын төзү эшләре алып барыла, ул М-7 һәм М-12 трассаларын М-5 трассасы белән тоташтырачак һәм алга таба Казахстан белән Кытайга чыгу мөмкинлеге бирәчәк. Әлеге проектларны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә 2025 елда 1 нче категорияле юлларның озынлыгы ике тапкырга артачак, Идел һәм Кама елгалары аша ике күпер файдалануга тапшырылачак.

«Имин һәм сыйфатлы юллар» милли проекты кысаларындагы проектлар да тормышка ашырыла килә, шул исәптән Зур Казан боҗрасы, Вознесение тракты төзелә һәм Горький шоссесы реконструкцияләнә.

Республика программалары кысаларында муниципаль юл челтәрләрен үстерү буенча эшләр дәвам итә. Һәр елны авыл территорияләрендә кимендә 700 километр юл төзелә һәм төзекләндерелә.

Казанда метроның икенче линиясе төзелә, ул пассажирлар агымы аеруча зур булган микрорайоннарны тоташтырачак.

МӘГАРИФ ҺӘМ ТУГАН ТЕЛЛӘР ТУРЫНДА

2023 ЕЛ РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕНДӘ УКЫТУЧЫ ҺӘМ ОСТАЗ ЕЛЫ ДИП ИГЪЛАН ИТЕЛДЕ. Илебез Президентының әлеге карары җәмгыятебездә укытучы һәм остазларның югары абруен, аларның хезмәте әһәмиятле булуын раслый.

Мәгариф системасының төп бурычы – педагогик кадрларны тиешле дәрәҗәдә әзерләүне тәэмин итү. **Югары уку йортларын тәмамлаучыларның иң белемлеләрен, иң яхшыларын укытучы һөнәрен сайларга кызыксындыру буенча эшне активрак дәвам итәргә кирәк.**

Файдалы һәм кирәкле җәмәгать башлангычларына булышлык күрсәтүнең нәтиҗәле институты буларак, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе эшчәнлеген аерым билгеләп үтәсем килә. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе итеп үзгәртеп корып, аның функцияләрен киңәйтү турында карар кабул ителде.

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы рус теле комиссиясе оештырылды. Татар теле буенча укыту-методик комплектлар һәм дәреслекләр, башка фәннәр буенча тәрҗемә басмалар эшләү эшендә шулай ук сизелерлек алга китеш бар.

Республиканың Мәгариф һәм фән министрлыгына әлеге эшне алга таба да дәвам итәргә кирәк булачак.

ЯШЬ БУЫН ТУРЫНДА

Сәләтле балалар һәм яшьләр белән эшләүнең нәтиҗәле системасын формалаштыру – илебез Президенты тарафыннан билгеләнгән төп юнәлешләрнең берсе. Безнең бурыч – яшьләр киләчәктә тормыш итү һәм үсеш урыны буларак Татарстанны сайласын өчен, аларга уку, эшләү һәм ял итү өчен барлык шартларны булдыру.

Агымдагы елда федераль дәрәҗәдә балалар һәм яшүсмерләрнең гомумроссия дәүләт-иҗтимагый хәрәкәтен оештыру турында игълан ителде, аның күзәтчелек советын Владимир Владимирович Путин җитәкли. Әлеге хәрәкәт яшь буынны берләштереп, нигезен Ватанга мәхәббәт тәшкил иткән һәм көчле Россия төзү кебек уртак максатка ирешүгә юнәлдерелгән тәрбия бирүнең яңа алымнарын формалаштыруга хезмәт итәчәк. **Әлеге бурычларның гомумдәүләт дәрәҗәсендә әһәмиятен исәпкә алып, республика Хөкүмәтенә Татарстанда яңа хәрәкәтне оештыруда һәрьяклы ярдәм күрсәтүне йөклим.**

Алдыбызда төрле өлкәләрдә җитди бурычлар тора. Уртак тырышлык белән без аларны үтәп чыга алачакбыз. БЕЗ БЕРГӘ! БЕЗ БУЛДЫРАБЫЗ!

МОБИЛИЗАЦИЯЛӘНГӘН ГРАЖДАННАРГА, ЭШКУАРЛАРГА ҺӘМ БИЗНЕСКА ИКЪТИСАДЫЙ ЯРДӘМ ЧАРАЛАРЫ

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетында өлешчә мобилизация шартларында Россия икътисадының тотрыклылыгын тәэмин итү мәсьәләләренә багышланган брифинг узды. Брифингта катнашучылар мобилизацияләнгән гражданнарга һәм эшкуарларга ярдәм итү буенча федераль һәм республика чараларының бүгеннән үк кулланырга мөмкин булган киң исемлеген тәкъдим итте.

КРЕДИТ КАНИКУЛЫ

Мобилизациягә кадәр яки махсус хәрби операция башланганчы рәсмиләштерелгән барлык кулланучылар кредитлары һәм займнар (ипотека, шулай ук кредит карталарын да кертеп) буенча түләүләрне кичектереп тору.

Каникул чоры:
30 көнгә арттырылган мобилизация срогы (бу вакытта штрафлар, неустойка һәм пеня исәпләнми). Кече һәм урта бизнес хуҗалары өчен 90 көнгә (һәм реабилитация узган очракта озагракка да) арттырыла.

Ташламадан кем файдалана ала:
- Махсус хәрби операциягә мобилизацияләнгән гражданнар (шул исәптән шәхси эшкуарлар), хәрби хезмәткәрләр һәм контракт белән киткәннәр, шулай ук аларның гаилә әгъзалары*.
- Җәмгыятьнең бердәнбер гамәлгә куючысы һәм бер үк вакытта аның җитәкчесе булып, ә компания үзе кече һәм урта эшкуарлык реестрында теркәлгән очракта – ҖЧҖ хуҗалары.

Ташламадан ничек файдаланырга:
Кредиторга мөрәҗәгать итәргә. Физик зат (яки аның ышаныч кәгазе нигезендә эш йөртүче вәкиле) – телефон аша яки кредит килешүендә күрсәтелгән бүтән ысулны кулланып. ҖЧҖ гамәлгә куючы яисә аның ышаныч кәгазе нигезендә эш йөртүче вәкиле кредиторга кредит каникулы турында таләп юллый.

** Тулырак – 377-ФЗ номерлы Федераль закон, 07.10.2022.*

Фото: tatarstan.ru

ЭШЛӘРНЕ ТАПШЫРУ ӨЧЕН 5 ЭШ КӨНЕ

Шәхси эшкуарлар, оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар), шулай ук бердәнбер башкарма орган вәкаләтләрен башкаручы җитәкчеләр мобилизацияләнгән очракта эшкуарлык эшчәнлеге буенча оештыру мәсьәләләрен хәл итү өчен 5 эш көне ала, шул исәптән ышанычлы затлар аша эшләнгәндә дә.

САЛЫМ ТҮЛӘҮ ҺӘМ ОТЧЕТ БИРҮ СРОГЫН ОЗАЙТУ

– шәхси затлар, үзмәшгульләр, ШЭ һәм бердәнбер гамәлгә куючысы һәм башкарма органы булган ҖЧҖ өчен.

Хезмәт тәмамланган айдан соң килүче өченче айның 28енә кадәр салымнар (НДФЛ һәм табышка салымнан тыш), җыемнар, иминият кертемнәрен түләү срогы озайтыла.

Хезмәт тәмамланганнан соң килүче өченче айның 25енә кадәр салым декларацияләрен (өстәмә табышка салым декларациясеннән тыш), исәп-хисаплар, бухгалтер хисабын тапшыру срогы озайтыла.**

ДӘҮЛӘТ МИЛКЕН АРЕНДАЛАГАН ӨЧЕН ТҮЛӘҮЛӘРНЕ КИЧЕКТЕРЕП ТОРУ

– бердәнбер гамәлгә куючысы һәм бердәнбер башкарма орган булган ШЭ һәм ҖЧҖ өчен:

- Кичектерелү федераль милекнең барлык төрләренә, шул исәптән җир кишәрлекләренә дә кагыла.
- Коммуналь түләүне мондый кичектерелү чорында арендага тапшыручы үзе түли.
- Дәүләт милкен арендалау килешүен штрафсыз өзәргә мөмкин.

МИКРОКРЕДИТ БИРҮНЕҢ МАКСИМАЛЬ СРОГЫН АРТТЫРУ

– хәрби хезмәт узу срогы дәвамында. Ташлама мобилизациягә яки контракт хезмәте килешүе төзүгә кадәр алынган, шул исәптән Татарстан эшкуарлыгына ярдәм итү Фонды тарафыннан бирелгән микрозаймнарга кагыла. Рәсмиләштерү процедурасы кредит каникулын алгандагы кебек үк.

ДӘҮЛӘТ КОНТРАКТЛАРЫ БУЕНЧА ЙӨКЛӘМӘЛӘР

Әгәр мобилизациягә бәйле рәвештә дәүләт контрактында катнашучы яки тәэминатчы үз йөкләмәләрен үти алмый икән, моңа бәйле пеня, штрафлар салынмаячак. Шулай ук оешма яки ШЭ намуссыз башкаручылар (тәэминатчылар) реестрына кертелмәячәк. Моннан тыш, яклар килешүе нигезендә контракт шартларын үзгәртү рөхсәт ителә. Бу чара 2023 ел ахырына кадәр гамәлдә булачак.

ХЕЗМӘТКӘРЛӘР САНЫ БУЕНЧА ТАЛӘПЛӘРНЕ ҮТӘҮНЕ КИЧЕКТЕРЕП ТОРУ

Әгәр мобилизация нәтиҗәсендә предприятиенең штаты закон буенча билгеләнгән минималь дәрәҗәдән артыгракка кимесә, компания эшен вакытлыча дәвам итә ала, штраф салынмый. Киткәннәрне вакытлыча алыштыру өчен хезмәткәрләрне 3–6 ай эчендә табарга кирәк. Лицензия таләпләренә туры килүне раслау, предприятиенең төренә карап, хезмәт итү вакытына һәм 6 айга кадәр озайтыла.

2022 ЕЛДА АЛЫНГАН ГРАНТЛАР БУЕНЧА ЙӨКЛӘМӘЛӘРНЕ ҮТӘҮНЕ ТУКТАТУ

– хезмәт итү срогы дәвамында (мобилизация яки контракт буенча), алга таба нәтиҗәләргә ирешү вакытын озайту да карала. Грант күләме үзгәрми. Билгеләнгән нәтиҗәләргә ирешелмәсә, аны киметергә яисә грантны куллану вакытын озайтырга мөмкин. Гранттан штрафсыз баш тарту мөмкинлеге бар.

Нәрсә эшләргә кирәк:

Грант бирү турында шартнамә срогы дәвамында, хәрби хезмәтне тәмамлаганнан соң 30 календарь көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Икътисад министрлыгына теләсә кайсы уңайлы ысул (телеграмма, факсограмма, кучмә радиотелефон элемтәсе чаралары, почта элемтәсен һәм электрон почтаны кулланып) белән тиешле гариза юлларга.

Өлешчә мобилизация шартларында эшкуарлыкка һәм бизнеска ярдәм итү буенча ТР хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган чаралар:

- 2021 ел өчен транспорт салымын түләүдән азат итү.
- Татарстан Республикасы Гарантия фонды биргән кредитларны реструктурлаштыру, бу вакытта түләүләр елына 0,5%тан 3 елга кичектереп торыла.
- Республика мөлкәтен арендалаган өчен түләүләрне кичектереп тору.

** Тулырак - РФ Хөкүмәтенең 1874 нче Карары, 20.10.2022

төп тема

УРТАГА САЛЫП СӨЙЛӘШЕР ЧАК

Каникул вакыты... Сез, бәлки, ышанмассыз да, ләкин бу безнең өчен уку-укыту процессында катнашучыларны бер-берсеннән аеру һәм тыныч кына сөйләшү мөмкинлеге табылган бердәнбер буш вакыт булды.

Ата-аналар һәм балалар турында – укытучылар белән.

Укытучылар һәм балалар турында – ата-аналар белән.

Ата-аналар һәм укытучылар турында – балалар белән.

Балалар, укытучылар һәм ата-аналар турында – ТР мәгариф һәм фән министры белән.

Төрле фикерләргә һәм үзара дәгъваларга карамастан, белем бирү процессында катнашучылар арасында зур мәхәббәт һәм ихтирам булуын чагылдырган кызыклы картина туды. Ничекме? Шулай – үзегез укып карагыз!

PRESSA

КӨЗГЕ КАНИКУЛ НИГӘ БИК КЫСКА?

Малай һәм кызларны, шулай ук аларның әти-әниләре һәм укытучыларын кызыксындырган шушы һәм башка сорауларга Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры Илсур Гәрәй улы Һадиуллин җавап бирә.

Фото: Алсу Шакирова

УКЫТУЧЫЛАРДАН:

КӘГАЗЬ ВОЛОКИТАСЫ БЕТСЕН!

– Илсур әфәнде, документлар әйләнешен тотыруга һаман үсә барган таләпләр укытучыларның бик күп вакытын ала, ә бит алар бу сәгатьләрне балаларны укытуга, алар белән күбрәк аралашуга сарыф итә алыр иде. Нәтиҗә буларак, укытучы эше, балалар белән турыдан-туры эштән һаман ераклашып, документлар тотыруга гына әйләнеп бара бугай. Вазгыять үзгәреп, кәгазь волокитасы белән мөгаллимнәр түгел, бәлки мәктәп администрациясе шөгыльләнә башлауга өмет бармы ул?

– Мәгариф системасында кәгазьләр һәрвакыт күп булды, әмма укытучының төп миссиясе – укыту һәм тәрбияләү. Әгәр без укытучыны статистка әйләндерәбез икән, нәтиҗәләр турында сөйләргә туры килмәячәк тә. Шунлыктан әлеге юнәлештә төрле дәрәҗәләрдә шактый җитди эш алып барабыз.

«Россия Федерациясендәге мәгариф турында» законга 2022 елның 1 сентябреннән гамәлгә кергән төзәтмәләрне дәлил итеп күрсәтим – алар буенча, хәзер укытучылар Россия Мәгариф министрлыгы раслаган исемлектәге хисапларны гына әзерләргә, ә электрон документлар әйләнеше кәгазьдә дә кабатланырга тиеш түгел. Бүгеннән укытучыга нибары биш документ тотыру зарур:

1) уку предметының (курсының) эш программасы;

2) өлгерешне исәпкә алу журналы (ул һәрвакыт булды һәм булачак);

3) дәрестән тыш эшчәнлек журналы (дәрестән тыш эшчәнлек алып баручы педагоглар өчен);

4) тәрбия эше планы (сыйныф җитәкчесе өчен);

5) укучыга характеристика (кирәк булган очракта).

Барлык башка документлар мәгълүмат базасында бар. Әгәр мәктәп администрациясеннән кемгә дә булса әлеге документлар кирәк була икән, рәхим итеп мәгълүмат базасыннан алыгыз, укытучының игътибарын укыту процессыннан читкә юнәлдермәгез!

ДОКУМЕНТАЦИЯ ТОТЫРУ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕНДӘ ХОКУК БОЗУ ОЧРАКЛАРЫ БУЛА ИКӘН, педагоглар ТР МһФМның мәгариф тармагында күзәтчелек һәм контроль департаменты ачкан «Кайнар линия»гә шалтырата ала. Мөрәҗәгатьләр «ВКонтакте» челтәрендә https://vk.com/obrnadzor_tatarstan бергәлегендәге хәбәрләр аша һәм 8 (843) 237-76-21, 8 (843) 237-75-15 телефоннары буенча кабул ителә.

Кәгазь документлар тотыруны киметү турындагы фәрманны катгый контрольдә тотачакбыз – «Рособрнадзор» мониторинг алып бара. Укытучы балаларны укытырга, алар белән шөгыльләнергә тиеш – һәм шул гына!

ҺӨНӘРИ ҮСЕШ МОДЕЛЕ

– Без сагынып сөйләргә яраткан совет чорында укытучы һөнәренең абруе, дәрәҗәсе бик югары иде. 1990 нчы елларда исә алар иң хәерче катламга әйләнде, беркемнең дә укытучы буласы килмәде. Инде хезмәт хакы югарырак, шартлар күпкә яхшырак булса да, хәзергә кадәр әлеге стереотип саклана әле. Укытучы һөнәренең абруен ничек күтәрергә?

– Укытучының статусы, абруе бүгенгедән һичшиксез югарырак булырга тиешлеген һәркем аңлый. Без бит үз балаларыбызны мөгаллимгә ышанып тапшырабыз, алардан нәтиҗә дә көтәбез. Ә нәтиҗәгә ата-аналар белән мәктәп арасында үзара аңлашу, шулай ук укытучының һөнәри осталыгы булганда гына ирешергә мөмкин. Моның өчен нәрсә эшләнә? Республикада берничә модель гамәлдә. Мәсәлән, һөнәри үсеш моделе. Аңа нәрсә керә?

Беренчедән, квалификацияне даими күтәрү. Татарстанда укытучыларның квалификациясен күтәрү белән 18 учреждение шөгыльләнә. Аларның сораулары буенча махсус программалар формалаштырабыз. Ел саен 1000нән артык укытучыны үз сафларыбызга алабыз.

Икенчедән, остазлык мәктәпләре бар, аларда яшь укытучылар һәм тәҗрибәле педагоглар бер-берсенә ярдәм итә. Мәсәлән, цифрлы технологияләрне яшьләр тизрәк аңлый һәм үз тәҗрибәсен өлкәнрәкләргә тапшыра. Ә инде психологик әзерлек, балалар белән эш җәһәтеннән – киресенчә, биредә зирәгрәк өлкән буын үз тәҗрибәсен яшьләр белән уртаклаша. Яшьләрнең иң яхшы остазлары «Мактаулы остаз» билгесе белән бүләкләнә.

Моннан тыш, Татарстанда психология-педагогика юнәлешендәге 173 сыйныф ачтык. Бу – 8–11 сыйныфлар. Ягъни булачак укытучыларны әзерләү инде мәктәптә үк башлана. Аларны республика югары мәктәпләре педагог һәм психологлары укыта, аларның дәресләренә галимнәр килә. Өлкән сыйныф укучылары мәктәп яны лагерьларында кызыклы педагогик практика үтә ала. Болар барысы да һөнәрнең асылына төшенү мөмкинлеген бирә. Аннары исә белем алуны югары уку йортларында дәвам итәргә була. Шул рәвешле әзерләнгән мәктәп баласы инде педагогика уку йортына конкурс түбән булганга түгел, үз күңеле тартканга, укытучы булырга хыялланганга керәчәк...

Исегезгә төшерәм: «Россия Федерациясендәге мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендә кабул ителгән 273 нче Федераль законга ярашлы рәвештә, «мәгариф тармагында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү» термины юкка чыгарылды, укытучылар мәгариф программаларын гамәлгә кертү белән шөгыльләнә, үз чиратында бу да педагогның статусын күтәрә.

БУЛАЧАК УКЫТУЧЫЛАРДАН:

АТА-АНАЛАР КҮП, ЭШ ХАКЫ АЗ

– Мин бу уку елында педагогика югары уку йортын тәмамлыйм һәм безнең төркемнән нибары ике кешенең генә мәктәпкә эшкә барырга җыенуын беләм. Күпчелекне хезмәт хакының түбән булуы түгел, бәлки, укытучыны бала караучы персоналга тиңләүче адекват булмаган ата-аналар куркыта. Моңа бәйле рәвештә сорау туа: укытучыны ата-ананың шундый мөнәсәбәтеннән ничек якларга?

– Бүген инде безнең югары уку йортларындагы педагогик белгечлекләр буенча 700 дән артык урын бюджет хисабына финанслана. Бу студентлар, имтиханнарын уңышлы тапшырган очракта, республика Президентының 15 мең сумлык стипендиясен ала. Өч яклы килешү төзелә: студент – югары уку йорты – эш бирүче. Һәм уку тәмамланганнан соң белгеч үз районында, үз мәктәбендә биш ел мәҗбүри эшләргә тиеш була.

Әмма, ышанмассыз да, бу бюджет урыннарына вакансияләр дә кала. Ни өчен анда укырга керергә теләмиләр? Сез хаклы – чөнки кайбер ата-ананың мәгариф системасына, мәктәпкә мөнәсәбәте үз ихтыяҗларын гына канәгатьләндерүгә юнәлтелгән, һәм бу бөтенләй дөрес түгел. Балаларны бергәләшеп тәрбияләргә һәм укытырга кирәк. Гаилә һәм мәктәп бердәм булырга тиеш. Укытучының, остазның эшен, үз мөгаллиме тырышлыгы белән нәтиҗәгә ирешкән укучыларны күрсәтү зарур. Чөнки укытучы – баланың киләчәгенә билет бирүче ул.

Яшь укытучыларның мәктәпләрдә эшкә берегеп калуы җәһәтеннән дә проблемалар бар. Елына 2000 кеше көндезге бүлекләрдә белем ала. Шулардан 1000 ләбе – педколледж тәмамлаучылар. Аларга сораулар юк. Анда укыту методикасы һәм технологиясе яхшы. Ә менә югары уку йортларыннан белгечлекләре буенча эшкә урнашучылар аз. Әйе, бюджет урыннарына керәләр, белем алалар, ә эшкә бармыйлар. Гәрчә ул бүген шактый саллы булса да, кемнедер хезмәт хакы канәгатьләндерми. Әмма югары эш хакының шундук түләнә башламаячагын аңларга кирәк бит. Балалар, ата-аналар белән ничек эшләвеңне, сәләтеңне күрсәтергә курыкма син. Үз квалификацияңне даими күтәрергә тырыш. Безнең республикабыз, президентыбыз яшь педагогларга социаль ипотека җәһәтеннән дә, өстәмә хезмәт хакы җәһәтеннән дә һәрвакыт булышырга әзер.

Кемнедер укучыларның ата-анасы белән мөнәсәбәтләр куркыта. Һәм аларны аңларга да була. Яшь педагог мәктәпкә килә. Сыйныфында – 25–30 бала һәм һәркайсының этисе, энисе, икешәр әбисе һәм икешәр бабасы бар. Алар өчен ул бала – галәм үзәге. Әле кичә генә үзе дә бала булган яшь педагогка ярдәм итәсе урынга, ата-аналар шундук өйрәтергә, таләп итәргә керешә, ял көннәрен дә, инде соң булуын, укытучының да ял итәргә хакы булуын онытып, теләсә кайчан аптырата башлый... Аңлашыла ки, мондый басым нәтиҗәсендә курку, борчылулар пәйда була. Ата-ана баласын тәрбияләү буенча барлык проблемаларны укытучыга өеп калдырырга түгел, бәлки аңа ярдәм итәргә тиеш. Һәр бала гаиләдә тәрбияләнә. Бергәләшеп гамәл кылганда, без зуррак уңышларга ирешәчәкбез.

НИЧЕК ИТЕП «АВЫЛ УКЫТУЧЫСЫ» БУЛАСЫ?

– Авыл мәктәпләрендә укытучыларга һәрвакыт кытлык. «Авыл укытучысы» программасы дәвам итәчәкме, һәм аңа ничек элэгергә?

– Районнарда үзенчәлекле «юл карталары» әзерләнгән, алар яшь белгечләрне авыл мәктәпләрендә «беркетү» мөмкинлеген бирә.

«Авыл укытучысы» программасы нәтиҗәсендә өч елда авыл мәктәпләрендә таләп ителгән урыннарга 32 укытучы җәлеп ителде, шул исәптән башка төбәкләрдән килүчеләр дә бар.

«АВЫЛ УКЫТУЧЫСЫ» КОНКУРСЫНДА КАТНАШУ өчен үзеңә кирәкле бер вакансиягә http://zemteacher.apkpro/ru/ порталында гариза калдырырга кирәк. Гаризалар 10 гыйнвардан 15 апрельгә кадәр кабул ителә. «Авыл укытучысы» федераль программасы буенча конкурска һөнәри урта яки югары белемле, квалификация таләпләренә һәм һөнәри стандартларга җавап бирүче, 55 яшькә кадәрге, РФ гражданнары булган укытучылар гариза бирә ала.

«Авыл укытучысы» федераль программасы Татарстанда 2023-2024 елларда да гамәлдә булачак.

АТА-АНАЛАРДАН:

ПОЛИЛИНГВАЛЬ ҮРНӘК

– Полилингваль мәктәпләрдә алынган белемгә кагылышлы нindiдер нәтиҗәләр бармы инде? Татарстанда мондый мәктәпләр тагын ачылачакмы?

– Нәтиҗәләр турында сөйләргә иртәрәк әле. Беренче комплекслар 2020 елда ачылды, һәм, нindiдер йомгак ясар өчен, 1 сыйныфтан 11 сыйныфка кадәр юл үткән бер буынны үстерергә кирәк. Бүген алты полилингваль мәктәптә 7 меңнән артык бала укый, 400 дән артык укытучы укыта, педагогларның 80 проценттан артыгы – татар телен, 50 проценттан артыграгы инглиз телен белә. Әйләнә-тирә дөнья, тарих, җәмгыять белеме, биология, география, технология, физкультура, музыканы балалар татарча, технология, музыка, география, математика, биологияне инглизчә өйрәнә.

Яңа полилингваль мәктәпләр ачу әлегә планлаштырылмый, әмма Татарстан Президенты тәкъдиме белән «Адымнар» мәктәбендә «Сәләт» сыйныфлары оештырыла.

«Адымнар» – Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәрип улы Шәймиев тырышлыгы нәтиҗәсендә пәйда булган яхшы проект. Мондый проектларны республика ярдәменнән башка гамәлгә ашырып булмый. Җиһазлау җәһәтеннән дә, укыту җәһәтеннән дә. Мәктәпнең шигаре: «Адымнар – белем һәм татулыкка юл!» Ата-аналар, укытучылар һәм укучылар арасындагы татулык бирердә һәрнәрсәдә сизелә. Мин хәзер Татарстаныбызда яшәүче халыкларның бердәмлеге хакында сөйлим. Укыту программасы – бер үк, ә укыту телләре – төрле. Мондый мәктәпләр – бөтен Россия өчен үрнәк. Башка милләтләргә хөрмәт, өлкәннәргә ихтирам, Ватанга мәхәббәт, патриотизм – барысы да балалар бакчасыннан, мәктәптән башлана. Балаларыбызда уңай сыйфатлар тәрбияләп, без чын шәхесләр формалаштырабыз.

Ата-аналарны балалар белән үзара хезмәттәшлек алымнарына актив өйрәтү максатларында «Адымнар» мәктәбендә «Ата-аналар университетлары: «Мин – актив әти-әни!» укыту-методик программасы эшләнгән. ӘЛЕГЕ ПРОГРАММАНЫ РЕСПУБЛИКАНЫҢ БАШКА МӘКТӘПЛӘРЕНДӘ ДӘ ФАЙДАЛАНУ ЗАРУР.

2023 елга Татарстан Президентының Дәүләт Советына Юлламасыннан

МАГИСТРАТУРАМЫ, СПЕЦИАЛИТЕТМЫ?

– Хәзерге сәяси вазгыятькә бәйле рәвештә, бездә укытуның Болон (Болонья) системасы (бакалавриат һәм магистратура) сакланачакмы, әллә без кире специалитетка әйләнеп кайтачакбызмы?

– Болон системасы төрле илләрнең югары уку йортларын берләштерә һәм әлеге системада катнаша торган илләренең дипломнарын тануга юнәлтелгән. Ул югары белем бирү системасын бакалавриат, магистратура, докторантура баскычларына бүлә. Ахыр чиктә бу – яшь белгечләрнең Россиядә дә, чит илләрдә дә эшкә урнашу мөмкинлекләрен арттыру ысулы.

Россиядә Болон системасын саклап калу-калмау турында карарлар федераль дәрәҗәдә кабул ителә. Болон системасыннан чыккан очракта башкарма хакимиятнең федераль органнары һөнәри белем баскычларын билгеләүне яңадан караячак, шуңа бәйле рәвештә федераль законнарга да үзгәрешләр кертәчәк.

Ихтимал, Россиядә үзебезнең мәгариф системасы кирәктер. Әмма бу безнең вәкаләтләр түгел инде. Шәхсән үземнең фикерем мондый – белемне бер генә өлкәдә алган студенттан яхшы белгеч чыгачак: хәзер исә бакалавр 4 ел буе, мәсәлән, педагог булырга укый, аннары, магистратурага күчкәч, юрист һөнәрен өйрәнә.

Ихтимал, система үзгәрер дә, чөнки без үз илебездә яшәргә, үз илебездә эшләргә әзер булган чын белгечләр әзерләргә тиеш. Европадагы толерантлык төшенчәсе үзенең нинди булуын күрсәтте инде. Бездә андый төшенчә юк. Илебез халыклары гасырлар буе бер-берсе белән тыныч һәм тату яши. Без бер-беребезнең менталитетын беләбез, безгә бергә рәхәт, кирәк булганга гына тешне кысып түзеп яшәмибез.

КАЙСЫ БДИ - ЯХШЫ, Ә КАЙСЫ - НАЧАР

– Ата-аналарның күпчелеге, БДИ безнең балаларны белемгә омтылудан мәхрүм итеп, тестлар эшләүгә генә (бигрәк тә чыгарылыш сыйныфларында) күнектерә, дип саный. Мәктәп балаларыннан имтихан алуның үзебезгә хас системасына кире әйләнеп кайту ихтималы бармы?

– Бүген БДИ – укучылар белеме сыйфатын бәяләүнең бердәнбер системасы ул. Аннан хәзер үк баш тарту өчен, нindiдер башка системаны кабул итәргә кирәк. Ә ул юк! Әмма безнең Педагогик үлчәүләр федераль институты (ФИПИ) бар, ул контроль-бәяләү материалларының (КИМ) эчтәлеген яхшырту белән шөгыльләнә. Ягъни тестлардагы сораулар укучыны уйланырга мәҗбүр итәрлек булсын дип тырыша... Стандартлар яңартылып тора, һәм укытучылар аларны яхшы белә. Бала беренче сыйныфтан ук тырышып укыган очракта, БДИ – яхшы. Бала унынчы сыйныфта гына уку белән кызыксына башлый һәм әти-әнисе аңа шул вакытта гына репетитор яллый икән – БДИ начар. Бу бик начар! Сүз уңаеннан, еш кына репетиторлар яңартылган стандартларны белми дә, бу исә БДИ тапшырганда гына ачыкланырга һәм начар нәтиҗәгә китерергә мөмкин. Беренче сыйныфтан ук тырышып укырга кирәк, һәм барысы да яхшы булачак.

АТА-АНАЛАРДАН:

БЕЗ УЯУ БУЛЫРГА ТИЕШ

– Кайбер фаҗигале мисаллардан күренгәнчә, мәктәп ничек кенә яхшы сакланмасын, анда барыбер нинди дә булса явыз ниятле кеше үтеп керә ала. Казандагы һәм Ижевскидагы очраклардан соң мәктәпләрдә балаларның иминлеген кайгырту максатында нинди чаралар күрелә?

– 175 нче мәктәптәге фаҗига, мәктәпләрдәге иң заманча куркынычсызлык чараларына карамастан, уяулыкны югалтмауның зарурлыгын күрсәтте. Чөнки өч метрлы коймалар да, периметр буенча һәм мәктәп эчендә күзәтү алып бару мөмкинлеген биргән видеоҗиһазлар да, сак сигнализациясе дә, башка норматив таләпләр дә кеше уяулыгын алыштыра алмый. Казандагы балалар учреждениеләрендә террорчылыкка каршы иминлек чараларына быел 2 миллиард сумнан артыграк акча тотылды. Киләсе елга Татарстан бюджеты һәм муниципалитетлар бюджетлары проектларында мәктәпләрне хосусый сак предприятиеләре белән тәэмин итүгә 1,44 миллиард сум акча бүленгән.

Әмма шуны хәтердән чыгармау мөһим: мәктәп бит ул хәрби объект түгел, анда корал юк, анда – балалар. Ул – тере организм.

Идеалда исә безнең балалар гомеренә кизәнүче ерткыч бәндәләр йә дәвалау, йә төзәтү учреждениеләрендә изоляцияләнгән булырга тиеш. Әлегә иректә йөриләр икән, вакытында туктатылырга тиешләр. Йә үз туганнары тарафыннан – алар бит ялгыз яшәми, яисә хокук саклау органнары тарафыннан. Без һәркайда, һәркемгә, әйләнә-тирәдәгеләргә карата уяу булырга тиеш – бу иң мөһиме.

УКУЧЫЛАРДАН:

ПРОГРАММАЛАР ТӨРЛЕ – НӘТИҖӘ БЕР ҮК

– Мин тугызынчы сыйныфта укыйм, гаиләм бер шәһәрдән икенчесенә еш күченгәнгә, миңа һәр яңа мәктәптә яңа программа буенча укырга туры килә. Башымда – ботка. Ни өчен укыту программалары төрле җирдә төрлечә?

– Программаларның төрлелеге бездә 1990 нчы еллардан башланды. Без укыганда бөтен илдә бер программа иде. Калининградтан Камчаткага кадәр – бер үк төрле математика, әлифба, табигать белеме дәреслеге... Ә менә хәзер бер үк фәннән дәреслек берничә. Күпмедер дәрәҗәдә мин бу укучы белән килешәм. Әмма дәреслекләр төрле булса да, федераль стандартлар бердәм бит. Төрле дәреслекләр, төрле программалар буенча шөгыльләнеп, без бер үк төрле нәтиҗәгә ирешергә тиеш.

Шул рәвешле, материалны өйрәнү тәртибендәге кайбер үзгәрешләр гамәлдәге законнарга каршы килми.

БАРЫСЫ ДА ГАДЕЛ!

– Ни өчен көзге каникул бик кыска?

– Бик кыска да түгел инде. 29 октябрьдән 6 ноябрьгә кадәр – 9 көн. Әлбәттә, җәйгесе кебек озын була да алмый. Әле бит беренче чирек, ике ай гына узды – өч айлык ялдан соң арырга да өлгермәдегез!

Уку елында каникулга 30 көн бирелә: көзге, кышкы, язгысына. Димәк, барысы да дөрес һәм барысы да гадел.

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫННАН:

ИНЖЕНЕРЛЫК БЕЛЕМЕ

– Илсур әфәнде, мәктәпләрдәге «инженерлык белеменә» карашыгыз нинди?

– Уңай! Татарстанда өстенлекле саналган машина төзелеше һәм нефть-газ-химия сәнәгате тармакларында югары квалификацияле кадрларга ихтыяҗ зур. Ә инде ихтыяҗ бар икән – химия, биология, физика, информатикадан яхшы әзерлекле абитуриентлар таләп ителә. Шунлыктан без профильле укыту мөмкинлекләрен белем бирүнең сыйфатын күтәрү максатларында файдаланабыз.

Моңа «Инженерлар республикасы» мәгариф проекты мисал була ала. Аның төп идеясе – республикада инженерлык мәктәпләре челтәрен булдыру. Мондый мәктәпләрнең максаты – һөнәри инженерлык-техника эшчәнлегенә һәвәс талантлы балаларны ачыклау һәм укыту.

Әлеге проект 2018 елда Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты, Яшьләр инновацияле иҗат үзәге (ЦМИТ-КАИ), Speak English Инглиз теле мәктәбе катнашында һәм ярдәмендә гамәлгә кертелә башлады.

Бүген әлеге проектта 500 укучы – 36 сыйныф катнаша. Бу – заманча белем бирү технологияләрен файдаланып, үзендә авторлык мәгариф программалары буенча техника һәм лингвистика юнәлешләрен берләштергән өстәмә белем бирү.

«МӨҺИМ СӨЙЛӘШҮ»

– Мәктәптә «Мөһим сөйләшү» дәресләре кертелде. Алар элегрәк «пионерия» һәм «комсомол» кебек хәрәкәтләргә йөкләнгән, хәзер җуелган патриотик вазыйфаны тиешле дәрәҗәдә башкара алачакмы?

– «Мөһим сөйләшү» проекты укучыларда үз ватаннары – Россиягә, анда яшәүче халыкларга, аның тиңдәшсез тарихына, бай табигатенә һәм бөек мәдәниятенә дөрес мөнәсәбәт тәрбияләүгә юнәлтелгән. Әлеге дәрестән тыш чара барлык мәктәпләрдә дә үткәрелә.

Мин моны үз илебезнең, республикабызның патриотларын күпләп тәрбияли башлауда бик җитди чара дип саныйм. Циклограммасы мәгълүм, тематикасы аңлаешлы. Бу – төбәк, республика, муниципалитет үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелгән 34 дәрес, ягъни без дәресләргә җирле темаларны да кертә алабыз. Сөйләшүне сыйныф җитәкчесе яки тарих укытучысы оештыра. Галимнәр, җәмәгать эшлеклеләре, шул мәктәпне тәмамлаган күренекле шәхесләр чакырыла. Гаилә, Конституция темаларын күтәрәләр, хезмәт династияләре, бабайларыбызның Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары, бүгенге вазгыять, очучы-космонавтлар, данлыклы ватандашлар хакында сөйлиләр... Барлык материаллар да мәктәп баласының яшь һәм психология үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелә.

Мондый дәресләр мөһим, әмма алар бит яңалык түгел – өлкәнрәк яшьтәгеләр шуңа охшаш политинформация дәресләрен хәтерли әле. Боларның барысы да киләчәктә балаларга кирәк булачак. Бу дәресләр патриотлар тәрбияләүгә булыша. Хәзер Россия мәктәпләрендә патриотлар хәрәкәте оештырыла. Аны, бәлки, «Россия варислары», бәлки, «Бөркеткәй» дип атарлар. Иң мөһиме – ул укучыларны берләштерергә тиеш. Балаларны чит ил мисалында, чит ил фильмнарында тәрбияләү дөрес түгел. Безнең үз фильмнарыбыз, үз каһарманнарыбыз бар.

«АДЫМНАР – БЕЛЕМ

Татарстандагы

ӘЛМӘТ

«Адымнар – Әлмәт» полилингваль гимназиясе

860 укучы **54** педагог

Полилингваль мохит тудыру өчен эш тулы көн режимында оештырыла. Өстәмә дәресләр, спорт, сәнгать-эстетика юнәлешендәге түгәрәкләр һәм секцияләр оештыру каралган. 22 нче полилингваль балалар бакчасы белән уртак эш планлаштырылган.

Адресы: 423461, Татарстан Республикасы, Әлмәт ш., Ринат Галиев ур., 20 нче бина

Проектны тормышка ашыру башлангычы белән Татарстанның беренче Президенты, ТР Дәүләт Киңәшчесе, ЮНЕСКОның Игелекле ихтыяр илчесе МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВ чыкты. Әлеге инициатива РФ Президенты ВЛАДИМИР ПУТИН һәм ТР Президенты РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ тарафыннан хупланды.

Асылы:

Рус, татар һәм инглиз телләрендә (РФ дәүләт белем бирү стандартларына һәм «Мәгариф» милли проекты бурычларына ярашлы рәвештә) укытыла торган полилингваль белем бирү комплексларын оештыру 2019 елда башлана. Проектны Татарстан Республикасының Тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне торгызу Республика фонды РФ мәгариф министрлыгы һәм ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы белән бергә тормышка ашыра.

КАЗАН

«Адымнар – белем һәм татулыкка юл» полилингваль комплексы

3613 укучы

178 педагог

3 схема буенча укыту:
- билингваль
- полилингваль (ата-ана сайлавы буенча)
- һәм гомуми белем бирү

Комплекс КФУның Филология һәм мәдәниятара коммуникацияләр институты һәм Халыкара мөнәсәбәтләр институты белән хезмәттәшлек итә, ул шулай ук ТР полилингваль комплексларының ресурс үзәге булып тора.

Адрес: 420126, Казан ш., Абдулла Бичурин ур., 22/26

Билингваль схема буенча укучылар гомуми белем бирү предметларын рус һәм татар яисә инглиз телләрендә укыйлар. Полилингваль схема буенча гомуми белем бирү предметлары рус, татар һәм инглиз телләрендә үзләштерелә. Полилингваль сыйныфларда технология, физик культура һәм музыка 3 сыйныфтан инглиз телендә укытыла башлый. Ә 7 сыйныфтан география, биология, математика шулай ук инглиз телендә алып барыла. Инглиз теле укытуда CLIL технологиясе кулланыла.

ТҮБӘН КАМА

«Адымнар – Түбән Кама» полилингваль мәгариф комплексы

1224 укучы (проект буенча) **700** укучы (беренче уку елында)

Адрес: 423570, Татарстан Республикасы, Түбән Кама ш., Төзүчеләр проспекты, 66А

Фото: tatarstan.ru

ҺӘМ ТАТУЛЫККА ЮЛ»

полилингваль комплекслар

Факт

Минтимер Шәймиев тәкъдиме белән барлык комплекслар «Адымнар – белем һәм татулыкка юл» исеме астына берләштерелде. «Адымнар» – комплексның исемендә үк мәктәпнең фәлсәфәсе чагылыш тапкан: телләр һәм мәдәниятләрнең төрлелеген кабул итүче, төрле халыкларның милли традицияләрен хөрмәт итүче яшь буын тәрбияләү.

АЛАБУГА

«Адымнар – Алабуга» полилингваль мәгариф комплексы

1137 укучы **68** педагог

Укыту телләре
- русча
- татарча
- инглизчә

Адрес: 423600, Татарстан Республикасы, Алабуга ш., Бакый Урманче ур., 7а

«Адымнар – Казан» шәһәр яны өстәмә белем бирү үзәге

180 укучыга кадәр

Ел әйләнәсе эшли

Эшчәнлеге: балалар ялын һәм савыктыруны оештыру, полилингваль комплекс укучыларының потенциалын ачу, аларның сәнгать, спорт, техник иҗат, фән өлкәләрендә, гуманитар дисциплиналар буенча сәләтләрен үстерү.

Адрес: Казан, Горький шоссесы, 100

ЯР ЧАЛЛЫ

«Адымнар – Чаллы» 59 нчы полилингваль гимназиясе

850 укучы **60** педагог

Укыту телләре
- русча
- татарча
- инглизчә

Адрес: 423827, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы ш., Чулман проспекты, 91

АКТАНЫШ

«Актаныш – Адымнар» полилингваль комплексы

462 укучы **62** педагог

Укыту телләре
- русча
- татарча
- инглизчә

5–11 сыйныф укучылары гарәп һәм төрек телләрен өйрәнә ала. Комплексның структурасы полилингваль мәктәптән һәм 3 нче һәм 6 нчы мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре белән челтәр хезмәттәшлеге кысаларында мәктәпкәчә белем бирүдән тора.

Адрес: 423740, Татарстан Республикасы, Актаныш ав., Аэропорт ур., 3а

МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВ, ТР ДӘҮЛӘТ КИҢӘШЧЕСЕ:

«Белем – ул аерым көч, нигезләрнең нигезе. Без белем бирү дәрәҗәсен күтәрү һәм моның өчен шартларны яхшырту турында сүз кузгаткач, шундый нәтиҗәгә килдек: заманча, алай гына да түгел ультразаманча мәктәпләрне төзи башларга кирәк, «Адымнар» мәктәбе нәкъ шундый уку йорты да инде».

МӘКТӘП: ҖИДЕ ЙОЗАК АСТЫНДА?

Руфия Фазылова

Бүген балаларыбыз ишекләре бикле биналарда укый. Бер егерме ел эл элек бу хәлләрне кешегә сөйләсәң, һич кенә дә ышанмаслар иде. Ни кызганыч, ачы чынбарлыкны танырга туры килә: Казан, Ижевск мәктәпләрендәге фаҗигаләр... Моңа өстәп, көн саен диярлек төрле мәктәпләргә шартлаткычлар куелу турында хәбәрләр килеп тора. Теге яки бу очракта ничек эш итәргә кирәклеге турында укытучыларга көн саен диярлек инструктаж үткәрәләр. Югыйсә укытучының төп максаты – белем, тәрбия бирү бит.

Мәктәпләребез ничек саклана? Укытучылар, ата-аналар бу хакта нәрсә уйлый? Шул хакта белештек. Алай гына да түгел, башкалабызның берничә мәктәбенә барып, куркынычсызлык таләпләре ничек үтәлүен тикшердек.

«ЮК, СӨЙЛӘШМИМ!»

Казан мәктәпләре буенча тәҗрибә үткәрергә ниятләгәч, башкалабызның төрле районнарына чыгарга кирәк, дип уйлаштык. Иң беренче эш итеп Мәскәү районының 17 нче татар гимназиясенә юл тоттык. Әлеге уку йорты ни өчен игътибарны җәлеп итте: биредә койма юк. Гимназия ишегеннән чыгуга, балалар җәяүлеләр юлына эләгә.

Сынау үткәрергә дип фотографыбыз Александр үзе белән зур букчасын алып чыкты. Аның дәү гәүдәсе, кулындагы аппаратлары теләсә кемдә шик-шөбһә уятырга тиеш кебек тоелды. Мин исә хезмәттәшемнән берничә адым арттарак иярдем.

Гимназиясенең ишеге бикле иде. Төймәгә баскач, озын гына буйлы сакчы ир чыкты. Кайдан, ни өчен килүебезне аңлаткач, ул телефоныннан гимназиянең директорына шалтыратты. Җитәкче Галиева Әлфия Әсгать кызы әллә ни озак көттермәде. Тик ул минем сорауларыма җавап бирүдән баш тартты.

Фото: Александр Ефремов

Мәскәү районының 17 нче татар гимназиясенә юл тоттык. Биредә коймa юк, гимназия ишегеннән чыгуга, балалар җәяүлеләр юлына эләгә..

– Сезнең килүегез турында югарыдагылардан кисәтү булмады, – диде ул.

Гаҗәп, мәктәп тирәсе ни өчен тотылмаган булуны аңлатыр өчен «югарыдагылардан кисәтү» кирәк икән...

Икенче тукталыш Киров районының 67 нче мәктәбе иде. Сакчы ханым, бөтен шартын туры китереп, журналга исем-фамилияләребезне теркәп кул куйдырды.

Шулай да гимназия ишек төбендә торган берничә эни белән сөйләшеп алдык. Белем йортының тирәсе тотылмаган булу аларны борчый булып чыкты. Һәрхәлдә, безгә шулай дип белдерделәр. «Ә мәктәп администрациясенә бу хакта әйткәнегез бармы?» – дигәч, юк, дип баш селкеделәр. «Тавыш чыгарып йөрисе килми», – диделәр. Үзләренең исем-фамилияләрен әйтергә дә теләмәделәр. Алайса инде, дуслар, бигайбә.

«ЯҢА КОЙМА ТОТТЫК»

Икенче тукталыш Киров районының 67 нче мәктәбе иде. 17 нче гимназиядән аермалы буларак, белем йорты биек тимер койма белән әйләндереп алынган. Александр машинадан төште дә капкага юнәлде. Кыңгырауга баскач, мәктәп ишегеннән сакчы ханым күренде. Безнең янга чыгып, кем булуыбыз белән кызыксынды. «Журналистлар», – дигәч, мәктәп директорына шалтыратты. Бушуева Елена Александровна мәктәпкә керергә рөхсәт итте.

Ишегалдына узгач та, сакчы ханым белән якыннанрак таныштык – Марина исемле икән, бик ачык. «Якында гына яшим. Минем аркылы чебен дә очып уза алмый, бөтен кешене йөзеннән таныйм», – диде ул. Мәктәпкә кереп җиткәч, Марина, бөтен шартын туры китереп, журналга исем-фамилияләребезне теркәп кул куйдырды. Аннан директор кабинетына озатты.

– Яңа уку елына мәктәп тирәсен ике метрлы яңа койма белән тотып алдык, – дип сүз башлады Елена Александровна.

– Ә моңа кадәр мәктәп тирәсе тотылмаган идеме? – дим.

– Тотылган иде, тик рәшәткәләр тәбәнәк иде. Хәзер инде куркынычсызлык таләпләренә туры китереп эшләттек.

– Сер булмаса, нинди акчага? Мәктәп бюджетында ул максатка дип акча каралмаган, дип беләм.

– Республика бюджетыннан күчте.

Әлеге белем йортында хәрби юнәлештә белем бирәләр, кадетлар мәктәбе санала. Биредә 392 укучы белем ала. Укучылар иртәнге сигездә көн саен ишегалдына чыгып тезелә, марш атлый. Дәрескә исә 8 сәгать 45 минутта кереп утыралар. Куркынычсызлык буенча даими рәвештә өйрәнүләр үткәрәләр икән.

– Укучылар ишеге бикле сыйныфларда укый, – дип дәвам итте Елена Александровна. – Дөресен генә әйткәндә, мин моның начарлыгын күрмим. Бәлане булдырганчы, аны кисәтү яхшырак. Кызым балалар бакчасына йөри, анда да шундый саклык чаралары күрелсә, бик шат булыр идем.

67 нче мәктәп бер сак оешмасы белән бу уку елына килешү төзегән. Безнең белән елмаепкөлеп сөйләшкән Марина ханым да шунда укып таныклык алган. Аңлашылганча, мондый эшкә бары махсус әзерлек узган кешеләрне генә алалар.

«ЯРДӘМ ИТЕГЕЗ!»

Чираттагы тәҗрибә Авиатөзелеш районында булды – 37 нче гимназия. Нәкъ метро янында ул. Әлеге белем йорты игътибарны ни өчен җәлеп итте: биредә дә мәктәп койма белән тотып алынмаган. Инде өйрәнелгән тәртип буенча Александр төймәгә басты. Ишекне сакчы ир ачты. Кемнәр икәнебезне аңлаткач, ул да директорга шалтыратты. Директорны көткән арада сакчы белән сүз алыштык:

– Ә ни өчен сезнең мәктәпнең кырыйлары тотылмаган?

– И, аңа үзебез дә борчылабыз. Инде бу турыда телевидениедән килеп тә төшерделәр. Мең сәбәп табылып тора. Бәлки, сез ярдәм итәрсез?!

Ул да түгел, мәктәп директоры Спиридонова Людмила Вячеславовна чыкты. Ни өчен килгәнебезне аңлатуга:

– Бернинди комментарий да бирмим! – дип кырт кисте һәм ишекне ябып куйды.

Гаҗәп, янә шундый мөнәсәбәт: проблеманы әйтергә курку. Иң кызганычы – чирне яшереп дәваланып булмый бит.

«КУРЫКМЫЙБЫЗ БЕЗ!»

Берәр заманча белем үзәгенә барып карыйсы килде. Шуның өчен дә мактаулы «Адымнар» мәктәбен сайладык. Заманча мәктәптә иң яхшы саклык чаралары күреләдер кебек тоелды. Ә юк, ялгышканбыз!

«Адымнар» мәктәбенең мәйданы бик зур, бөтен яклап тотып алынган ул. Керә торган төп ишектә пыяладан эшләнгән заманча сак бүлмәсе бар. Шунда ук керү-чыгуны контрольдә тоту һәм идарә итү системасы (СКУД) куелган. Ни хикмәт: без аның аркылы бик җиңел уздык. Берәү дә безне туктатмады, дөресрәге, анда кеше күрмәдек. Инде мәктәпнең зур ишегалды буйлап атлый торгач, төп керү ишеген таптык. Гаҗәп, моннан да бик җиңел генә эчкә уздык, ишекләр бикле түгел иде. Мәктәп эчендә безне ике сакчы ир-ат каршы алды. Алардан директорны сорадык. «Кыска вакытлы ялда», – диде ирләрнең берсе. Директор урынбасарының да мәктәптә юклыгын әйттеләр.

Кыскасы, мәктәп администрациясе белән сөйләшеп булмады. Аның каравы, әти-әниләр белән аралашып алдык. Икешәр сак системасы аша мәктәпкә шулай җиңел генә кереп булуын алар да раслады.

– Ә сезне бу борчымыймы? – дигәч, тыныч булуларын әйттеләр.

– Монда бөтен җирдә камералар, сакчылар эчке якта күзәтеп тора бит, – диде әниләрнең берсе.

Ханымнарның оптимист булулары бик әйбәт, әлбәттә. Ләкин «Адымнар» кебек зур мәктәптә саклык чараларына бүтән караш булырга тиеш кебек. Монысы инде директор колагына.



Авиатөзелеш районының 37 нче мәктәбе дә койма белән тотып алынмаган.

«Адымнар» мәктәбенең мәйданы бик зур, бөтен яклап тотып алынган. Ни хикмәт: эчкә бик җиңел уздык.

«ДИРЕКТОР ҖАВАП БИРӘ»

Казан мәктәбендәге фаҗигадән соң барлык белем йортларында сак системасы булдыру турында сүз чыкты. Татарстанда гына түгел, ә бөтен Россия буенча. Тик моның өчен мәктәп бюджетында акча каралмаганлыгы ачыкланды. Шулвакыт күп кенә ата-ана каравылчы өчен үзләре түләргә әзер булуны әйтте. Бәхеткә, бу эшне дәүләт үз җилкәсенә алды. Нәтиҗәдә, мәктәпләрне койма белән тотып алу, каравылчы хезмәте, керү-чыгуны контрольдә тоту һәм идарә итү системасы (СКУД) урнаштыру – барысы өчен дә акча республика бюджетыннан күчерелә. Бу эшнең ничек оештырылуы турында шактый еллар башкаланың бер мәктәбендә директор булып эшләүче яхшы бер танышымнан сораштым. (Аерым сәбәпләр аркасында, аның исем-фамилиясен язмыйм).

– Мин эшләгән мәктәп койма белән 2005 елда ук тотып алынган булган, – диде ул. – Быел аның алгы ягын яңадан ясаттык. Норма буенча мәктәп рәшәткәләре 1700 сантиметрдан ким булмаска тиеш, ә безнең 1500 сантиметр гына иде. Киләсе елга ян-як һәм арткы якны тотасы була. Мәгълүм булганча, һәр мәктәпнең куркынычсызлык паспорты бар. Уку елы башында Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре килеп, шул паспортны тикшерә. Безгә нәкъ менә койманың биеклеге буенча сорау булды. Яңа елга кадәр барлык мәктәпләрнең тирәсе тотып алынган булырга тиеш. Һәрхәлдә, ЭЭМ хезмәткәрләре бездән шуны таләп итә.

Танышым җитәкләгән мәктәптә койма республика бюджетыннан күчкән акчага яңартылган. Ләкин директор яшерми, моның өчен шактый документ артыннан йөргән ул.

– Ничек уйлыйсың, бүген мәктәпләр куркынычсызлык таләпләренә тулысынча җавап бирәме? – дим.

– Җавап бирә. Сакчы, иртәнге җиде тулып киткәч, балаларны урам як ишегенә чыгып каршы ала, дәрес башлангач, эчке якка кереп күзәтә. Сакчыдан тыш, мәктәпләрдә вахтер да бар, ул да күз-колак булып тора. Вахтерларга хезмәт хакы мәктәп бюджетыннан түләнә. Ә сакчылар белән аерым исәп, ул безнең бюджетка карамый. Дөрес, сак оешмалары белән килешүне директор үзе төзи. Әле каравылчыны табу бик җиңел түгел, мәктәптә эшләргә лицензияләре булырга тиеш. Ә ул бөтен каравылчыларда да булмый. Дөресен генә әйткәндә, балаларның куркынычсызлыгы бүген төп проблемаларның берсе. Бер-бер хәл булса, директор җавап бирә бит. Шуның өчен дә һәр мәктәп директоры әлеге мәсьәләгә бик җаваплы карый, дип уйлыйм.

Ләкин моның икенче ягы бар – кеше факторы. Теге яки бу ситуациядә үзен ничек тотасын берәү дә төгәл генә әйтә алмый. Яман ниятле кеше балаларны урамда да саклап тора ала. Дәрес беткәч, берьюлы дистәләгән укучы кайтырга чыга. Андый олы фаҗигаләрне күрергә язмасын инде...

КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫККА – 1,4 МЛРД СУМ

Бүген Татарстанда 3 317 белем бирү оешмасы исәпләнә. 3 647 белем бирү объектында (бу санга мәктәп филиаллары да кергән) куркынычсызлык паспортлары булдырылган. РФ Хөкүмәтенең 2019 елның 2 августында кабул ителгән карары нигезендә бөтен белем бирү оешмаларының андый документы булырга тиеш.

Кызганыч ки, хәзерге вакытта мәгариф оешмаларын террорчылыкка каршы техник системалар белән тәэмин итү буенча аерым бер программа юк. Нигездә ул Татарстан Республикасы мәгариф оешмалары биналарын капиталь ремонтлау буенча республика программасы кысаларында гамәлгә ашырыла. Шулай ук аерым йөкләмәләр һәм бюджеттан тыш финанслау, республика муниципаль берәмлекләре бюджетлары хисабына да эшләнә. Бу программа муниципаль берәмлекләр тәкъдимнәре буенча формалаштырыла. Анда конкрет мәктәпнең исеме, эш төрләре күрсәтелә. Мисал өчен, 2022 елда Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларын капиталь ремонтлау республика программасы кысаларында 18 дәүләт мәгариф оешмасы саклану җиһазлары белән тәэмин ителгән. Барлыгы 65 979 000 сумлык эш башкарылган.

Тагын бер сан: ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов карары белән, 2022 елда мәгариф учреждениеләрен саклауга 1,4 млрд сум акча бүлеп бирелгән. Монда махсус сак бүлмәләрен җиһазландыру, куркынычсызлык төймәсен булдыру, гадәттән тыш хәлләрдә сигнал бирә торган тавыш көчәйткеч җайланмасын урнаштыру, керү-чыгуны контрольдә тоту һәм идарә итү системасы (СКУД) сатып алу, сак хезмәтенә түләү – барысы да кергән.

– Саклану җиһазларына сорау елдан-ел арта, – диде танылган бер сак оешмасы җитәкчесе Алексей Фоминых. – Мисал өчен, пандемия вакытында керү-чыгуны контрольдә тоту һәм идарә итү системасының тән температурасын үлчи торганына сорау арткан иде. Ягъни кулланучыны, корал, металлны тану-сизү белән беррәттән, башка функцияләр дә кызыксындыра. Хәтта бүген бактерияләрне юк итә торган контроль идарә системалары да эшлибез. Шулай ук кечкенә мәктәпләр (нигездә авыл җирләрендә) кул белән тикшерә торган металл эзләгечкә заказ бирә. Аның бәясе кыйммәт түгел – 5 мең сум тирәсе.

...Мәктәпкә бүген теләсә кем кереп йөри алмый – шунысы сөендерә. Һәрхәлдә, күбесенә дип әйтик. Бүген күрелгән саклык чаралары 175 нче мәктәптәге кебек олы фаҗигане булдырмаска ярдәм итәр, дип ихластан өметләнәм.

Ә безнең белән аралашырга теләмәгән мәктәп директорларының әйтер сүзе бар икән, редакция бу теманы дәвам итәргә әзер.

Куркынычсызлык чараларына күпме акча тотылган:

КАЗАН:

1 000 046 000 сум
койма, капкалар ясау, төзекләндерү

58 253 000 сум
контроль-тикшерү постлары урнаштыру

39 775 000 сум
бинаның беренче катында видеокүзәтү системасын булдыру

ЧИСТАЙ:

10 000 000 сум
видеокүзәтү системасын булдыру, контроль-тикшерү постлары урнаштыру, койма тоту, тышкы яктырткычлар кую, металл эзләгечләр сатып алу

ӘЛКИ РАЙОНЫ:

894 000 сум
гадәттән тыш хәлләрдә сигнал бирә торган тавыш көчәйткеч җайланма урнаштыру

ӘТНӘ РАЙОНЫ:

1 150 000 сум
видеокүзәтү системасын булдыру, домофоннар кую, койма тоту, периметр буенча яктырту

ЮГАРЫ ОСЛАН РАЙОНЫ:

3 565 000 сум
койма тоту, куркынычсызлык төймәсен монтажлау

ЯҢА ЧИШМӘ РАЙОНЫ:

360 000 сум
тышкы яктырткычларны монтажлау

САРМАН РАЙОНЫ:

360 000 сум
видеокүзәтү системасын булдыру

ЧИРМЕШӘН РАЙОНЫ:

1 173 000 сум
видеокүзәтү системасын булдыру, контроль-тикшерү постлары урнаштыру, металл эзләгечләр сатып алу

СПАС РАЙОНЫ:

5 500 000 сум
сак сигналын монтажлау, сак контролен булдыру

ПИТРӘЧ РАЙОНЫ:

3 754 000 сум
гадәттән тыш хәлләрдә сигнал бирә торган тавыш көчәйткеч җайланма урнаштыру, видеокүзәтү системасын булдыру

АЛАБУГА РАЙОНЫ:

508 000 сум
гадәттән тыш хәлләрдә сигнал бирә торган тавыш көчәйткеч җайланма урнаштыру, коймаларны төзекләндерү

ӘТНӘ РАЙОНЫ:

661 000 сум
видеокүзәтү системасын булдыру, тышкы яктырткычлар кую, койма тоту

НУРЛАТ РАЙОНЫ:

2 055 000 сум
куркынычсызлык төймәсен урнаштыру, койма тоту, видеокүзәтү системасын булдыру

ТР ПРЕЗИДЕНТЫ РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ КАРАРЫ БЕЛӘН, **2022 ЕЛДА МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕН САКЛАУГА 1,4 МЛРД СУМ АКЧА БҮЛЕП БИРЕЛГӘН**.

PRESSA

ИМИНЛЕК – МӘКТӘП «КЫСА»СЫНДА

«Метаскан» металл детекторларына «капка» аша күпме укучы узуыннан бигрәк, малай-кызларның күпме металл әйбер алып керүе мөһим.



52 смартфон, 48 ачкыч бәйләме, 27 каеш аелы, 18 тимер төймә, 17 алтын һәм көмеш чылбыр һәм беләзек, 12 акча янчыгы каптырмасы, 7 җиң каптырмасы, төрле номиналдагы берничә дистә тәңкә акча, электрон конструктор платасы, лазерлы указка, тимер линейка – Казанның бер мәктәбендә иртә белән беренче 50 кеше узганнан соң, рамка «эләктереп калган» әйберләр исемлеге менә шундый. Бу предметлар куркынычсызлык хезмәткәренең мониторында күренә. Детектор билгеле бер авырлык һәм күләмдәге предметны, аерым бер металл төрен күреп алганда, хәвеф сигналы яңгырый. Кирәк булмаганда, тавыш куптармый ул – гел чыелдап тормасын өчен сүндереп кую теләге уянырга сәбәп юк.

«Метаскан»ның аркалы детекторлары ил күләмендә меңләгән мәктәп, балалар бакчалары, югары уку йортлары һәм башка иҗтимагый учреждениеләр өчен иң беренче итеп сайлап алына торган технологиягә әйләнде. Аларның мондый карары «Метаскан» кысаларының төп өч сыйфатына бәйле. Әнә шул үзенчәлекләр нәтиҗәсендә әлеге кысалар балаларның куркынычсызлыгын тәэмин итү аеруча мөһим булган учреждениеләргә урнаштыру өчен кирәкле таләпләргә максималь туры килә.

Беренче сыйфаты – ГОСТ таләпләреннән дә югарырак төгәллек. Сканерлар металл предметның авырлыгын, аның урынын (куртка яки чалбар кесәсе, рюкзак) һәм металлның төрен (кара яки төсле металл) таный. Җайланманың операторы предметларның сурәтен мониторда да күрә. Шул рәвешле, бинага керүчене машина да, кеше дә тикшерә.

Икенче сыйфаты – кыса аша берьюлы узган ун кешедән шик уяткан предметның кемдә булуын детектор тарафыннан ачыклану сәләте.

Өченчесе – җайланманың абсолют куркынычсызлыгы. «Метаскан» кысалары нибары 100 мкВт, ягъни тиңдәшләреннән 30 тапкыр кимрәк электр энергиясе куллана. Аларның электромагнит нурланышы табигый фон белән тиңләшерлек дәрәҗәдә. Өстәвенә, бу детекторлар вандалларга каршы чыдам, алар кыска ялганыш аркасында янып китүдән һәм башка көтелмәгән хәлләрдән сакланган.

– Безнең шундый заказчыларыбыз (шул исәптән югары уку йортлары да) бар, аларга металл детекторы белән бәйле системаның бинага керүчене тышкы кыяфәтеннән танып, аны базага кертелгән фото белән чагыштыра белүе һәм әлеге базада булмаган кешенең узып китүен күрсәтүе мөһим. Зур учреждениеләрдә кысалар һәм видеокүзәтү камералары бердәм челтәргә тоташтырыла, ә система хәвеф сигналы тышкы сак пультына килерлек итеп көйләнә, – ди «Метаскан»ның баш конструкторы, Идел буе дәүләт технология университеты (Мари Эл) доценты Алексей Фоминых. – Шулай итеп, бер-берсе белән бәйләнгән берничә куркынычсызлык контуры булдырырга мөмкин. Аларның эчкесе – күзәтү камераларыннан һәм кысалардан, ә тышкысы полиция хезмәткәрләре карый торган шәһәрнең тышкы күзәтү камераларыннан гыйбарәт. Мондый контрольнең барлыгы инде үзе үк әһәмиятле профилактик чара булып тора.

«Метаскан»ның тәкъдимнәре, бик күп инновацияләрне колачлавына карамастан, импортны алыштыру тенденциясе таләпләренә туры килә. Предприятиенең киң ассортименттагы аркалы һәм грунт металл детекторларының барлык төрләре, ким дигәндә, 70% ка үз илебездә җитештерелгән детальләрдән тора һәм Татарстанда җыела. Компаниянең үзе эшләгән инженерлык яңалыклары да бихисап. Шуңа күрә «Метаскан» детекторларны шәхси заказ буенча ясый ала. Һәм шул рәвешле универсаль иминлекне тәэмин итәргә сәләтле.

METASCAN
metascan-md.com
тел. 8 800 444-00-27
info@metascan-md.com
grunt. metascan-md.com

Фотолар «Метаскан» компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА

ИЛСУР ҖИҺАНШИННЫҢ «ПЕДАГОГИК ПОЭМА»СЫ

Казанның 2 нче интернат-лицееның җәмгыять белеме укытучысы, «Ел укытучысы-2022» Бөтенроссия конкурсы лауреаты Илсур Җиһаншин укучыларны яклау, ата-аналар белән футбол уйнауның мөһимлеге һәм начар мөгаллимне яхшыга әйләндерү серләре турында сөйли.

БӘХЕТЛЕ ОЧРАК

– Мин очраклы рәвештә генә укытучы булып киттем, дип әйтергә була. Һәрвакыт хокук саклау органнарында эшләү турында хыялландым һәм хәтта юридик белем дә алдым, әмма үзем тәмамлаган лицейга чакыргач, укытучы булып эшләп карадым. Миңа ошап китте. Профильле белемне соңрак алдым. Хәзер исә үземне башка һөнәрдә күз алдына да китерә алмыйм.

«АНА ИНСТИНКТЫ»

Кайчандыр бер дустым миңа, «ана инстинктың» түбән булганга, синнән яхшы укытучы чыкты, диде. Мин башта аңламадым һәм хәтта бераз үпкәләдем дә: ничек инде түбән? Чыннан да, укытучылар арасында балаларга карата «ана инстинкты» бик көчле булган хатын-кызлар күбрәк – алар сабыйларны кайгырта, яклый, өйрәтә, ярата. Еллар үткәч, миндә дә әлеге инстинкт бик көчәйде – үземнең укучыларымны бик яратам. Аларны барысына да өйрәтергә, һәрвакыт якларга әзер – үз балаларын яклау да мөгаллимнең вазыйфасы бит! Мин үземнең укучыларым белән горурланам – алар шундый төрле, әмма алар барысы да искиткеч!

АТА-АНАНЫ САЙЛАП АЛМЫЙЛАР

Миңа бәхет елмайды – шундый мәктәпкә килеп эләктем ки, биредә администрация үз укытучыларын кәгазь волокитасыннан һәм укучыларның әти-әниләре белән чамасыз аралашудан сакларга тырыша. Лицейда ата-аналар өчен төрле чаралар оештырыла: футбол уйныйбыз, төрле походларга йөрибез, әмма көндез дә, төнлә дә төрле чатларда интектерүләр яисә дәресләрдән соң каравыллап торулар бездә юк. Бездә хәтта ата-аналар җыелышлары да шул рәвешле уздырыла – һәр укучыга биш минут бүленә, шул вакыт эчендә аның әти-әнисенә бала турында бөтен кирәкле мәгълүмат җиткерелә. Шулай ук без, укытучылар, уку елы дәвамында бер тапкыр укучының өендә кунакта булырга, аның нинди шартларда яшәве белән танышырга, аңа нинди ярдәм кирәклеген белешергә тиеш.

КЕЧКЕНӘ МӘКТӘПЛӘР ТУРЫНДА ХЫЯЛЛАНАМ

Һәр кешенең һөнәри бер хыялы бар. Минеке өлешчә тормышка ашты. Мин һәрвакыт кечкенә мәктәп турында хыялландым – анда күп дигәндә 700–800 бала укысын иде. Мәктәп зуррак булган саен, анда уңайлылык, укучы белән укытучы арасындагы мөнәсәбәтләрдәге җылылык, укучыга күбрәк игътибар бирү мөмкинлеге азая бара. Сыйныфларда балалар саны аз булсын, дип хыялландым – бу очракта аларга белем бирү нәтиҗәлерәк. Безнең лицей нәкъ менә шундый да. Минем хыялымда барлык мәктәпләр дә шундый булырга тиеш. Карьерага килгәндә исә... Мин аны ниндидер административ үрләрне буйсындыруда күрмим. Минеке түгел ул. **Миңа үземнең белем һәм күнекмәләремне укучыларыма тапшыру, балалар кызыксынырлык итеп укыту күбрәк ошый. Кемнедер рухландырудан һәм илһамлануга өйрәтүдән мин үзем дә ләззәт алам.**

НАЧАР УКЫТУЧЫ ЮК, ЧАМАСЫЗ ЙӨКЛӘМӘЛӘР ГЕНӘ БАР

Яхшы укытучы һәм начар укытучы... Әйе, шулай да була. Кайвакыт әлеге һөнәргә кеше ялгыш килеп эләгә. Яисә ул эшкә формаль карый – тиешле сәгатьләрен тиз генә

Фото: Илсур Җиһаншин архивыннан; «Педагогик поэма» фильмыннан кадр, 1955 ел.

укыта да өенә ашыга. Минемчә, күпчелек очракта бу эшнең чамадан артык булуыннан килә, ул укытучыдагы төп мөгаллимлек асылын юкка чыгара. Бер ярым-ике ставкалык сәгатьләр саны бер яктан яхшы кебек, акчасы күбрәк була. Әмма син арып-талганчы эшлисең икән (ә кеше организмы яшәрә бармый, ул ял таләп итә, артык күп эштән ул арый), белем бирү сыйфатына һичшиксез зыян килә. Шунлыктан күп кешедә үз-үзен сакларга омтылыш беренче планга чыга.

Макаренконың «Педагогик поэма»сын укыгыз. Ул чакта заман да, балалар да бүгенгедән катлаулырак булган. Аның да барысы да шундук барып чыкмаган. Әмма уйлап карасак, балалар белән түгел, бәлки нәкъ менә административ яктан – тикшерүче оешмалар, алар таләп иткән хисаплар, стандартлар нәтиҗәсендә проблема килеп чыккан бит... Ә балаларны бернинди стандартлар кысаларына да куып кертеп булмый. **Мөгаллим өйрәтергә, кызыксындырырга, үз фәне белән яшәтергә тиеш. Һәм үз фәне белән генә дә түгел, укуга дәрте белән дә. Мәктәп администрациясе исә булышырга тиеш. Шулчакта балаларга да кызык булачак, безнең дә барысы да майлагандай барачак.**

« БӨТЕН НӘРСӘ ТӘРБИЯЛИ: КЕШЕЛӘР, ӘЙБЕРЛӘР, КҮРЕНЕШЛӘР, ӘММА ИҢ ӘҮВӘЛ ҺӘМ БАРЫННАН ДА ОЗАГРАК – КЕШЕЛӘР. АЛАР АРАСЫНДА БЕРЕНЧЕ УРЫНДА – АТА-АНА ҺӘМ ПЕДАГОГЛАР.

Антон Макаренко, «Педагогик поэма», 1935 ел.

МӘХӘББӘТКӘ ӘЙЛӘНГӘН НӘФРӘТ

Казандагы 83 нче лицейның башлангыч мәктәп укытучысы Лидия Вафина үзен укыткан мөгаллимнәргә «үче» һәм куралмаган математиканы ничек ярата башлавы турында сөйли.

ЯРАТМЫЙЧА САЙЛАНГАН ҺӨНӘР

Укытучы һөнәрен мин очраклы гына сайлап алдым. Үзем укыган мәктәп турында бик начар хатирәләр генә калды. Мин аны куралмый идем. Укырга да, укытучыларын да яратмадым, бигрәк тә математика үзәгемә үтте. Хәзер мин аның нигә шулай булуын аңлыйм инде дә бит – чөнки беренче сыйныфта мин Вальдорф мәктәбендә укыган идем. Бер елдан соң аны яптылар һәм безне төрле мәктәпләргә тараттылар. Мин эләккән мәктәп исә беренчесеннән бик нык аерыла: программасы да башка, укытучылары да, балаларга мөнәсәбәт тә бөтенләй икенче.

ХУРЛЫК ДӘФТӘРЕ

Миңа икеләләр ява башлады. «Әйдәгез әле, Вафинаны тыңлап карыйк һәм рәхәтләнеп бер көлеп алыйк!» – дип, нигәдер мине түбәнсетергә тырышкан укытучыны һаман оныта алмыйм. Кайбер педагоглар исә әлеге икеләләрне дәфтәр тышына ук тезеп куюдан аерым бер ләззәт таба иде – янәсе, хурлык дәфтәрен бөтен кеше әллә кайдан ук күреп торсын! Нинди тәрбия ысулы булган соң бу?! Әниемнең, Макаренконың «Педагогик поэма»сын култык астына кыстырып, мәктәпкә йөгереп килүләрен дә хәтерлим. Шул рәвешле педагогларның хаксызлыгын аңлатырга тырышкан әниемә алар исә чираттагы көйсез баланың аны өзелеп яраткан көйсез әнисенә караган кебек кенә карый иде...

Һәм, әлбәттә инде, үзем һич аңламый интеккән математиканы куркыныч төш кебек исемә төшерәм.

РЕПЕТИТОРГА РӘХМӘТ

Бервакыт математика буенча репетитор минем башыма ничек тә белем кертә алмый гаҗиз калудандыр инде: **«Әгәр син кайчан да булса укытучы булырга ниятләсәң һәм минем оныкларым син эшләгән мәктәпкә укырга керсә, мин аларны анда бер генә көн дә укытмаячакмын!»** – диде.

Бу репетиторга рәхмәт! Чөнки нәкъ шул мизгелдә минем бик каты ачуым чыкты – үземне аңгырага санаган укытучыларымның хаксыз булуларын дәлилләү өчен башымда алардан үч алу теләге уянды. «Мин укытучы булам, – дигән карарга килдем мин. – Һәм сезнең «үчне» оныкларыгыздан алачакмын!» Үч исә салкын килеш бирелә торган тәгам, шунлыктан мин аны әйбәтләп әзерләргә керештем.

ХЫЯЛДАГЫ ЭШ

Педколледжга укырга кердем, һәм анда уку миңа бик ошады, бигрәк тә мин практикадан, балалар белән аралашудан канәгать калдым. Һәм менә хәзер мин лицейда эшлим – бу нәкъ мин хыялланган эш булып чыкты! Читтән торып университетта укыйм. Минем укучыларым хәзер инде өченче сыйныфта. Мин аларның барысын да (25 әү алар миндә!) бик яратам, алар да мине үз итә. Алар яхшы укый, барысы да шундый үзенчәлекле, ихлас, һәркайсы белән гел нindидер күңелне кузгатырлык вакыйгалар булып тора – мин шуларны язып барам, киләчәктә бер китапка туплап, мәктәпне тәмамлаган чакта үзләренә балачак хатирәсе сыйфатында бүләк итәргә ниятлим. Алар бишенче сыйныфка күчкәндә, ничек аерылышачагыбызны әлегә күз алдыма да китерә

Фото Лидия Вафина архивыннан



алмыйм! Укучыларым сорый инде: «Ә сез безнең белән бишенче сыйныфка да барасызмы?» – диләр. Мин шаяртам: «Бишенче сыйныф математикасын гына әзрәк өйрәнәсем калды – аннары мин дә көчәрмен!» – дим.

ФӘНГӘ МӘХӘББӘТ

Җитди итеп әйткәндә исә, сыйныфыбызда математика белән проблемалар юк. Олимпиадаларда катнашабыз һәм призлы урыннар яулыйбыз. Мин математиканы бик яхшы беләм икән ләбаса. Балалар аңларлык итеп төшендерә дә алам. Бу инде колледжда ук ачыкланган иде, чөнки анда безгә бик төпле белем бирделәр.

Балада фәнгә мәхәббәт мөгаллимне ярату, әлеге предмет белән кызыксыну аша тәрбияләнүне аңлар өчен маңгайның җиде карыш булуы таләп ителми. Укытучының дәфтәр тышына ачу белән зур итеп ясап куйган икелеләре, кайбер укучыларны бөтен сыйныф алдында мәсхәрәләү исә укуга нәфрәт кенә тудырырга мөмкин.

ЙӨРӘККӘ ЯКЫН ПАРЧАЛАР

Күптән түгел генә сыйныфыбызда бер малай бер кызга гашыйк булды. Һәм беркөнне тәнәфестә әлеге кызчыкка өлкән сыйныфта укучы бер малай ялгыш кына килеп бәрелгән. Гашыйк малай, үпкәләтүченең килеш-килбәте нинди булуын гына сорап, шундук аны эзләп тә киткән.

– Ак күлмәк, зәңгәр чалбар кигән иде, – дип аңлаткан кыз.

Мәктәптә кирәкле кешене әлеге «эксклюзив» билгеләр буенча гына тану мөмкин түгелдер кебек. Әмма безнең герой тапкан:

– Шуңа охшаш кыяфәтле берничә кешене таптым да барысын да кисәттем, – ди.

– Нәрсә белән куркыттың соң үзләрен? – дип сорыйм.

– Нәрсә белән түгел, кем белән, диегез! Әлбәттә инде, Лидия Фәнисовна белән! – ди.

БАЛА КЕМГӘ ЫШАНА: УКЫТУЧЫГАМЫ, БЛОГЕРГАМЫ?

Халык мәгарифе һәм фән хезмәткәрләре һөнәр берлегенең Татарстан Республикасындагы комитеты рәисе Юрий Прохоров гаилә белән мәктәпнең үзара элемтәсенә ни комачаулавы турында фикер йөртә.

ЧАГЫШТЫРУЫ КЫЕН

Элекке һәм хәзерге мәгариф системасын чагыштыру бик авыр, асылда, мөмкин түгел диярлек, чөнки сүз ике чор, ике төрле дәүләт, ике төрле строй турында бара. СССРда мәгариф дәүләт сәясәтенең бер өлеше иде. Ата-аналар, балалар һәм укытучылар арасында бердәмлек, үзара ярдәм, бәйләнеш тә әлеге сәясәтнең бер өлеше булды. Бу өчлек дус-тату эшләде. Һәр мәктәп уку-укыту гына түгел, тәрбия белән дә шөгыльләнде. Ә тәрбия әнә шул бәйләнешне күз уңында тота да. Шуңа күрә, мөгаен, элек мәктәпкә һәм укытучыга ышаныч та, хөрмәт тә зуррак булгандыр, дип уйлыйм.

ПЕДАГОГ ХЕЗМӘТЧЕ ТҮГЕЛ!

Ә хәзер акча идеологиясе хөкем сөрә. Анда мәгарифне хезмәт күрсәтү өлкәсе дип игълан иттеләр, һәм ата-аналар белән балалар мәктәпне дә, педагогларны да хезмәтче сыйфатында кабул итә башлады. Быел законнардан «мәгариф хезмәте күрсәтү» төшенчәсе алынды, әмма бу тармакка инде зыян салынган һәм аны төзәтү җиңел булмаячак.

Яшь педагогларның бүген мәктәпкә барырга атлыгып тормавының сәбәбе нәкъ менә укытучыга карата мөнәсәбәт белән бәйле булуына иманым камил. Мәктәптән яшьтәшләрем һәм бездән соң килгән буын педагоглар киткәч, нәрсә булачак? Кадрлар каян килсен ул?

ТӘРБИЯ УРЫНЫНА – ИНТЕРНЕТ

Әйе, төрле ысуллар сынап карала, мәсәлән, төрле юнәлештәге оешмалар булдырыла. Ләкин алар ниндидер уртак максат белән берләштерелгәнме? Пионерия һәм комсомол эше баланы киләчәктә җәмгыятьнең җаваплы әгъзасы булырлык итеп тәрбияләүгә һәм әхлакый үстерүгә юнәлдерелгән иде. Бүгенге мәктәп балалары һәм яшьләр оешмалары бу бурычны хәл итә аламы? Ярый, мәктәп әхлакый тәрбия функциясенә яңадан җиң сызганып кереште, ди. Көндез без тере каһарманнар, әдәби геройлар, фән, сәнгать эшлеклеләре мисалында идеаллар турында сөйләшәбез. Кич белән бала өйгә кайтып, телевизорны кабызуга, шоу һәм сериалларда болар барысы да бик тиз кире кагыла. Аннары ул интернетка керә. Бала кемгә күбрәк ышана: педагогларгамы, әллә блогерларгамы?

АТА-АНАЛАР, СЕЗ КАЙДА?

Мәктәп бүген күп эшли, ләкин, кызганыч ки, ул эш-гамәлләрнең кыйммәте бердәм максат булмау аркасында бетерелә. Бүген бездә, мәсәлән, ата-аналар белән сыйныф җитәкчесен бик зур упкын аерып тора. Мессенджерларда язышу гына күзгә-күз сөйләшүне алыштыра алмаячагына ышанам. Бу үзара элемтә түгел, ә ниндидер рәсми хәбәрләшү, инструктаж, мәгълүмат җиткерү генә. Мин мәктәп директоры булып эшләгәндә, ата-аналар җыелышын айга бер тапкыр үткәрә идек. Малайларның – этиләре, кызларның әниләре килә иде. Бездә ике берләшмә бар иде: берсе – әниләрнеке, икенчесе – этиләрнеке. Чөнки алар бер-берсеннән аерылып тора, хәл итә торган проблемалары да төрле. Хәтта этиләр комитеты да оештырылды, күп ата-ана бер үк предприятиедә эшли иде. Әгәр укучы гел тәртип боза икән, комитет башлыгы аның этисе янына цехка бара һәм, мәгълүмат төгәл, дөрес барып җитсен өчен, шунда җыелыш уздыра. Шулай итеп, ата-ана буларак, һәркемдә үз баласы өчен һәм үз эш-гамәлләре өчен җаваплылык хисе формалаштырылды. Бүген сез мондый нәрсәне күз алдына китерә аласызмы? Юк. Бүген сез, эти-әниләр, мәктәпкә болай гына керә дә алмыйсыз, сакчы туктатачак.

Фото Юрий Прохоров архивыннан алынды

КҮҢЕЛГӘ ЯКЫННЫ ХӨРМӘТЛИБЕЗ

Каллиграфия укытучысы Ксения Сенцова мөгаллим һәм укучы бер-берсен яхшырак аңлый алсын өчен нәрсәләр кирәк булуы турында сөйли.

Фото Ксения Сенцова архивыннан алынды

ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ ПЕДАГОГИК АЛЫМ

Бала үзенә кызык булганда өйрәнә, укый. Синең белән кызык икән, димәк, ул сине педагог буларак хөрмәт итә. Әмма син үзең укучыларыңны хөрмәт итмәсәң, тегесе дә, монысы да булмаячак. Һәрхәлдә, мәктәп елларыннан мин шуны истә калдырдым.

ФӘНГӘ – ӘЙЕ! ПЕДАГОГКА – ЮК...

Балалар күңеле бик сизгер, һәм алар олыларның үзләренә карата мөнәсәбәтен бик яхшы тоя. Үз предметын яхшы белүче укытучыбыз бар иде. Үз фәненә бәйле бик күп кызыклы нәрсәләр сөйли. Кайчагында мәктәп программасына кермәгән материаллар да бирә, әмма аның мондый чыгышлары бернičә кешегә генә атала иде – укытучы аларны гына үз игътибарына лаек дип санады. Без, ягъни калган барлык балалар, аның фикеренчә, укырга теләмәгән һәм гомумән укый белмәгән соры массаны тәшкил итә идек. Мин аның фәнен чын күңелдән ярата идем (һәм хәтта үз һөнәремне дә бу өлкә белән бәйләдем дип әйтергә була), ләкин укытучының үзен җенем сөймәде. Әлегә кадәр аңлый алмыйм: ник ул җиденче сыйныф укучылары алдында үзенең акыл ягыннан өстенлеген күрсәтүне нәтиҗәле педагогик алым дип санады икән?

ИҢ ЯХШЫ ӘҢГӘМӘДӘШЕМ

Аның каравы башка укытучыбызны без барыбыз да яраттык. Ул үзен һәрвакыт бик табигый тотты, әллә ни шаккатарлык чыгышлар ясамый, ялгышырга курыкмый иде, һәрберебезгә карата гел игътибарлы һәм дустанә мөнәсәбәттә булды. Беренче көннән үк булмаса да, без аны чын-чынлап хөрмәт иттек. Ул миңа тугызынчы сыйныфта әдәбият буенча дәүләт имтиханына әзерләнергә булышты. Шулчакта мин аңарда үзем өчен кызыклы темалар турында сөйләшергә әзер әңгәмәдәшне таптым. Онегинның Татьянага хаты, Тургеневта аталар һәм балалар конфликты – инде һәркем гарык бу «классик» сюжетлар минем өчен яңа яктан ачылды, чөнки укытучы әлеге темаларның асылын аңлата алды. Укытучыбыз декрет ялына киткәч, без дәресләрне аның өендә дәвам иттек, ә аннан соң ул минем иншаларымны бәби тудыру йорты янындагы эскәмиядә дә тикшерде әле. Өстәмә дәресләр өчен беркайчан да акча алмады, шуңа күрә мин аңа җиләк-җимеш һәм тәм-томнар алып килә идем. Аның тырышлыгы белән күпләребез рус теленнән БДИне яхшы язып чыкты, ә укытучы уеннар аша аңлаткан кагыйдәләрне мин әле дә хәтерлим.

СӘЙЛӘН БЕЛӘЗЕК – УҢЫШ УЛ

Хәзер үзем педагог булгач, укучыларның игътибарын җәлеп итеп, аларның дикъкатенә ирешергә тырышканда, укытучының нинди хисләр кичергәнен аңлыйм. Кайвакыт баланы кызыксындыру бик авыр (хәтта мөмкин дә түгел). Бу еш кына аның әлеге предметка мөнәсәбәтенә түгел, ә гомумән фикер-карашлары, балалар тормышында да еш күзәтелгән стрессларга бәйле. Кайбер алымнарны, әйтик, шул ук уен ысулын, мин классик педагогикадан алам, кайберләрен үзем уйлап табам. Тәртип өчен баллар системасы (асылда, теләсә кайсы балага таныш «лайк»лар), күнегү төрләрен мөмкин кадәр тиз, табигый агымга зыян салмыйча гына алыштырып тору һәм, әлбәттә, дустанә мөнәсәбәт – хәзер минем төп ярдәмчеләрем. Бер кыз белән без һәр дәрес ахырында сәйләннән беләзек (фенечка) һәм башка нәрсәләр үрәбез, шул вакытта ул миңа ял көннәренең ничек узуы, нинди фәннәрнең аңа авыр бирелүе, музыка мәктәбендә укуны бик ошатуы турында сөйли. Балаларга минем дәресләремдә уңайлы, рәхәт булуы күңелемә хуш килә, аларның уңышына куанам. Без берберебезне хөрмәт итәбез, дип уйлыйм.

БЕРДӘМ ФИКЕРГӘ КИЛИК

Ксения Кузнецова, укытучы

ОШАМЫЙ:

Ата-ана нәрсәнедер ачыкларга теләгәндә еш кына, сыйныф җитәкчесе янына килмичә, шундук директор яки завуч янына бара. Кайвакыт укытучы әлеге проблема турында берни белми, шул рәвешле ата-ана аны уңайсыз хәлгә куя.

Тагын әле ата-аналарның күпчелеге балаларын мөстәкыйльлеккә өйрәтми. 5–6 сыйныфта да баланың портфелен үзләре тутыра. «Дәфтәрең кайда?» - дип сорагач, бала: «Әни рюкзакка салырга оныткан», – дип җавап бирә.

Яисә билгеләрне чамадан тыш контрольдә тоталар. Ә бит билге – бик субъектив күрсәткеч ул. Бала үзләштергән белем исә теләсә кайсы билгедән дә мөһимрәк.

Кайберәүләре хәтта дүртле өчен ачулана. Әти-әнисе теләгән билгене алмаган укучыда истерика башлана, һәм бу бик начар. Балада перфекционизм тәрбияләргә кирәкми, ул тормышта комачаулаячак кына. Аны билгеләргә әллә ни игътибар итмәскә өйрәтергә кирәк.

ИДЕАЛЬ АТА-АНА:

Идеаль ата-ана – барыннан да бигрәк укучы һәм укытучы арасындагы үзара мөнәсәбәт булган укыту процессына тыкшынмыйча, балага дөрес юнәлеш бирүче ул. Бу, баланы мәктәпкә бирдең дә, аның турында уйламыйсың да, дигән сүз түгел. Балага ирек бирү, шулай ук җаваплылыкны үзенә алу мөмкинлеген тапшыру мөһим.

Әйе, балаларын Аллаһның кашка тәкәсе санаган ата-аналар да бар. Әлбәттә, без барыбыз да үз балаларыбызны яратабыз, әмма бу мәхәббәт аның сәләтләрен объектив бәяләү хисен томаламасын иде. Кайберәүләр кызы яки улына психологик ярдәм кирәклеген танырга теләми.

Ә бит иң мөһиме – үз баланңы башкалардан өстенрәк күреп, проблемалардан качарга тырышу түгел, бәлки аның өчен ничек яхшырак булуын уйлап гамәл кылу.

Укытучы ата-анага мөрәҗәгать итә икән, ул аларны гаепләргә омтылмый, бергәләп проблеманы хәл итәргә тырыша. Мәсәлән, укучы күчерергә ярата, ди. Моның сәбәбен ачыклау зарур: бәлки, ул аңламагандыр, бәлки, әзерләнергә өлгермәгәндер. Яисә ул дәрестә тәртип боза, ихтимал, ул үзенә күбрәк игътибар җәлеп итмәкче буладыр. Шунлыктан проблеманы хәл итү юлларын бергәләп эзләү мөһим.

«АТА-АНА – УКЫТУЧЫ» АРАСЫНДА ИДЕАЛЬ МӨНӘСӘБӘТ:

Баланы укуга илһамландырып, мөгаллим һәм ата-ана икесе бер фикердә булырга тиеш.

Ә ата-аналар исә үзләре еш кына педагогның абруен төшерә: «Укытучының башы яшь, шуңа үзе дә бернәрсә белми ул», – кебек сүзләр ычкындыргалый. Ата-ана укытучыга хөрмәт белән карарга өйрәтмәсә, нинди ихтирам турында сүз булуы мөмкин?

ЭЛЕК ҺӘМ ХӘЗЕР:

Элегрәк минем әти-әнием укытучыга шалтыратырга, бигрәк тә инде өй эше нинди булуын сорарга курка иде, моның башка килүе дә мөмкин түгел. Сыйныфташлардан сорашып белешәләр иде.

Хәзер исә укытучыга тәүлекнең теләсә кайсы вакытында шалтыратып, өй эшен сорау гадәти хәлгә әйләнде.

Болай булырга тиеш түгел. Укытучы да кеше, һәм аңа да ял кирәк.

УКЫТУЧЫ ФИКЕРЕ

Фото: Ксения Кузнецова һәм Резеда Җамалиева архивыннан

Үзара үпкәләшеп кенә мәсьәләне хәл итеп булмый. «Татарстан» укытучылар белән ата-аналар арасында иң еш очрый торган үпкә һәм аңлашылмаучанлыкларны туплады һәм аларны, ике як фикерен дә исәпкә алып, хәл итү юлларын табарга тырышты. Бу эштә безгә КМТТУ-КАИ Лицей - Инженерлык үзәгендәге Махсуслаштырылган фәнни уку үзәгенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы Ксения Кузнецова һәм 8 сыйныф укучысының әнисе Резеда Җамалиева ярдәм итте.

Резеда **Җамалиева**, 8 сыйныф укучысының әнисе

ОШАМЫЙ:

Күптән түгел генә шундый хәл булды: кызым рус теленнән йомгаклау контроль эшен (ВПР) начар язды. Укытучысы торгызып бастырган да аны бөтен класс алдында икеле капчыгы дип атаган. Кызым бик борчылды. Мин ул укытучыга түгел, сыйныф җитәкчесенә шалтыраттым һәм рус теле укытучысы белән сөйләшүен үтендем.

Бер очрактан соң мин уку процессына тыкшынмыйм. 3–4 сыйныфларда мин кызыма: «Синең тырышлыгың җитми», – дия идем. Ә ул күз яше аралаш: «Мин яхшы булырга бик тырышам, әмма бу мәктәп безнең бөтен мөнәсәбәтләрне боза», – диде.

Шулчакта мин хәттин ашуымны аңладым һәм: «Синең белемең – үзең өчен, ә менә үзем бирә алган бөтен нәрсәне – әхлакый, рухи кыйммәтләрне мин сиңа бирәчәкмен», – дидем. Ә уку эшләренә башка тыкшынмыйм.

ИДЕАЛЬ АТА-АНА:

Безнең мәктәптә кытай теле укытучысы бар, Лаоши исемле.

Ул гадел, балаларга һәрвакыт, сез күп нәрсәгә ирешәчәксез, һәркем үз сәләте һәм килачәге белән туа, ди, аларда үз көчләренә ышаныч тудыра.

Мин барлык педагогларның да шундый булуын теләр идем.

«АТА-АНА - УКЫТУЧЫ» АРАСЫНДА ИДЕАЛЬ МӨНӘСӘБӘТ:

Бала мәнфәгатьләре истә тотыла икән, димәк, идеаль. Билгеләр аркасында аның психикасын бозарга кирәкми. Аның мәктәптән башка да ниндидер спорт секцияләре, музыка түгәрәкләре һ.б. да бар бит әле. Мөгаллим һәм ата-ана тандемы беренче чиратта бала файдасына булырга тиеш.

Совет педагог-новаторының бер цитатасы белән тәмамлыйсым килә: «Минем ышануымча, педагогика бөтен кеше – укытучылар өчен дә, ата-аналар өчен дә фәнгә әйләнергә тиеш», – дигән ул.

ЭЛЕК ҺӘМ ХӘЗЕР:

Мин үзем совет мәктәбендә тәрбияләнгән кеше, һәм безнең өчен педагог һәрвакыт хаклы иде. Укытучыларның күрәләтә хаталарына юлыкканчы, мин шул фикеремдә тордым әле. Әмма педагогның хаксыз икәнен белгән очракта да хөрмәт барыбер сакланырга тиеш. Укытучы – укытучы инде ул. Әгәр ошамый икән, ачуланудан файда юк, башкасына алыштырсаң гына.

Соңгы елларда укытучыга мөнәсәбәт ничек үзгәрдеме? Һәрвакыт күзәтәм: укытучыны гел тикшерәләр – нинди ул, гаиләсе нинди, кайларга барырга ярата. Социаль челтәрләргә рәхмәт. Бөтен кеше бөтен нәрсәне белеп тора хәзер.

Аның үз тормышында ниләр эшләве миңа мөһим түгел, мине аның нинди педагог булуы һәм үз вазыйфасын ничек башкаруы гына кызыксындыра.

АТА-АНА ФИКЕРЕ

ГАИЛӘ ҺӘМ МӘКТӘП

TeamSoft компаниясе бизнес-тренеры Гүзәл Хисмәтуллина укытучылар, ата-аналар һәм балаларга «мәктәп өчпочмагында» ничек тату яшәү һәм бер-берсенә үз эшләрен башкарырга комачауламау турында сөйли.

БАЛАНЫ КОЧАРГА ТЕЛӘГӘНДӘ

– Дус кызымның улы белән сөйләшәм: «Ел ахырына әти белән әни бөтенләй бәйдән ычкына, «Ел азагы, ел азагы!» дип теңкәмә тияләр. Ул бит алар өчен – ел азагы, ә минем өчен бәлки ел тәмамланмыйдыр, барысы да башлана гынадыр әле!»

Беләсезме, бу сүзләреннән соң минем аны кочаклап аласым килде!

АТА-АНА БЕЛӘН УКЫТУЧЫ ДА – КЕШЕ БИТ

Мин бала чакта әти-әнием «Семья и школа» журналын алалар иде. Дөресен генә әйткәндә, аны күбрәк мин – мәктәптә укучы үсмер кыз укый идем. Анда үземне кызыксындырган сорауларга җавап табам, ә **иң мөһиме, кинәт кенә ата-ана һәм укытучының да кеше икәнен, аларның да безнең белән проблемалары булуын һәм шул хакта журналга хатлар язуларын ачыкладым.** Шул мизгелдән минем әти-әнигә һәм укытучыларга мөнәсәбәтем үзгәрде. Алар да кешегә әйләнде.

МӘКТӘП ӨЧПОЧМАГЫ

Гаилә һәм мәктәп: ата-ана – бала, ул үк укучы – укытучы.

Өчпочмак.

Өчәүләшеп дуслашып караганыгыз бармы?

Бик катлаулы, шунлыктан бик сирәк очракта гына булырга мөмкиндер.

Бөтенесе бер-берсеннән нәрсәдер өмет итә.

Уртадагысына иң кыены, аңа ике яклап басым ясыйлар.

Ә басым ясаганда без нишлибез?

Әлбәттә, каршы торабыз.

Алайса басачаклар.

Ә болай үзе барысы да бик гади булырга тиеш кебек: ата-ананың бурычы – ярату, укытучыныкы – укыту, баланыкы – үсү, рухи яктан җитлегү, чөнки ул физик яктан болай да үсәчәк, ә менә рухи яктан ничек җитлегүе күпчелек очракта ата-ана һәм укытучылар тудырган мохиткә бәйле.

АТА-АНАЛАР ЧАТЛАРЫ

Әмма үзеңә кадерле кешене ярату шатлыгы бөтен нәрсәне контрольдә тотарга тырышу аркасында юкка чыга.

Әти-әнигә бөтен нәрсәдән хәбәрдар булу кирәклеген искәрдегезме?

Нәкъ менә шуңа күрә ата-аналар чатларында активлык гаять зур да. **Барысы да нәрсәдер ачыклый, контрольдә тота һәм сөйли, кайчагында исә кичекмәстән чара күрүне таләп итә.**

Бервакыт дус кызым белән кафеда очраштык. Телефонга күз салмыйча гына, 40 минутлап каһвә эчтек. Шул арада телефонындагы ата-аналар чатына 116 хәбәр килгән.

– Укыма! – дим.

– Ничек инде укымыйсың? Берәр мөһим хәбәр булса!

Һәм менә шундый – мәгълүматка муеннан чумган ата-ана нинди яратуга сәләтле була алсын икән ул?

Әйе, тыныч әти-әни генә файдалы була ала.

Ә без онытабыз һәм контрольне һаман көчәйтәбез, борчылганнан борчыла барабыз.

Ярсыйбыз, аннары тынычланабыз – һәм барысы да яңадан башлана.

ГЕЛ ГАЕПЛЕЛӘР

Һәм әлбәттә инде, укытучылар. Үз һөнәрен яратучылар һәм бигүк үз итеп бетермәүчеләр. Арыганнар, бик сирәк кенә ял итүчеләр, интегүчеләр, һәрвакыт кемгә нәрсәдер тиешләр.

Фото: Ната Смирнова

Администрация таләп итә, ата-аналар таләп итә, балалар исә бөтенләй бәйдән ычкынган. Һәм алар ук барысына да гаепле. Алар да кеше.

Соңгы елларда укытучы һөнәренең дәрәҗәсе арттымы?
И-их. Укытучыга мөнәсәбәт үзгәрде. Һөнәргә мөнәсәбәт үзгәрде.
Кем алар яклы?
Аларга кем ярдәм итә ала?
Ата-аналар булышырга тиешләр кебек, чөнки максат бер бит. Тик юк. Максатлар бер, позицияләр төрле, һәм әлеге позицияләрдә һәркем кемгәдер нәрсәдер тиеш.

ЭМОЦИОНАЛЬ СИЗГЕРЛЕК

Без барыбыз да сабый идек.
Без барыбыз да үсеп җиттек.
Шулай булган һәм булачак та!

Әмма, үсеп җиткәч, без оныта башлыйбыз.
Һәм аннары безгә – әти-әниләргә, укытучыларга – үзебезнең кинәт үсеп җиткән балаларыбызны аңлау катлаулана.

Без эмоциональ сизгерлегебезне югалтабыз.
Беренче планга ярсу хисе чыга, һәм ул җавап итеп баланың да ачуын кузгатырга мөмкин.

НИШЛӘРГӘ?

Бер-береңне ишетергә, аңларга тырышырга.
Бернинди системага да карамастан...

Аерым бер ата-ана – бала/укучы – укытучы: барыбызның да бер көймәдә утыруын һәм 11 ел буе бергә йөзәргә туры киләчәген хәтердән чыгармау мөһим; һәм шул 11 ел буе без йә җаваплылыкны бүлешәбез, таләп итәбез һәм территория бүләбез яисә инде үзара килешәбез дә, **әти-әни – ярата, укытучы – укыта, бала исә – үсә, җитлегә. Һәм тагын бернәрсә. Бер-беребезгә ярдәм итәргә сүз бирик. Һәм үз эшебезне намус белән башкарырга тырышыйк.**

Һәм башкаларга үз эшен башкарырга комачауламаска вәгъдәләшик.

Иллюстрация: Фёдор Решетниковның «Опять двойка» картинасы

БӨТЕН МӘКТӘПЛӘР ДӘ ЯХШЫГА ӘЙЛӘНГӘЧ

Жанна Сарымсакова

Амбициоз отличник, ныклы ударник, өчлегә сөйрәлүче. Сүз укучылар турында түгел, мәктәпләр хакында бара. Алар, мәктәпләр, үзләренең укучылары кебек үк, гел үрнәк генә булмый. Ә хәзер күз алдына китерегез: иң начар мәктәпләрне иң яхшылар дәрәҗәсенә күтәргәч, җәмгыятебез нинди отышта калачак? Фантастика диярсезме?

Башта бер очрак турында. Лэйсэн Новикова* гаиләсе дүрт ел элек кечкенә генә шәһәрдән Казанга күченеп килә. Андагы гап-гади мәктәптә кыз яхшы билгеләренә укый. Ә башкаладагы абруйлы гимназиядә укый башлагач, беренче уку елында көчкә «канәгатьләнерлек» билгеләренә өлгерә. Укыту дәрәҗәсе кебек үк, таләпләр дә элеккеге мәктәбе белән чагыштырырлык булмый.

*Исем-фамилиясе үзгәртелгән

Күпме күз яше һәм өстәмә дәресләр... – моны бары тик ул үзе һәм әнисе генә белә. Хәзер инде, өч ел узганнан соң, Ләйсән бу турыда дулкынланмыйча, тыныч кына сөйли ала.

– Мин бары тик күченеп килгәч кенә мәктәптә укырга кирәклеген һәм укыганда укытучының белем дәрәҗәсеннән бик күп нәрсә торганлыгын аңладым.

Ләйсән миңа МДУ студенты билетын күрсәтә – мөгаен, аның хаклы булуына иң көчле дәлил шулдыр. Дүрт ел эчендә ул табигать фәннәрен тырышып үзләштерә, һәм бу аңа, БДИны шәп билгеләргә генә тапшырып, илнең иң абруйлы вузларының берсенә укырга керергә мөмкинлек бирә.

Хеппи-энд? Алай ук түгел. Дусты Марина Мәскәү вузы турында Ләйсәнгә караганда да күбрәк хыяллана. Җитмәсә үзе отличник та – шул, элек Ләйсән яшәгән шәһәрдә. Ләкин алар Казанга күченми, һәм БДИ кызның бөтен хыялларын пыран-заран китерә.

– Марина миңа караганда сәләтлерәк тә иде, – дип борчыла Ләйсән дус кызы өчен. – Мәктәптән тора...

АРТТА КАЛУЧЫЛАР ӨЧЕН ФОРСАТ БУЛАРАК «500+»

Бөтен мәктәпләр дә иң яхшылар рәтенә күтәрелсен һәм баланың киләчәге белем бирүнең түбән сыйфатына бәйле булмасын өчен, артта калучы мәктәпләргә ярдәм итүгә юнәлдерелгән «500+» федераль проекты барлыгын ачыклыйбыз. Узган ел Татарстан да әлеге проектка кушыла.

Үз мәгариф проектларын бөтен илгә таратырга лаеклы, дистәләгән мәктәбе (Казандагылар гына түгел!) Идел буе федераль округы һәм хәтта ил буенча тотрыклы рәвештә беренчеләр исемлегенә кергән республиканың монда ни катнашы бар, дип сорарсыз сез.

Россия һәм халыкара олимпиадаларда җиңү яулаган һәм БДИны 100 баллга тапшырган укучылар да республикада бишәүунау гына түгел. Ә бер ел элек август педсоветында Рособрнадзор җитәкчесе Анзор Музаев хәбәр иткәнчә, дөньяда иң яхшы нәтиҗәләрне Татарстанның туксанга якын мәктәбе (!) күрсәтә.

Ләкин башка статистика да бар, анысы алай ук сөенечле түгел. Республикадагы абруйлы һәм уртача саналган мәктәпләрдән тыш, «500+» проектына кергән вакытта бездә якынча иллеләп мәктәпнең күрсәткечләре мактанырлык түгел иде. Аларның эш нәтиҗәләре мәгариф рейтингларында Татарстанны тотрыклы рәвештә төпкә сөйри торган балласт санала. Ярар, рейтингларга да кул селтик, ди. Көчле мәктәпкә эләкмичә, начаррак мәктәптә укыган күпме Мариналарның үз хыяллары белән хушлашырга мәҗбүр булуын кемнеңдер кайчандыр санаганы бармы икән? Өстәвенә, кайда яшәвенә һәм укытучылар коллективының һөнәри әзерлеге нинди булуына бәйсез рәвештә һәр баланың лаеклы белем алырга хакы бар.

Шуңа күрә түбән нәтиҗә күрсәткән мәктәпләрне тиешле дәрәҗәгә күтәрергә дигән бурыч туа да.

КЕМНЕ БУКСИРГА АЛЫРГА?

Россиядә «500+» проектына старт 2020 елда бирелә. Әмма илнең барлык төбәкләре шунда ук бу идеяне күтәреп ала һәм проектка керә дип әйтү хакыйкатькә туры килеп бетми. Рособрнадзор җитәкчесе Анзор Музаев та яшерми: проектка барысы да кушылмаган. Сәбәбе аңлашыла: республикаңда яисә өлкәңдә проблемалы мәктәпләр бар дияр өчен дә кыюлык таләп ителә. Һәм балаларның язмышы уңышлар турындагы теләсә кайсы отчеттан да мөһимрәк булуын аңлар өчен дә. Татарстанда, бәхеткә, моны аңлыйлар – республика бер елдан соң проектка кушыла.

Бездә ничә мәктәпне буксирга алырга һәм тиешле дәрәҗәгә күтәрергә карар кылына соң? Узган ел республикада андыйларның саны 24 кә җыелган. Кандидатларны федераль дәрәҗәдә билгеләделәр, дип хәбәр иттеләр ТР Мәгариф һәм фән министрлыгында.

Эшләрен яхшыртырга тиешле уку йортларын атамыйбыз. Һәм эш эксперимент өчен мәҗбүри булган конфиденциальлектә генә түгел. Күп кенә мәктәпләр үзләренең урнашу урыны, финанс һәм башка сәбәпләр буенча баштан ук лидер һәм хәтта урта хәлле уку йортлары белән тигез шартларга куелмаган.

24 мәктәп арасына кергәннәрнең күбесе, мәсәлән, авыл җирендә урнашкан, дип хәбәр итте ТР Мәгарифне үстерү институтының укыту-методика эшләре буенча проректоры Гөлнара Сагиева. Аңлатып була: авылларда һәм зур булмаган бистәләрдә педагогик кадрларга кытлык зур. Хәер, шәһәр мәгариф учреждениеләре дә әлеге программага кергән, алай гына да түгел, дүртесе – Казанныкы. Федераль проекттан тыш, программаның төбәк аналогын эшләтеп җибәргәннәр. Аның буенча, дип аңлатты Казан мәгариф идарәсе җитәкчесе Ирек Ризванов, тагын сигез мәктәп эшли.

ТӨП ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ – АДРЕСЛЫЛЫК

Хәзер артта калучы мәктәпләрнең тиешле дәрәҗәгә ни рәвешле күтәрергә ниятләүләре турында сөйлик. Мөгаен, проектның төп үзенчәлеге аның адреслы булуындадыр. Һәр мәктәпкә куратор билгеләнә – кагыйдә буларак, бу уңышлы мәгариф учреждениесе директоры яки аның урынбасары. Тагын бер мөһим момент: кураторны мәктәп урнашкан районнан сайлап алалар. Бу аңлашыла да: әгәр күрше мәктәп яхшы нәтиҗәләргә

иреша алган икән, димәк, аның урындагы авырлыкларны җиңү буенча конкрет тәҗрибәсе бар.

Әлбәттә, һәр конкрет очракта педагогка – уңышка ирешергә, ә мәктәпкә яхшы нәтиҗәләр күрсәтергә аяк чала торган сәбәпләр дә бар. Берсенә – техник яктан начар тәэмин ителү, икенчеләренә – кадрлар кытлыгы, өченчесенә – квалификациясенең түбәнлеге, дүртенчесенә югарыда аталган факторлар барысы бергә комачаулый. Конкрет мәктәпләргә хас аерым үзенчәлекләр дә бар. Мәсәлән, телне белеп бетермәү киртә булырга мөмкин, бу мәктәптә мигрант гаиләләрендә тәрбияләнүче балалар күп булган очракта. Яки имин булмаган социаль мохит.

– Мәктәпнең перспективада нинди конкрет максатка ирешергә тиешлеген аңлавы зарур, югыйсә уңыш казану мөмкин түгел, – ди Гөлнара Сагиева.

Чаралар стратегиясе дә шуннан чыгып сайлана: якындагы өч-биш елга үсеш концепциясен проектта катнашучы мәктәп җитәкчесе куратор белән бергә эшли. Әлбәттә, урта сроклы программа да бар – якын араларда уздырылырга тиешле чаралар планы.

ҺӘРКЕМНЕҢ ҮЗ ҮСЕШ НОКТАСЫ

Нинди чаралар соң ул? Монда да күп нәрсә конкрет мәктәп проблемаларына бәйле. Артта калучылар күп булса – аларның һәркайсы өчен индивидуаль дәресләр планын әзерлиләр, шул ук вакытта һәркем махсус үсеш көндәлеген алып бара. Әгәр укытучының квалификациясе җитеп бетми икән, аның өчен өстәмә белем бирү системасы формалаша (квалификация күтәрү программаларына бүген кытлык юк, күбесен интернеттан табып була). Директор һәм завуч өчен аерым укыту программалары эшләнгән. Кураторлар, үз чиратында, аларга үсеш нокталарын билгеләргә һәм конкрет проблемаларны хәл итү юлларын табарга ярдәм итә. Мәсәлән, мигрант балалар күп булган мәктәпләрдә класстан тыш эшне җанландырырга тәкъдим ителә – экскурсия, концерт, спектакльләр хисабына. Болар барысы да укучыларга рус телен үзләштерергә ярдәм итәчәк...

Социаль мохит имин булмаган районнарда урнашкан мәктәпләр өчен дә үз программасы каралган.

Иллюстрацияләр: Андре Анри Даргеласның «Кругосветное путешествие», Глеб Богдановның «Практикантка» картиналары

– Монда өстәмә белем бирүне мөмкин кадәр күбрәк үстерергә, спорт секцияләрен ачарга кирәк, – ди Ирек Ризванов. – Мондый районнарда, сүз уңаеннан, эти-әниләр белән эшләү шактый авыр. Кайчак алар бала проблемасына бернинди дә кызыксыну күрсәтми. Монда һәр очракта индивидуаль эш итәргә кирәк, әлбәттә. Бу эшкә сыйныф җитәкчесе дә, психолог та, тәрбия эше буенча директор урынбасары да җәлеп ителергә тиеш.

Яр Чаллы шәһәрендә кызыклы тәҗрибә бар. Шәһәр мәгълүмат-методика үзәге методисты Надежда Нестерова, безгә «Аңлы ата-ана» проекты эшләп килүе турында сөйләде. Проект эти-әниләрнең педагоглар белән нормаль аралашуын булдырырга ярдәм итә. Аның кысаларында ата-аналарны яшь буын белән дөрес мөнәсәбәтләр корырга өйрәтәләр.

ЭШЛӘҮ ҖИҢЕЛӘЙДЕ

Аңлашыла ки, бер-ике ел эчендә генә мәктәпне алдан билгеләнгән дәрәҗәгә кадәр күтәрү мөмкин булмастыр. «500+» проекты тарафдарларыннан тыш, скептиклар да бар, аларның аргументлары да шактый саллы. Иң авыры – педагогка йөкләнгән эш күләме, аларның барысы да элиталы гимназияләрдә эшләми бит.

Саннар шуны күрсәтә: Казан ел саен якынча 10 мең укучыга арта. Ә укытучылар аз, узган ел, мәсәлән, башкала мәктәпләренә нибары 400 ләп кенә яшь укытучы эшкә кергән. Ихтимал, укытучылар әзерләү буенча максатчан программа ничектер ярдәм итәр. Мондый программа бүген КФУ белән бергә Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тормышка ашырыла. Ләкин аның нәтиҗәләрен көтү өчен дә вакыт таләп ителә.

Шуңа да карамастан, «500+» проектында катнашучы педагогларны өстәмә эш куркытмый.

– Сез беләсезме, безгә, киресенчә, эшләү җиңеләйде – дип сөйли проектта катнашучы мәктәп директоры Лидия Андреевна**. – Коллектив, нигездә, үзгәрешләр кирәклеген аңлый иде. Әмма вакыт җитмәү аркасында үз эшеңә тәнкыйть күзлегеннән карау, нинди үзгәрешләр кирәклеген билгеләү мөмкинлеге булмады. Ә бәлки, тиешле тәҗрибә, белем җитмәгәндер. Безгә килгән кураторлар төп проблемаларны табарга ярдәм итү белән бергә, аларны хәл итү юлларын да әйтеп җибәрә. Шундый тойгы туа: әйтерсең лә без ярымуяу халәттә эшләгәнбез тә, безгә «Уяныргa!» дигән команда биргәннәр.

Беренче нәтиҗәләр бармы? «500+» проектына төбәкләрнең җәлеп ителүе буенча узган елда үткәрелгән федераль мониторинг күрсәткәнчә, Татарстан, 1208 баллдан 1207 балл җыеп, яшел зонада тора. Хәер, сөенергә иртәрәктер: әлеге баллар процессның башлануын һәм катнашучы мәктәпләрнең планлаштырылган чараларны график буенча үткәрүен генә раслый. Артта калган мәктәпләрнең ничек үзгәрүен вакыт күрсәтер.

– Өлгереш, һичшиксез, без игътибар итә торган иң беренче күрсәткеч, – ди Ирек Ризванов. – Ләкин тәрбия өлеше дә мөһим – әйтик, шундый проблемалар булган мәктәп укучыларында тәртип бозулар кимегәнме... Кешеләрнең мәктәптән канәгать калуы да әһәмиятле. Ә гомумән мәгарифтә тиз нәтиҗәләр көтәргә ярамый. Хәтта бик интенсив эшләгәндә дә беренче сизелерлек нәтиҗәләр өч-дүрт елдан соң пәйда булачак.



БАРЛЫК МӘКТӘПЛӘР ДӘ БАШТАН УК ТӨРЛЕ ШАРТЛАРДА ЭШЛИ, ШУҢА КҮРӘ МӘГАРИФ ҖИТӘКЧЕЛӘРЕ РЕЙТИНГ ТУРЫНДА ТҮГЕЛ, Ә РЭНКИНГ (нинди дә булса күрсәткечнең берсе буенча тәртипкә салынган исемлек – ред. иск.) ТУРЫНДА СӨЙЛӘРГӘ ТЫРЫША һәм мәктәпләрне, иң беренче чиратта, элек нинди булулары белән чагыштыра. Шул ук вакытта, әлбәттә, БДИ, ТДИ, бөтенроссия тикшерү эшләре нәтиҗәләре төп күрсәткеч булып кала бирә – аларның нәтиҗәләре буенча мәгълүмат Белем бирү сыйфатын бәяләү федераль институтында (ФИОКО) туплана. Шулай ук PISA (укучыларның белем алу казанышларын бәяләү буенча халыкара программа, ул төрле илләрдәге мәктәпләрне уку, математика һәм табигать фәннәре буенча эшләнгән тест нәтиҗәләреннән чыгып бүлә) нәтиҗәләре дә исәпкә алына. Дөньяның иң яхшы мәктәпләре PISA тикшеренүендә 500 дән артык балл җыя, һәм нәкъ менә 500+ саны артта калган мәктәпләргә федераль ярдәм проектының исеме булып тора да. Проектның кураторы – ФИОКО.

** Исем-фамилиясе үзгәртелгән

ИКСЕЗ-ЧИКСЕЗ РЕСУРСЛЫ МӘКТӘП

Мәктәп ашханәсендәге ризык, ата-аналар биюләре, «йолдыз»лар белән иртәнге ашлар Россиянең тотрыклы киләчәген тәэмин итүгә булыша аламы? Әйе, чынлыкта боларның барысы да бик тыгыз бәйләнгән. Әлеге күренешләрнең үзара элемтәсен басмабыз 146 нчы «Ресурс» лицеенда булып кайткач ачыклады.

БЕР ПРОЕКТ – ИКЕ БУРЫЧ

Профориентация – «Ресурс»та элек-электән үк алып барыла торган эш юнәлешләреннән берсе. Бүгенге көн исә бу эшне тамырдан үзгәртүне таләп итә. Мәсәлән, сез «йолдыз» белән эшлекле иртәнге ашка ничек карыйсыз? Шул рәвешле лицейда берничә ел элек яңа күркәм тради-

Фото 146 нчы номерлы «Ресурс» лицееннан алынды. РЕКЛАМА

циягә нигез салына һәм аның бренд проектына әйләнә.

«Пәнҗешәмбе саен эшлекле иртәнге аш» – эшчәнлекнең теләсә кайсы даирәсенә караган уңышлы кешеләр, лицейчыларның гаиләләре һәм аны тәмамлаучылар белән очрашу ул. Бу гамәлне моннан берничә ел элек лицей «Дәрестән соңгы мәктәп» грантын откannан соң оештырылган мәктәп телестудиясенең яшь телеоператорлары видеога төшерә, яшь журналистлары тасвирлап бирә.

Укучылар һәм педагоглар белән әлеге рәсми булмаган җанлы форматта күп кенә танылган актерлар, язучылар, спортчылар, сәясәтчеләр аралашкан инде. Еш кына аларга шактый җитди сорауларга җавап бирергә туры килә. Гәрчә очрашу урыны бик тыныч булса да – чөнки бу тапшыру мәктәп ресторанында төшерелә. Әйе-әйе, ресторанда шул. Аның үрнәгендә, хәзер нәкъ менә «Ресурс»тагы кебек ресторannар республикабызда гына түгел, Россиянең башка төбәкләрендә дә оештырыла.

– 146 нчы лицейның ре-эстетигы – сәламәт туклануны оештыру процессы белән идарә итүдә булдырылган төгәл логистика системасы ул, – ди **лицей директоры Диләрә Кәримова**. – Без шулай ук үзебезнең мәктәптә «Дөрес туклану турында сөйләшү» программасын гамәлгә кертәбез.

«146 НЧЫ «РЕСУРС» ЛИЦЕЕ» 1991 ЕЛДА ЯШЬЛӘР ТОРАК КОМПЛЕКСЫ (МЖК) МӘКТӘБЕ БУЛАРАК АЧЫЛА. Аны МЖК отрядларындагылар үз балалары өчен төзи – алар үзләренең яшьләр микрорайонында «тәүлегенә 24 сәгать буе бәхетле булу» турында хыяллана. Комплекска торак йортлар, балалар бакчасы, мәктәп, телестудия, иҗат үзәге, китапханә, спорт мәйданчыклары керә – аның бөтен инфраструктурасы гаилә мәнфәгатьләрен, сәламәт яшәү рәвешен һәм микрорайон халкының иҗади үсешен кайгыртуга юнәлтелгән була. Һавадан караганда аның мәйданындагы биналар сурәте киләчәккә омтылган уклы җәяне (арбалетны) хәтерләтә. Лицей, элеккечә үк, хәзер дә комплексның үзәге булып кала. Бүген 146 нчы лицей – **54 сыйныф**, **1511 лицейчы**, **79 мөгаллим ул**, алар барысы да уртак идея – «ресурста булу» белән берләшкән. 2008 елда лицей «Россиянең иң яхшы мәктәпләре» конкурсында җиңә, 2019 елда исә «Уңышлы мәктәп» грантын яулый.

Бүген бик күпләр мәктәп ашханәсендә тәмле ашату, анда ризыкны сайлап алу мөмкинлеге булуы, туклану культурасын тәрбияли торган атрибутлар зарурлыгы турында кайгырта. Әйе, матур интерьер булдырырга, сыйфатлы ризыклар китертергә, аларны тәмле итеп әзерләргә була. Әмма, әгәр дөрес һәм сәламәт ризык ашауның мөһимлеге бала аңына гаиләдә дә, мәктәптә дә системалы рәвештә сеңдерелмәсә, без бернинди нәтиҗәгә дә ирешә алмаячакбыз. Мәгарифтәге теләсә кайсы эш кебек, бусы да ике яклы. Бер яктан, без балаларны бөтен кирәкле нәрсә белән тәэмин итәбез, икенче яктан – аларда аңлы туклану культурасы тәрбиялибез. Тегесе дә, бусы да – мәктәп балаларының сәламәтлеген ныгыту өчен.

Биредә шулай кабул ителгән... Һәр лицейчының сәламәтлеге турында кайгырталар.

2019 ЕЛДА 146 НЧЫ ЛИЦЕЙ БӨТЕНРОССИЯ ТУКЛАНУ КОНКУРСЫНДА «Гомумбелем бирү оешмаларындагы туклану системаларын оештыруда идарә итү һәм контрольдә тоту (җәмәгать контролен дә кертеп) системаларын камилләштерүнең иң яхшы практикасы» НОМИНАЦИЯСЕНДӘ ПРИЗЕР БУЛА.

ӘТИНЕҢ ХӘЛЕННӘН КИЛӘ! ӘНИНЕҢ ДӘ...

Мәктәп ресторанында төшке аш. Кизү торучы укучылар һәм ашханә персоналы белән бергә искиткеч актив бер ир-ат та әлеге процессны көйләүдә катнаша, тегеләренә дә, боларына да булышырга өлгерә. Бер баланың әтисе икән. Әлбәттә инде, бу хәбәр көне-сәгате белән командировкадагы директорга да барып ирешә. Нәтиҗәдә актив волонтер турында мәгълүмат мәктәпнең компьютер челтәрендәге һәр чатында басыла: «Ярдәмегез өчен рәхмәт!»

Биредә шулай кабул ителгән... Ихластан рәхмәт әйтәләр.

АТА-АНАЛАР КОВОРКИНГЫ

Гомумән, лицейнең ата-аналары арасында актив булу кабул ителгән. Үзеңне төрлечә күрсәтергә була, әмма һәрвакыт ачык, бары тик яхшы яктан гына.

Лицей җитәкчелеге һәм педагоглары авторлык мәктәбенең серен проект һәм идеяләрне гамәлгә ашырганда үзара хезмәттәшлек итүдә күрә. Әлеге үзенчәлекле аерымлык һәм сыйфат билгесе «Ресурс»та күп еллар дәвамында балалар, ата-аналар, педагоглар һәм персоналның актив катнашында экосистема булдырылуы турында сөйли.

Шундый хәлләр дә булгалый: ата-аналар, өстәмә экспертлар сыйфатында, теге яки бу проблеманы хәл итү юлларын да таба.

Биредә төрле делегацияләр шактый еш кабул ителә. Алар өчен экскурсияне традиция буенча директор яки аның урынбасарлары үткәрә. Хәзер исә бу эшкә өлкән сыйныф укучыларын җәлеп итә башлаганнар. Ничек, дисезме? Һөнәре буенча экскурсияләр үткәрүче булган бер әни табылган, ул укучыларны үз һөнәренә өйрәтергә тәкъдим иткән һәм өйрәткән дә.

Тагын бер әни, бизнес-тренер, дәресләрдә укучыларның укытучылар белән үзара нәтиҗәле хезмәттәшлек итүе темасын күтәреп чыккан. Шул рәвешле лицей өчен бик әһәмиятле һәм колачлы тагын бер проект пәйда булган – ата-аналар коворкингы. Чынлыкта бу әти-әниләр белән эшләүнең яңа бер баскычы, алар үзләренең белемен балалар белән уртаклашырга ризалашкан.

Барлык идеяләр һәм аларны гамәлгә ашыру, табигый ки, педагогик коллективның оешкан, бердәм булуын таләп итә, әмма бу бит искиткеч куәтле ресурс та. Бүген әлеге ресурс сәгать кебек төгәл эшли һәм анда лицей җитәкчелегенең катнашуы да әллә ни кирәк түгел. Бу инде традицияләр системасы. Тату гаиләдәге кебек. Шунлыктан: «Мәктәптә «Гаилә турында фән»: модалы трендмы, әллә зарурлыкмы?» дигән сорауга җавап ап-ачык күренеп тора.

Биредә шулай кабул ителгән... Лицейчылар гаиләсендәге һәркемнең мәнфәгатьләрен кайгырталар.

ДИРЕКТОРНЫҢ ҺӨНӘРИ КРЕДОСЫ

Педагог һәм ата-аналар кайвакыт бер-берсен ни өчен аңламый? Мәгълүмат җитәрлек булмаганга. Шунлыктан лицей коллективының төп һөнәри кагыйдәсе – ата-аналар балаларының бөтен эшләрен белеп торырга тиеш. Идарә итүдәге теге яки бу карарны гадел аңлатып биргән очракта ата-аналарның җитәкчелеккә ышанычы арта гына.

– Хаталарны танып гафу үтенүдән куркырга кирәк түгел, – дип саный Диләрә Салих кызы. – Андый хәлләр дә булгалый. Мондый аралашу ыша-

ныч тудыра, ул исә тагын да куәтлерәк үсәргә һәм лицейга тагын күбрәк укучыларны җәлеп итәргә булыша. Беләсезме, «безнең өчен аяк белән табыш бирәләр» дигән термин бар бит. «Ресурс»ка балаларны ныклы традицияләргә, төрле укыту техникаларына кызыгып китерәләр.

Бездә төркемләп укыту методы кулланыла. Мин бик күптәннән инде балаларның төркемдә, командада эшләве яклы.

Мондый вариантта һәр бала курыкмыйча үз фикерен әйтә, үзен дәрестә күрсәтә ала. Икенче яктан караганда, бу укытучыдан бик зур киеренкелек таләп итә, чөнки дәрес-импровизация бирү күпкә катлаулырак. Шунлыктан безнең педагоглар белемнәрен бертуктаусыз арттырып тора.

Бирегә шулай кабул ителгән... Үз хаталарын танудан курыкмыйлар.

ДҮРТ «И» ПРИНЦИБЫ. ҺӘМ БУ ГЫНА ДА ТҮГЕЛ

Авторлык мәктәбендәге төп кагыйдәләрдән берсе – «Ресурс»та фирма эчендәге укыту системасының эшләве. Кем моны кабул итә һәм укырга-камилләшергә әзер, командада кала, башка вариантлар юк.

Әмма белем бирү сыйфатына ирешү өчен мәгариф оешмасы нинди генә нәтиҗәле кагыйдәләрдән файдаланмасын, эшне үзеңнән башларга кирәк, дип саный Диләрә Кәримова.

Шунлыктан ул үз эшчәнлеген дүрт «И» гә нигезли: индивидуаль (шәхси) якын килү + интеллектуаль стимуллаштыру + илһамландыргыч мотивация + идеаллаштырылган йогынты (харизма). Дөнья тәҗрибәсен өйрәнү аңа яңа белем бирү чынбарлыгын булдыруга һәм мәйданны төрле мәгариф бурычларын үтәргә үзгәртү күнекмәләрен үзләштерүгә булышкан.

Парлы һәм төркемләп эшләүне оештыру өчен шартлар тудыру, шулай ук корпоратив укыту технологияләреннән файдалану әлеге процессның аерылгысыз өлеше булып тора, бу хәтта укуга әлләни исе китмәүче балаларның да уңышка ирешүенә китерә.

Инде ике елга якын лицейда «Уңышка ирешүчеләр» проекты гамәлдә, аның төп бурычы – мотивациясе булмаган, уку мөмкинлекләре түбән булган укучыларга җитәрлек игътибар бирү. Балалар максатка ярашлы рәвештә шөгыльләнә башлагач, нәтиҗәләр дә озак көттерми. Уртача балл күтәрелә, «өчле»ләр саны кими. Әмма иң мөһиме – балаларның үз-үзен кабул итүе үзгәрә.

Бирегә шулай кабул ителгән... Уку процессына мотивациялиләр.

ГАЛИҖӘНАП «ЦИФР»

Белем сыйфатын яхшырту өчен лицей педагоглары цифрлы мәгариф платформаларын актив кертә. Шулардан берсе Educont.ru – Россиядәге иң популяр платформаларның берсе, аның төп бурычы – төрле мәгариф ресурсларыннан файдалану мөмкинлеген тудыру. Аның ярдәмендә теләсә кайсы кулланучы үзенең төрле өлкәләрдәге белем һәм әзерлек дәрәҗәсен арттыра ала. «Ресурс»та әлеге платформада ресурсның мөмкинлекләреннән актив файдаланучы мөгаллимнәр дә, укучылар да теркәлгән.

Бирегә шулай кабул ителгән... Мәгариф мохитен «цифрга» әйләндерәләр.

ТОРМЫШКА ӨЙРӘТЕРГӘ КИРӘКМИ

Сүз дә юк, сыйфат белем бирүнең аерылгысыз өлеше булып тора, әмма көндәшлеккә сәләтле шәхес тәрбияләү өчен укучыларның иҗади сәләтләрен дә үстерү зарур. Шунлыктан лицейда күпсанлы иҗади проектлар гамәлгә ашырыла. Укучыларның 80 проценты күптөрле дәрестән тыш эшчәнлеккә җәлеп ителә. Иҗат үзәгенең 12 студиясе, 3 спорт залы, 3 хореография залы, мәгълүмат-китапханә үзәге, инженерлык-техника лабораториясе, телестудия, актлар залы, конференц-зал лицейчылар хозурына бирелгән, гаять зур мәктәп паркы бар...

Бирегә шулай кабул ителгән... Лицейда тормышка әзерләмиләр. Бирегә янып яшиләр.

Диләрә Кәримова, «146 нчы «Ресурс» лицее» МАМУ директоры, педагогика фәннәре кандидаты, ТР атказанган укытучысы, РФ Мәгариф отличнигы, «Иң яхшы директор-2018» Бөтенроссия конкурсы призеры, бу көннәрдә үзенең гомер бәйрәмен билгеләп үтә.

Лицейның укучылар, ата-аналар һәм хезмәткәрләрдән торган тату коллективы җитәкчеләрен шул вакыйга белән тәбрикли:

– Хөрмәтле Диләрә Салиховна! Сезне ихластан туган көнегез белән котлыйбыз. Сезгә күңелегезгә якын фикердәшләр күбрәк очрап, киләчәктә алар белән тагын бик күп кызыклы педагогик проектларны гамәлгә ашырырга язсын. Сәламәтлек, уңышлар һәм бәхет телибез!

ДӨНЬЯ АЧКЫЧЫ БЕЗНЕҢ ТИРӘДӘ

«Прибытие» фантастик фильмының төп героинясы Луиза читтән килүчеләрнең телен үзләштерә, ул аңа киләчәктә булачак вакыйгалар белән идарә итәргә өйрәнергә мөмкинлек бирә. Якынча шундый ук сәләтне Җир телләрендә Казанның 1 нче номерлы Инженерлык лицееның лингвистика мәктәбендә укыталар.

— Look! He dug a little hole into the earth and buried the coin/Карагыз әле, ул кечкенә генә чокыр казып, тәңкәне шунда салган, – ди лепрекон киемендәге артист, икенче берәүгә күрсәтеп.

– I'm so excited! I wonder wдип кушыла hat will grow here! /Бу бик дулкынландыргыч! Нәрсә үсеп чыгар икән? – дип сүзгә кушыла принцесса киеме кигән артистка.

Хикәяче-автор, король, королева, өч принцесса һәм өч лепрекон – артистлар артындагы экранда яңгыр ява. Ә аннан соң чокырга күмелгән тәңкәдән салават күпере пәйда була.

– So, anytime you see a rainbow, it means that somewhere, someone has done a kind deed/Хәзер сез салават күпере чыккан саен, берәүнең ниндидер изгелек эшләвен беләсез! – ди хикәяче, тамашачыга мөрәҗәгать итеп.

Лепреконнардан алтын чүлмәге урлаган һәм аннан соң, аны кайтарып биреп, үз гамәлләре өчен акланган өч принцесса турындагы «Урланган алтын» дип аталган могҗизалы пьесаны Казандагы 1 нче Инженерлык лицееның башлангач лингвистика мәктәбенең «Pinocchio» («Пиноккио») музыкаль театрында катнашучылар куйды.

ИҖАТ – КОМАНДА ЭШЕ

Музыкаль театр – мәктәпнең визит карточкасы. Ул өч ел элек лицей

Фотолар 1 нче Инженерлык лицееннан алынды. РЕКЛАМА

директоры Венера Хәйретдинова тырышлыгы белән оеша. Театрда балалар – 1–4 сыйныф укучылары уйный. Инглиз телендә уйнала торган спектакльләрне өлкәннәр – уку эше буенча директор урынбасары, югары квалификацион категорияле инглиз теле укытучысы Екатерина Гаврилова, режиссер Дельфина Булычева, сәнгать фәннәре кандидаты, хор һәм вокал укытучысы Алексей Баранов, хореограф Эмма Динмөхәммәтова, инглиз теле укытучысы һәм режиссер ярдәмчесе Ирина Куприянова җитәкли.

– Музыкаль театрдан тыш, безнең лингвистик театр да бар – елына өч тапкыр һәр сыйныф кечкенә генә спектакль әзерли. Барлыгы бер елга 30 спектакль куябыз. Алар кечкенә куелышлар, ләкин педагоглар ярдәмендә аларны тулысынча балалар үзләре әзерли, – ди Ирина Куприянова. – Бу спектакльләрне без әтиәниләргә зур фестиваль вакытында күрсәтәбез. Ә инде музыкаль театр тарафыннан әзерләнгән озынрак, катлаулырак спектакльләрне шәһәр һәм республика конкурсларында күрсәтәбез. Безнең портфолиода мәктәп театрларының халыкара, төбәк һәм муниципаль фестивальләрендә катнашып алган 1 дәрәҗәдәге берничә диплом бар инде.

ТЕЛ ТЕАТРДАН БАШЛАНА

Лицейның башлангыч сыйныфларында уку җиңел түгел, әмма балалар да, педагоглар да театр эшендә бик теләп катнаша. Чөнки театр – ул көчле белем ресурсы, һәм бу актерлык осталыгын үстерүгә генә карамый.

– Без бер зур дәрестә бию, вокал, театр сәнгатен берләштерәбез, лингвистиканы да үстибез. Һәм үзенә күрә бер тылсымлы халәт туа: бала үзендәге курку-шөбһәләрдән, шул исәптән чит телдә сөйләшергә комачаулый торган киртәләрдән котыла. Музыкаль театрда төрле яшьтәге балалар уйный, ә без барысының да якынча бертөрле дәрәҗәдә булуына, кечкенәләренең олыракларга тартылуына ирешергә телибез, – ди Дельфина Булычева. – Шуңа күрә беренче репетицияләр тренинг һәм мастер-класслар рәвешендә уза. Алар балаларга бердәм командага тупланырга, бер эш эшләүләрен тоярга ярдәм итә. Бер-беребезгә никадәр мөһим һәм кирәк икәнне аңлагач кына, рольләрне бүлә башлыйбыз.

– Монда тойгыларны белдерү, аваз, дөрес әйтелеш, артикуляция, дикция буенча эшлибез. Балалар теләсә кайсы өлкәдә үзләрен иҗади яктан күрсәтергә, музыкаль образларны ачарга, музыка сәнгатенең төрле формалары, жанрлары һәм төрләре турында күзаллаулар булдырырга өйрәнә. Бу җиңел түгел, чөнки бирәдә һәр балага ачкыч табарга, тартынмыйча, шатланып иҗат белән шөгыльләнә алсын өчен, һәрберсенә сәләтен ачарга ярдәм итәргә кирәк, – ди Алексей Баранов. – Миңа барыннан да бигрәк спектакльгә керешү мизгеле ошый: без материалны, рольләрне аңларга өйрәнгәндә, балалар иҗади эзләнү, шик һәм хаталарның булуын нормаль күренеш дип кабул итә. Без бергәләп дөрес юлга чыгабыз. Аларда гаять көчле энергия һәм үз мөмкинлекләренә зур ышаныч туа. Бу – театрда уйнар өчен генә түгел, уку өчен дә бик зур этәргеч.

БАРЫСЫ ДА ТӨП РОЛЬ

– Театрда миңа барысы да ошый. Мин биергә яратам, бигрәк тә спектакльләрдә. «Пиноккио»да шөгыльләнгән өч ел эчендә мин күпкә яхшырак җырлый, бии башладым, – ди 4 А сыйныфыннан Камилла Кербенева. – Күп кеше төп рольләр турында хыяллана, әмма минем өчен барлык рольләр дә тигез, чөнки зур булмаган рольне дә менә дигән итеп башкарырга була.

– Безнең театр – бик матур тойгылар уята, бигрәк тә без фестивальләрдә катнашып, беренче урыннар яулаганда күңелле. Рольләрне өйрәнү миңа үземне тамашачы каршында иркен тотарга өйрәнергә ярдәм итте. Инглиз телен өйрәнү дә хәзер җиңел бирелә, – ди 4 В сыйныфы укучысы Ясминә Фәйзрахманова. – Зур текстлы рольне уйнысым килгән иде. Хыял тормышка ашты – «Урланган алтын»да мин иң күп сүзләре булган хикәячене уйнадым.

Кечкенә сыйныф укучыларының инглиз телендә сәхнәдә чыгыш ясаганда үзләрен иркен тотулары – пе-

PRESSA

дагогларның җентекле эше нәтиҗәсе. «Тел мохите» трендын Инженерлык лицее Татарстандагы урта гомуми белем бирү учреждениеләре арасында беренчеләрдән булып җитди дәрәҗәдә күтәреп ала һәм, мөгаен, беренче булып үз укучылары өчен чын тел мохите тудыра. Бу яктан караганда, музыкаль һәм лингвистик театрлар – мөһим, әмма бердәнбер компонент түгел.

МОНДА БАЛАЛАР СӨЙЛӘШӘ

Тел мохитен булдыруга беренче адым аерым – лингвистика юнәлеше җитәкчесе вазыйфасын раслаудан башлана. Smart Kids балалар бакчасы, ILSchool XXI с.+ башлангыч мәктәбе һәм лицее арасындагы тел буенча методик һәм педагогик бәйләнеш ролен методист һәм инглиз теле укытучысы буларак зур тәҗрибә туплаган педагог Екатерина Гаврилова үз өстенә ала.

– Иң яхшы тәҗрибәгә һәм иң яхшы вузларга йөз тоткан профильле белем бирү учреждениесе буларак, тел өйрәнү безнең өчен ос-

тенлекле юнәлеш булды һәм булып кала бирә. Инглиз теленә без аерым бер илнең теле буларак түгел, ә халыкара аралашу һәм фән теле буларак карыйбыз, – ди Екатерина Гаврилова.

Инженерлык лицеендагы лингвистика мәктәбенең телләрне тирәнтен өйрәнә торган башка мәктәпләрдән тагын бер мөһим аермасы шунда: инглиз телен белүче педагоглар – тьюторлар эше, алар көндезге сәгать 12 дән соң сыйныф җитәкчесе белән бергә класста булалар.

– Көннең икенче яртысында мин «самоподготовка» (биредә өй эшен эшләү шулай дип атала) вакытында балаларга булышам, класс сәгатьләре үткәрәм, лингвистик театрга әзерләнәбез. Барысы да инглиз телендә бара, – ди тьютор Земфира Ганиева. – Монда телне өйрәнүнең башка ысуллары алдында ике зур өстенлек бар. Беренчесе – дәрестә өйрәнгән бөтен нәрсә уен, сөйләшү, фикер алышулар аша ныгытыла, дәреслек һәм дәфтәр битләрендә калмый. Икенчесе – балаларның уртак кызыксынулары бар, аралашу өчен темалар да күптагын инглиз телендә. Шулай итеп, яшьтәшләре даирәсендәге уңайлы шартларда тел истә кала һәм шактый яхшырак үзләштерелә.

Моннан тыш, көннең икенче яртысында балалар Екатерина Гаврилова тарафыннан эшләнгән World Around Us («Әйләнә-тирә дөнья») дип аталган сертификацияләнгән программасы буенча дәресләргә йөриләр.

– Бу дәресләрдә без физик, химик табигать күренешләре, тормышның төрле өлкәләреннән кызыклы фактлар, халыкларның гореф-гадәтләре, күренекле галим, язучы, җәмәгать эшлеклеләре һәм башкалар турында сөйләшәбез, – ди Екатерина Гаврилова. – Балалар әкренләп төрле тармакларга караган лексиканы үзләштерә, теләсә кайсы темага инглизчә сөйләшү өчен нигез ала. «Әйләнә-тирә дөнья» – программада каралган инглиз теле дәресләренә, инглиз телле укытучылар белән аралашуга зур файда бирә.

КИЛӘЧӘККӘ ӘЗЕРЛЕК

Инглизчәдән тыш, башлангыч мәктәптә балалар 2 нче сыйныфтан база дәреслеге буенча немец телен өйрәнә, ә кайбер сыйныфларда – кытай телен. Шундый төпле лингвистик алымның бер нәтиҗәсе – балаларның төрле дәрәҗәдәге олимпиадаларда җиңүләре. Лингвистика мәктәбендә укучылар республика олимпиадаларында җиңүче һәм призерлар исәбендә. Мондый әзерлек югары сыйныфларда олимпиадаларда уңышлы катнашырга ярдәм итәчәк, ә җиңүләр исә сайлап алынган профильле вуз ишекләрен ачачак. Тагын бер нәтиҗә – инглиз һәм немец телләре буенча халыкара дәрәҗәдәге имтиханнарны уңышлы тапшыру. Имтиханнар 4 сыйныфны тәмамлаганда онлайн тапшырыла һәм бу турыда сертификатлар бирелә.

– Урта һәм югары сыйныфларда балаларның тел белән күп шөгыльләнергә мөмкинлекләре юк, шуңа күрә безнең төп максат – башлангыч сыйныфларда лингвистика белеме нигезләрен салу. Балалар бу чорда телне бик җиңел кабул итә, мәгълүматны тиз истә калдыра, әлбәттә, ул аларны мавыктырырга тиеш. Без бу ресурсны мөмкин кадәр файдалырак итеп кулланырга тырышабыз, – ди Екатерина Гаврилова. – Киләчәктә безнең укучылар иркен сөйләшә, инженерлык белгечлекләре белән бәйле профильле лексиканы истә калдыра, югары сыйныфларда үз проектлары өстендә эшләү өчен кирәкле әдәбиятны өйрәнә ала. Ә иң мөһиме – аларның тышкы дөнья белән аралашу мөмкинлегенә ышанычлары арта. Бу бик күп ишекләрне ача торган ачкыч.

Шәһри КАЗАН
Язмыш

Мәхәббәт һәм нәфрәт, хыянәт һәм гыйбрәт, фаҗигале хәлләр һәм язмышлар – болар бар да «Шәһри Казан. Язмыш» газетасында.

Атна саен 24 битлек язмышлар!

Ярты елга язылу бәясе

597,66 сум

Язылу индексы

ПК313

Реклама 16+

акыллы гамәлләр

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Ни өчен Урал пилмәннәрен шулпасыз ашарга кирәк

Надежда Сәфәрова **ничек** 66 ел мәктәптә укыткан

Валерий Барсуков 45 ел эчендә **ничә** чакрым юл салган

Александр Герасимов **ничек** республика юлларын асфальтка төргән

Кайчан киледә карабодай төйгәннәр

редакция кухнясы

КӨЙЛЕ-МОҢЛЫ УРАЛ ПИЛМӘННӘРЕ

Татьяна Вафина

«Татарстан»ның «Редакция кухнясы» тарихында беренче мәртәбә без төшке ашка гына түгел, ә концертлы мәҗлескә эләктек!

«Кухня»да ашчы булып Н.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясенең Урта махсус музыка мәктәбе директоры Денис Маршанский «чыгыш ясый». Ә Казан консерваториясенең Юниор-оркестры дирижёры Евгений Афанасьев процесс белән идарә итә.

КУЛДАН ЯСАЛГАН

– Пилмән бөгәбез! – дип белдерә Денис Борисович. – Безнеңчә, Уралныкын. Мин тумышым белән Уралдан, Свердловск өлкәсеннән. Туган якларымда пилмән – теләсә кайсы табынның төп сые. Балачагымда мин ясаган пилмәннең исәбе-хисабы юктыр, мөгаен. Шуңа күрә кибет пилмәненә күтәрелеп тә карамыйм.

– Тик мин барыбер бер кап кибетнекен сатып алдым әле, ышанычлырак булсын өчен, – дип Евгений Сергеевич товарын күрсәтә.

– Кирәге чыкмаячак! – ди баш ашчы.

ОСТА ҺӘРЧАК ӘМӘЛЕН ТАБА

Без күренекле профессор, совет чорында яшәгән хор дирижёры Семён Абрамович Казачковның музей-фатирындагы кухняда ашарга әзерлибез. Тик бу искиткеч музыкаль фатирда... уклау юк.

– Борчылмагыз! – дип тынычландыра Денис Борисович. – Уклау булмаса да, зирәклек бар! Камырны шешә белән җәярбез.

– Шешә дә юк, – дип аптыратуын дәвам итә дирижёр.

– Димәк, әнә теге фужер белән җәячәкбез, – чын аш остасына берни комачаулый алмый. – Камырдан түгәрәкләрне дә шуның белән кисеп алырбыз.

Шампан шәрабы өчен фужер белән камыр җәйгәнне күрсәткән эксклюзив видеоны «Татарстан» журналының социаль челтәрләрендә карарга мөмкин.

РЕКТОР ИДЕЯСЕ

Дирижёр Евгений Афанасьевның музыкаль куллары моңарчы пилмән ясый белмәгән. Әмма директор теләсә кемне өйрәтә һәм теләсә кемне мәҗбүр итә ала! Һәм менә инде пилмәннәрнең төз рәтләре бөтен өстәлне тутырып килә – кайсы түгәрәк, кайсы кырыйлары матурлап бөгелгән ярымай рәвешендә. Әйтерсең, симез-симез пилмәннәрдән гыйбарәт оркестр килеп чыга.

– Безнең Юниор-оркестрга ун яшь, – дип сөйли Денис Борисович, чагыштыруыбызны эләктереп алып. – 2012 елда безнең мәктәп консерваториягә кушыла, менә шундый яшьләр коллективын булдыру идеясе ул чактагы ректор Рубин Кәбир улы Абдуллинның башына килә. Бу – Казан консерваториясенең иң яшь иҗат коллективы. Әлбәттә, моңа кадәр дә мәктәптә оркестрлар булган, ни дисәк тә, аның яше инде 60 тан узган. Аерым алганда, Рөстәм Абязов биредә директор булган чакта мәктәп оркестрын

БЕЗГӘ КИРӘК БУЛАЧАК:

Камыр өчен:
- 600 г он
- 1 йомырка
- 1 стакан су
- Бер чеметем тоз.

Эчлек өчен:
- 500 г сыер итеннән фарш
- 1 баш суган
- Тәменчә тоз, борыч.

Фото: Александр Ефремов

PRESSA

1 һәм менә инде пилмәннәрнең төз рәтләре бөтен өстәлне тутырып килә – кайсы түгәрәк, кайсы кырыйлары матурлап бөгелгән ярымай рәвешендә.

1 Басабыз

2 Болгатабыз

3 Җәябез

4 Кисәбез

5 Бөгәбез

6 Пешерәбез

7 Судан алабыз

8 Телибез

җитәкләгән. Моңарчы ул коллективлар нигездә симфоник түгел, ә камера оркестрлары булган. Ләкин нәкъ менә 2012 елда симфоник оркестр оештырылган.

Бу вакыт эчендә оркестрны Татарстанда танылган музыкантлар җитәкли: соңыннан Пермь опера һәм балет театрының баш дирижёры булачак Артём Абашев; аннары – Татарстанның халык артисты Анна Гөлишамбарова. Иң күп тырышлыкны, әлбәттә, опера-симфоник дирижёрлык кафедрасы мөдире Сергей Ферулёв кертә. Ул үзе тәрбияләгән коллектив белән биш ел җитәкчелек итә. Һәм менә хәзер «юниорлар»ны Ферулёвның укучысы Евгений Афанасьев җитәкли. Менә шундый дәвамчанлык.

МИНЕМ КЕЧКЕНӘ ОРКЕСТРЫМ

– Юниор-оркестрның үз традицияләре бар, – дип дәвам итә Евгений Сергеевич. – Сезонга ике тапкыр С.Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында, Чаллының Орган залында чыгыш ясыйбыз. 2018 елда Кировта «Нократ язы» халыкара фестивале кысаларында оркестр концерты узды!

– Бу елларда оркестр белән, солист сыйфатында, заманында безнең мәктәптә укыган Михаил Плетнёв чыгыш ясады, – дип өсти Денис Борисович. – Безнең музыкантлар белән уйнаганда, Михаил Васильевич оркестрга мактаулы бәя бирде: «Аның профессиональ коллектив булмавы аңлашыла, әмма мәктәп оркестры өчен бу – бик яхшы дәрәҗә».

Оркестр белән легендар грузин пианисты Элисо Вирсаладзе да чыгыш ясый. Бервакыт яшь музыкантлар белән Польша дирижёры Богуслав Давидов эшли – ул чакта оркестр София Гобәйдуллина исемендәге Халыкара пианистлар конкурсы финалистлары өчен уйный. Коллектив иң зур дәрәҗәгә 2016 елда ирешә – оркестрның видеоязмасы Парижда узган халыкара конкурста Гран-при ала. Ә быел май аенда коллектив Санкт-Петербургта үткән «Симфония мира» халыкара конкурсында беренче премияне яулый.

УКУЧЫЛАР ОРКЕСТРЫ

– Оркестрда состав бик мөһим, – ди дирижёр. – Ә безнең составның нигезен Урта махсус музыка мәктәбе балалары – җиденче сыйныфтан алып унберенче сыйныфка кадәр укучылар тәшкил итә. Тагын консерваториянең беренче-икенче курсыннан берничә студент. Чып-чын мәктәп оркестры! Былтыр без Татар дәүләт филармониясе залында, Иннополис шәһәренең А.С.Попов исемендәге технопаркы залында чыгыш ясадык. Быел да бу проектта катнашырбыз, дип өметләнәм.

Россиядә балалар симфоник оркестрлары күп түгел, чөнки тынлы уен коралларында, аерым алганда, бакыр тынлы уен коралларында уйнаучыларга кытлык бар, виолончель, альт, контрабас кебек инструментлар-

да уйнаучылар да җитми. Бәхеткә, безнең мәктәп, консерватория һәм аның хәзерге ректоры Вадим Роберт улы Дулат-Алиев ярдәме белән менә шундый коллектив туплашты.

МУЗЫКАЛЬ ҺӨНӘР

– Без ни өчен оркестр белән шөгыльләнәбез? – дип сорау куя Денис Борисович, яңа гына бөгелгән пилмәнне башкалары янына озатып. – Чөнки бу балаларның киләчәк белгечлеге дигән сүз. Бездә кыллы уен кораллары, тынлы уен кораллары бүлекләре бар, кемдер музыка мәктәпләрендә эшләячәк, аерым алганда, Анна Гөлишамбарованың «Яңа музыка» оркестрына юл тотачак. Дәүләт академия симфоник оркестрында, опера театры оркестрында да безнекеләр җитәрлек. Мәктәбебез – дәүләтнеке, уку түләүсез, укырга керергә теләүчеләр арасында конкурс бар, чөнки Россиядә федераль дәрәҗәдәге мондый мәктәпләр нибары бишәү генә.

Мондый мәктәпләр музыкага сәләтле балалар өчен ачылган икән. Алар монда гомуми һәм урта һөнәри белем ала. Мәктәп музыка училищесы белән берләштерелгән дияргә мөмкин, ягъни 5-7 ел мәктәптә укуга 4 ел училище белеме өстәлә. Конкурс нигезендә балалар теләсә кайсы сыйныфка укырга керә ала. Ләкин башта имтиханнар бирү таләп ителә, ягъни бу гади музыка мәктәбе түгел, монда укучыларга таләпләр күпкә югарырак, чөнки балалар белгечлек алып чыга.

СӘХНӘ АРТЫ СЕРЛӘРЕ

– Артык югары таләпләр куеп уку, мөгаен, авырдыр. Музыкадан тыш, балалар тормышында башка – гомуми белем предметлары да бар бит әле...

– Безгә үз тормышларын музыкага бәйләргә теләүчеләр килә. Алар шуның белән яши. Менә сезгә шушы көннәрдә генә булган хәлне сөйлим әле, – дип, Денис Борисович пилмән өчен су кайнатырга күрсәтмә бирә дә сүзен дәвам итә. – Янымa тугызынчы сыйныф укучысы килде. Оркестр өчен борчылып йөриләр икән, чөнки репетицияләргә барысы да җаваплы карамый. Һәм менә алар, 9 сыйныф укучылары, вазгыятьне үзгәртергә ниятли. Алар аерым бер актив булдырырга: виолончельләр, беренче скрипкалар, бакыр тынлы уен кораллары төркемнәренең һәркайсына аерым җаваплы кеше билгеләп куярга телиләр. Төркемнәр аерым-аерым да очраша һәм өстәмә репетиция ясый алсын өчен. Беләсезме, аларның мондый теләкләре бик куандыра. Оркестр – тулы бер организм бит ул. Балалар оркестрның үзләренеке икәнен аңлый башлады. Һәркайсының аерым-аерым түгел, ә бер-берсе белән бәйләнештә булуын төшенделәр. Аларга үз оркестрлары кадерле. Бездә репетиция атнага ике тапкыр сәгать ярым бара. Бу күп тә түгел кебек, ләкин аз дип тә әйтә алмыйбыз.

– Профессиональ коллективлар көн саен репетиция үткәрә, – ди Евгений Сергеевич берникадәр үкенеч белән. – Атнага ике тапкыр гына җыелып, тулы программа әзерләү шактый кыен. Ләкин бездә нормалар шундый. Әгәр малайлар һәм кызлар төркем-төркем үзләре җыела ала икән, бу бик шәп, мондый күренешне хупларга гына кала.

– Үз-үзеңне оештыру һәм цех серләрен үзләштерү мөһим, – дип сөйләгән арада, баш ашчыбыз соңгы стадиягә керешә: пилмәннәрне кайнап торган суга салып җибәрә. – Ә мондый серләрне балалар үзләренә ошаган кешедән өйрәнә... Юниор-оркестр София Гобәйдуллина концертында катнашканда, укучыларыбыз белән Польша дирижёры Богуслав Давидов эшләде. Һәм балалар гала-концертта аңа: «Богуслав, китмәгез! Без сезгә интернатта бүлмә әзерләп куйдык!» – дип, чәчәк бәйләме бүләк иттеләр.

ПӘРДӘ ТӨШӘР АЛДЫННАН

Уртак тырышлык белән пилмән ясалды, пешерелде һәм табынга бирелде. Тегеләй-болай гына түгел, ә музыка яңгырап торганда. Классик музыка.

Башкаручы – пианист Денис Маршанский. Дирижёрлык пультында – дирижёр Евгений Афанасьев.

– Урал пилмәне шулпасыз гына бирелә, – ди Денис Борисович, бераз укроп сибеп җибәреп. – Шулпа инде ул татарлар керткән өлеш. Пилмәнне шулпага салып биргәннәрен Казанда гына күргәнем бар. Хәтта Мәскәүдә дә, миңа уку һәм яшәү бәхете тигән консерватория тулай торагында да, Евгений студент булган Гнесинка (Гнесиннар исемендәге Россия музыка академиясе) тулай торагында да пилмәнне шулпа белән бирмиләр иде.

– Ә бәлки, шулпасын да салганнардыр, – дип уйга калды Евгений Сергеевич. – Тулай торакта иң мөһиме күбрәк булуы бит, ә пилмән янына кайсын – ипинеме яки шулпанымы күбрәк бирергә – анысы бик әһәмиятле түгел.

2

Шампан шарабы өчен фужер белән камыр җәйгәнне күрсәткән эксклюзив видеоны «Татарстан» журналының социаль челтәрләрендә карарга мөмкин.

@PROTATARSTAN


Дорогие читатели!
Желаем сохранять вкус к жизни!
Приходите на наши концерты :)
Пусть Музыка звучит в Ваших сердцах!

Надежда Сәфәрова (уртада) чыгарылыш сыйныф укучылары белән.

Фото проектта катнашучыларның архивыннан



Автодромның шоссе-бөҗра трассасы. 2009 ел.
Сулдан уңга: Фоат Вәлиев, «Алексеевскдорстрой» ААҖнең генераль директоры;
Илфар Гыйльметдинов, Юл фонды директоры;
Валерий Барсуков, «Алексеевскдорстрой» ААҖнең баш инженеры

«Татарстан» журналының махсус проекты

ЗАРЛАНМЫЙЧА ЭШЛӘГӘН БУЫН

Авыр вакытларга, кырыс заманнарга, кайчак түзеп булмаслык тормыш шартларына да карамастан, зарланмый-сукранмый, үз юлларында очраган бөтен кыенлыкны җиңеп, бу буын кешеләре алга атлаган, дөньяны ямьлерәк, уңайлырак итәргә омтылган. Алар юллар төзегән, күперләр сузган, электростанцияләр, заводлар салган, яу кырларында ватанны саклаган, сугыштан соңгы илне күтәргән.

«Татарстан», үзенең каһарман якташлары белән очрашып, сезне әлеге фидакарь буынның маҗаралар тулы тормыш юлы белән таныштыруны дәвам итә.

4 НЧЕ ТАРИХ
Надежда Сәфәрова ничек 66 ел мәктәптә хезмәт куйган

5 НЧЕ ТАРИХ
Валерий Барсуков ничек 3 мең километр юл салган

6 НЧЫ ТАРИХ
Александр Герасимов республика юлларын ничек асфальтка төргән

Беренче өч тарих турында басмабызның октябрь санында укый аласыз.

4 нче тарих

66 еллык мөгаллимлек бәхете

Хәтеренә уелган бер көндә укытучы булырга карар кылган ач-ялангач икенче сыйныф баласыннан РСФСРның атказанган мәктәп укытучысы дигән дәрәҗәле исемгә кадәр юл авырлыклар һәм сынауларга бик бай була. Әмма Надежда Сәид кызы Сәфәрова үзе кичергән барлык кыенлыклар турында: «Алар барысы да вак-төяк, чүп кенә!» – дип, җиңел итеп искә ала. Чөнки аның тормышында элек тә, хәзер дә иң мөһиме – балаларга мәхәббәт һәм аларның да аны яратуы.

Яхшы укытучы – яшь, әле ныгымаган балага дөрес юнәлеш һәм таяныр нокталар табарга мөмкинлек биреп, өлкәнлек дөньясына озатучы шәхес ул. Ә Надежда Сәфәрованың үз тормышында шундый юл күрсәтеп җибәрүче булганмы икән?

ӨЛКӘННӘР ДӨНЬЯСЫНА ЮЛАМАН

– Миңа ул вакытта сигез яшь чамасы иде. Таҗикстанның Регар шәһәре, 1946 ел. Бер салкын кыш көнне, чып-чын зәмһәрир суыкта, күрше Коля абый каяндыр бер бидон керосин алып кайткан да шуны сатарга мине җибәрде. Ә миндә кием дигән нәрсәдән биленнән бау белән кысып бәйләнгән ирләр пиджагы, аякта ниндидер чүпрәкләр (оекбашлар юк) һәм 41 нче үлчәмдәге галошлар гына иде. Базарда шул керосин белән басып торганда, салкынның үзәгемә үтүен тоям. Кинәт берәүнең: «Кызый, керосин күпме тора?» – дигәнен ишеттем. Суыктан ярымүле иреннәремне көчкә селкетеп: «50 сум...» – дип җавап бирдем. Ул ир-атның үзе белән акчасы булмыйча, миннән өенә кайтуымны үтенде. Барак ишеге ачылып китүгә, гаҗәеп хуш истән тәмам өнсез калдым. Бу укроплы борщ исе икән, ләкин мин ул вакытта андый ризыкны белми дә идем... Хуҗабикә миңа күз салып алуга ук барысын да аңлады. Мине табынга утыртты да савытка туп-тулы итеп борщ салды. Һәм бер телем икмәк бирде. Мондый тәмле ризыкны башка беркайчан да ашамадым... Мин җылыдан һәм тамагым туюдан тәмам изрәдем! Ә аннары теге ханым шифоньерда актарынды да бер пар йон оекбаш тартып чыгарды, аягымдагы чүпрәкләрне сүтеп, шул оекбашларны кидерде. Бәхетемнең иге-чиге юк иде! Мине өенә алып кайткан ир-атның рус теле һәм әдәбияты укытучысы икәнлеген соңыннан гына белдем. Ул көнне мин шуны аңладым: рус теле һәм әдәбияты укытучыларыннан да игелеклерәк һәм кешелеклерәк затлар юк икән. Һәм мин дә шундый булачакмын дигән карарга килдем.

Фото Надежда Сәфәрова архивыннан

ПЛАНЫ
ЦЕЛИ УРОКА
ПЕДАГОГИЧЕСКАЯ НАУКА И ПРАКТИКА

СТАЛИНАБАДТАГЫ ПАРИЖ КЫЗЫ

Надежда Сталинабад шәһәренең бер мәктәбендәге тәүге дәресен һаман да хәтерли, бу мәктәпкә аны, пединститутның өченче курсын тәмамлаганнан соң, практикага җибәрәләр. Унынчы сыйныфта Маяковский иҗатына багышланган дәрес була ул.

– Мин бер укучыны такта янына чакырдым. Ул совет паспорты турында шигырь укый башлады. Аңа якынаюым булды, бөтен класс кинәт шаркылдап көлеп җибәрде. Ә мин ни булганын аңлый алмыйм! Соңыннан төшендем – буем ул укучының күкрәк тирәсеннән артмаганга, бу кырыйдан караганда чыннан да бик көлке күренә икән. Кич белән ул хәлне апама көлә-көлә сөйләдем. Ул, бер сүз әйтмичә, шкафтан аяк киеме тартмасы тартып чыгарды, ә анда – Кытайдан кайтартылган 10 сантиметрлы үкчәле замша босоножка. Әнә шулай итеп мин буйда укучыларым белән бераз тигезләштем. Шул вакыттан бирле биек үкчәле туфлине салмадым! Мөгаен, нәкъ менә шуның аркасында укучылар мине үзара «парижанка» дип атагандыр да инде.

ЧЫП-ЧЫН АВАНТЮРА

Таҗикстанда дүрт ел эшләгәннән соң, Надежда ире һәм кечкенә улы белән бергә җәмгатенең туган ягына – Татарстанга күченеп кайта. Биредә аны тәүге сынау көтә – Сәфәровлар гаиләсе төпләнгән Лениногорск шәһәрендә рус теле һәм әдәбияты укытучысы вакансиясе юк икән…

– Эшсез утырмас өчен, мин «Завета Ильича» газетасы редакциясенә татар теленнән русчага тәрҗемәче булып урнаштым. Бу чып-чын авантюра иде, чөнки, Златоустта туып, Урта Азиядә яшәп, минем татарчаны эти-әниемнән генә ишеткәнем бар иде, ә үзем исә татарча бөтенләй сөйләшмим. Ул чорда калын-калын ике сүзлек өстәл китабыма әйләнде. Телне кыр шартларында өйрәндем дияргә була. Әлбәттә, көтелмәгән хәлләр дә килеп чыккалады. Бервакыт миңа колхозларның язгы чәчүгә ничек әзерләнүе турында материал килеп керде. Һәм менә текстта «карданваллар эшлиләр» дигән сүзләре булган бер җөмлә очрады. Мин «карданвал» сүзе барлыгын белми дә идем һәм аны сүзен-сүзгә тәрҗемә иттем: кардан валлар ясыйлар. Сез ул хаталы тәрҗемә өчен миңа ничек эләккәнен күз алдына да китерә алмыйсыз! Тик минем үз аңлатмам бар иде: кар валлары – басуларда кар тоту, суны янга калдыру өчен кирәк. Редакциядә эшләгән елларым минем өчен чын татар теле мәктәбенә әйләнде, мактану булса да, мин бу имтиханны менә дигән итеп тапшырдым дип әйтә алам, чөнки күп еллар узгач, мине шәһәр мәгариф идарәсенә татар теле укытырга чакырдылар бит!

МӨҺИМ ДӘРЕС

Вакыт тәгәрмәче алга тәгәри, һәм Надежда үз белгечлеге буенча эшкә урнашу мөмкинлеге таба – ике балалар йортыннан оештырылган интернат-мәктәпкә тәрбияче булып керә. Эшнең беренче көнендә үк героинябыз диплом белән түгел, ә тормышның үзендә укытучы булырга ярдәм иткән сабак ала.

– Миңа 4 нче сыйныф эләкте, ул бик төрле иде: бер балага – 10, икенчесенә 15 яшь… Авыр язмышлы, четерекле холыклы балалар – барысы да ятим. Менә беренче эш көнем тәмамланып килә. Балалар кичке аш ашады, өй эшләрен хәзерләде, көндәлек гигиена процедуралары үтте. Мин, аларга тыныч йокы теләр өчен, башта кызларның йокы бүлмәсенә кердем. Анда бик җылы мохит – һәр тумбочкада курчак яки матур рәсем тора, кызлар серләшә, кеткелдәп көлеп ала. Аларга тәмле төшләр теләгәч, утны сүндереп чыгып киттем. Чиратта – малайлар. Керсәм, аларда йокы бүлмәсе түгел, ә казарма икән – сукно одеяллар астыннан кырылган башлар гына чыгып тора. Йөрәгем кысылып куйды. Малайлардан хәлләрен сорашам. Аларның берсе (исемен әле дә хәтерлим – Әхнәф иде) үз янына килүемне сорады. Болай гына, сөйләшер өчен генә. Нииндидер юк-бар турында… Аның өстенә яптым да, җилкәсеннән сөеп, тыныч йокы теләдем. Утны сүндерергә җыенган гына идем, тагын берсе: «Ә минем янга?» – димәсенме? Һәм ул сүзләр кырык тапкыр әйтелде. Йокы бүлмәсеннән чыгуга, елап җибәргәнемне хәтерлим. Тормыш миңа бик мөһим дәрес биргәнен аңладым – һичкем кыерсыта алмас булып тоелган әлеге тәртипсез, көчле малайлар мәхәббәт, игътибар һәм җылылыкка кызларга караганда да күбрәк мохтаҗ икән.

ПЕНСИЯГӘ ЧЫГЫП 20 МИНУТ ҮТҮГӘ…

Интернат-мәктәптән соң Надежда Сәфәрова берничә ел Лениногорскиның төрле мәктәпләрендә тел һәм әдәбият укыта, аннары исә шуларның берсенә директор итеп чакыралар. Ә соңыннан, хезмәт юлының ахырына табарак, шәһәр мәгариф идарәсенең методик кабинетын җитәкләргә тәкъдим итәләр. Лаеклы карьераны лаеклы рәвештә тәмамлау да кебек, бер карасаң. Ләкин Надежда бу ноктадан соң нинди зур өтер куелачагын хәтта күз алдына да китерми!..

– 1992 ел иде ул. Мин әле генә пенсияне хисаплаттым да, шәхси әйберләремне җыеп, моңсу гына өйгә юл тоттым. Йозакның ачкычын борганда, фатирның түр ягында телефон шалтыраганын ишеттем, тизрәк кереп, трубканы алдым. Педагогика институтыннан шалтыраталар – анда әле генә ике яңа бүлек ачылган һәм кадрлар проблемасы көн үзәгендә икән. Хөрмәтле Надежда Сәидовна борынгы славян теле курсын алып бара алмас микән? Ә борынгы рус телен? Ә, бәлки, мантыйк дәресләрен дә? Этика курсы турында ни әйтә аласыз? Ә эстетика мәсьәләсендә? Диалектология турында ни уйлыйсыз? Алай булгач, тел белеменә кереш белән культурологияне дә алып буладыр? Һәм чит ил әдәбиятын да, әйе, барлык дүрт гасырныкын…

Шулай итеп, пенсиягә чыгып нәкъ 20 минут узуга, мин 17 предмет укытучысы булдым. Әлбәттә, бу язмыш бүләге иде. Миңа эшләргә генә түгел, ә чын мәгънәсендә көн-төн тир түгәргә туры килде – университет белемнәрен искә төшерергә һәм арттырырга кирәк иде. Чөнки студентларымның дәресләрдә вакыт уздырып түгел, ә авыз ачып тыңлавын һәм лекцияләрдән әсәрләнеп кайтып китүләрен теләдем. Ул чорда мин бөтенләй йокламаска өйрәндем! Бик кызык, мавыктыргыч, дулкынландыргыч вакытлар иде – бу минем өчен чын имтихан булды! Талантлы студентларның хезмәттәшләремә, ягъни укытучыларга әверелү процессын күзәтеп ләззәт алдым. Нәкъ менә шул вакытта Ходайның мине әнә шулай эш аша яратуын һәм саклавын аңладым. 95 нче елда улым һәлак булды бит. Әгәр эшем булмаса, мин ул кайгыны кичерә алмас идем. Тагын 10 елдан иремнең гомере өзелде, ул чакта да мине эшем коткарды...

ДӨРЕС КИТАПЛАР

20 ел институтта тир түккәннән соң, Надежда тынычлангандыр дип уйлыйсыз икән, сез бик ялгышасыз! Укытучылык эшләре тәмамлангач, репетиторлыкка багышланган унъеллык башлана.

– Безнең яшьлек чорында репетиторлар булмады. Чөнки аларның кирәге дә юк иде. Сер түгел, хәзерге балаларның белем дәрәҗәсе, без «дөньяда иң укый торган ил» булган вакыт белән чагыштырганда, кими төште. Әйе-әйе, балалар укудан туктады һәм барлык кирәкле мәгълүматны бармак белән бер генә төртеп интернетта таба алабыз дигән иллюзия сазлыгына батты. Ләкин мәгълүмат белем белән бер түгел! Ул мәгълүматлар белемгә әйләнсен өчен, баш мие анализ, синтез, чагыштыру, абстрактлаштыру, гомумиләштерү кебек иситкеч зур эш башкарырга тиеш. Моны чынга ашыруның бер генә ысулы бар – китаплар. Ул гына да түгел, мин әле сезгә укытучы өчен һич килешмәгән бер фикерне дә әйтәм: грамоталылыкка махсус өйрәнү дә кирәкми – күп итеп уку да җитә. Мин үз укучыларымны укырга гына мәҗбүр итеп калмадым – аларга әдәбиятны тарихи контекстка бәйләп бирә идем. Шул рәвешле балада китапның эчтәлеге белән кызыксыну да уяна, аның дөньяга карашы да киңәя. Уку тәмен тойган кешенең тышкы яктан да үзгәрүен күреп соклanasың, аның җилкәләре тураеп китә, күз карашы да ничектер тирәрәк һәм үткенрәк була, ә иң мөһиме – ул бәйләнешле сөйләмә һәм сүз байлыгы белән аерылып тора. Миндә ымлыклар белән генә сөйләшкән бер кыз бар иде. Сыйныфта да аны, әлбәттә, читкә тибәрәләр иде. Әмма дәресләребез ярты ел да бармагандыр, кызны санга сукмаган сыйныфташлары ничек тә аның тирәсендәрәк булырга тырыша башлады, чөнки ул теләсә нинди темага шундый мавыктыргыч итеп фикерен әйтеп бирергә өйрәнде! Ә моның сере исә – дөрес сайланган китапларда.

ШУЛАЙ ИТЕП, ПЕНСИЯГӘ ЧЫГЫП НӘКЪ 20 МИНУТ УЗУГА, МИН 17 ПРЕДМЕТ УКЫТУЧЫСЫ БУЛДЫМ. ӘЛБӘТТӘ, БУ ЯЗМЫШ БҮЛӘГЕ ИДЕ. МИҢА ЭШЛӘРГӘ ГЕНӘ ТҮГЕЛ, Ә ЧЫН МӘГЪНӘСЕНДӘ КӨН-ТӨН ТИР ТҮГӘРГӘ ТУРЫ КИЛДЕ.

2020 елда мин олы тормыш юлына соңгы укучымны озаттым. Ягъни мөгаллимлек стажым, әйтергә дә куркыныч! – 66 ел дәвам итте. Мин гомерем зая узмады дип горурланып әйтә алам. Укучыларым миңа гел шылтыратып тора, кунакка киләләр. Сыйныфташлары белән очрашканда, минем дәресләремне генә искә төшергәннәрен бик еш телгә алалар... Укытучы өчен шуннан да зуррак бүләк бармы? Мин бәхетле кеше!

5 нче тарих

ТӘКЪДИРГӘ ЯЗЫЛГАН ЮЛДАН

Валерий Барсуков 45 ел гомерен юл төзелешенә багышлаган.

– Бу вакыт эчендә күпме юл салганыгызны, күпмесен төзекләндергәнегезне, яңартканыгызны санаган юкмы? – дип сорыйбыз аңардан.

– Күптән түгел чамалап караган идем – 3,5 мең километрдан артык килеп чыкты.

– Соң бу бит Казаннан Красноярскига барып җиткән кебек!

Әдәби тәнкыйтьчеләр рәхәтләнеп китап укый, ә театр тәнкыйтьчеләре ләззәтләнеп премьера карый алмый, диләр. Кызык, трасса һәм магистральләр төзүче осталар рульдә үзләрен ничек хис итә икән?

– Автомобильгә утыруга ук, миндә юлларны тәнкыйтьләүче уяна, – дип көлә Валерий Игнатьевич. – Хәтта калганнар юлның уңайлылыгына сокланганда да, мин, үзем дә сизмәстән, җитешсезлекләрне билгеләп үтәм: «Менә монда тагын да яхшырак эшләргә мөмкин иде, ә монда бераз гына җитеп бетмәгән».

ГАСЫР ТӨЗЕЛЕШЛӘРЕНДӘ

1970 нче елларда юллар начар була. «Каздорстрой» предприятиесенең яшь инженеры Валерий Барсуковка хезмәт куярга туры килгән тәүге колачлы проектларның берсе – Казан – Яр Чаллы юлы.

– Ул елларда юл төзелеше җиңелләрдән булмады, – дип искә ала ул. – Асфальт-бетон заводларын үзебез төзедек, вак ташны Уралдан ташыдык, кайчагында бу үзе бер зур мәсьәлә иде. Техникага килгәндә, анысы да әллә ни мактанырлык алдынгы түгел, барысы да кул белән, автоматикасыз башкарылды. Хәзерге кебек 3D үлчәмдә эшли торганнары каян булсын!

Бу эшләр ун елга якын дәвам итә, аннары «Каздорстрой» башка проектларга алына. Әйтик, Казанны төньяктан әйләнеп узу юлы. Яки тагын бер «гасыр төзелеше» – Чулман аша Саескан Тавы авылы белән Алексеевское арасында күпер. Сүз уңаеннан, нәкъ менә Алексеевск районында Валерий Игнатьевның язмышы яңа борылыш ясый – ул вакытта төзелгән «Алексеевскдорстрой» компаниясе командасы озак елларга аның хезмәт гаиләсенә әверелә. Республикабыз куйган иң җитди бурычларны алар бергәләп хәл итәргә алына – 32 районда юлсызлык проблемасына каршы көрәшкә күтәреләләр.

ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ ХОЛЫК ИЯЛӘРЕ

– Юл төзүчеләрнең менталитеты үзгә, – дип сөйли Валерий Игнатьевич. – Уйлап кына карагыз, алар һәрвакыт эшне ялан кырдан башлый! Димәк, алар өчен барлык шартларны – бәдрәфен дә, ашханәсен дә оештырырга кирәк. Кайда яшәячәкләрен дә кузаллау зарур. Шуңа күрә безгә җитештерү процессын оештыру, заманча технологияләр, яңа материалларны кулланышка кертү, юл эшләренең сыйфатын күтәрү генә түгел, кешеләр турында да кайгыртырга туры килде.

Кайчагында юл төзүчеләр берничә ай гаиләләрен күрми яши. Бик сабыр һәм үз эшенә бирелгән кешеләр генә мондый хезмәткә сәләтле. Гадәттә, шундый һәр төзүченең гаиләсе дә шундый ук сабыр һәм тугры була.

– Ягъни ул бик таушалдыра торган эш?

– Иртәнге алтыда син инде эштә, кичке унда өйгә кайтасың. Ял көннәре, нигездә, кышын гына. Әмма әллә ни «таушалмадым», күрәсез, исән-сау, – дип көлә Валерий Игнатьевич. – Бу безнең яшәү нормасы иде – без, юлчылар, моңа күнеккән. Кызыксындыру чарасы дигән нәрсә белән дә тәртип иде – яхшы түләделәр, совет идеологиясе дә ярдәм итте. Чын осталар – Владимир Иванович Усатенко, Ринат Хәбиб улы Шәфыйков, Игорь Васильевич Ярцев һәм, әлбәттә, Фоат Вәли улы Вәлиев җитәкчелегендә эшләп үсүем белән дә бик уңдым...

БӘХЕТЛЕ ОЧРАК...

Ә бит язмыш бөтенләй башкача да язылырга мөмкин булган. Яңа гына мәктәп тәмамлаган Валерий юл төзүче карьерасы турында хыялланмаган да – ул шунда ук берәр эшкә урнашырга ниятләгән. Әмма дуслары Казан инженерлык-төзелеш институтына укырга кереп карарга күндерә. Дуслар барысы бергә укырга тели. Нәтиҗәдә, бөтен компаниядән ул берүзе генә укырга керә ала.

– Әйе, хезмәт юлын шундый очраклылык белән башлап җибәрдем, – ди Валерий Барсуков. – Ә чынлыкта бөтен язмышны билгеләгән эшемне тапканмын икән! Мин бу эшне бик яраттым.

– КАЙЧАГЫНДА ЮЛ ТӨЗҮЧЕЛӘР БЕРНИЧӘ АЙ ГАИЛӘЛӘРЕН КҮРМИ ЯШИ. **БИК САБЫР ҺӘМ ҮЗ ЭШЕНӘ БИРЕЛГӘН КЕШЕЛӘР ГЕНӘ МОНДЫЙ ХЕЗМӘТКӘ СӘЛӘТЛЕ.** ГАДӘТТӘ, ҺӘР ШУНДЫЙ ТӨЗҮЧЕНЕҢ ГАИЛӘСЕ ДӘ ШУНДЫЙ УК САБЫР ҺӘМ ТУГРЫ БУЛА.

Ул гаилә династиясенә дә нигез сала – Валерий Игнатьевичның энесе Юрий да, бертуганнарының өч улы да аның эзеннән китә. Хәер, Барсуков гаилә династиясе генә түгел, хезмәт династиясен дә булдыруга ирешкән.

– Башта мин инженер-техник хезмәткәрләрне укыту һәм аларның квалификацияләрен күтәрү эшен оештырырга тиеш идем – «Алексеевскдорстрой» миңа шундый бурыч куйды. Эш күп дигәндә ике елда төгәлләнер дип кузалланган иде. Тик, нәтиҗәдә, мин анда егерме елга якын калдым. Баш инженер буларак, безгә лаеклы алмаш кирәклеге турында һәрчак уйлап йөрдем. Ул яшьләр инде күптән сыйфатлы юллар төзи алырлык тәҗрибәле, белемле белгечләргә әйләнде. Гасырлар буе торырлык юллар дип әйтергә дә курыкмыйм! Димәк, чыннан да, алмаш лаеклы булып чыкты.

Фото: Александр Ефремов

6 НЧЫ ТАРИХ

ДИНАСТИЯДӘН БЕРЕНЧЕ

Фото Александр Герасимов архивыннан алынды.

Александр Герасимов – Татарстан тарихында беренче тапкыр республика юлларын асфальтка төрә башлаган юл төзүчеләр буынының лаеклы вәкиле ул.

Тыгызланган, урыны белән вак таш ярдәмендә ныгытылган киң балчык тасмадан гыйбарәт юл яз-көз үтеп чыккысызга әйләнә, хәтта тракторлар да батып кала. Сөт ташый торган машиналар бистәләргә, авылларга бик авырлык белән барып җитә. Ә «ашыгыч ярдәм» ролендә исә җигүле ат кына йөри ала. 1960 еллар азагында Татарстан районнарында юллар әнә шундый булган. Кукмара районында да хәлләр шулайрак торган.

– Мәктәпне тәмамлап, һөнәр сайлаган чагым иде. Казан инженерлык-төзелеш институты (хәзер – Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты – ред. иск.) проспекты кулыма эләкте. Шуны укыгач, кызыксынып киттем. Әнә шулай итеп юл төзелеше факультетына укырга кердем. Һәм анда Кукмара районыннан иң беренче студентларның берсе булдым – нигәдер безнең төбәктән миңа кадәр андый белем алырга теләүче табылмаган. Гаиләдә исә мин беренче юл төзүче булдым – аңарчы финансистлар гына иде, – дип сөйли Александр Герасимов.

Профильле белем алганнан соң, ул үз районына кайта һәм Кукмара юл-төзелеш идарәсенә эшкә урнаша.

ЧҮМЕЧЛӘП САНАДЫК...

Үзең төзегән юл буйлап беренче тапкыр грейдерда узу онытылмаслык хис-тойгылар уята! Шул бәхетле мизгелләр бәрабәренә булса да, көн-төн бер үк төрле ялыктыргыч хезмәт белән шөгыльләнеп, юл дигән нәрсәнең исе дә булмаган урында яңа трасса түшәү кирәктер инде ул.

Һөнәр серләрен үзләштерүдә Александр Анатольевичка тәҗрибәле остазлар – Кукмара юл-төзелеш идарәсе җитәкчесе Равил Хәсәнов, аның урынбасары Фаил Газизов, баш инженер Зоя Сухарева һ.б. ярдәм итә. Кукмара районы нәкъ менә шундыйлар тырышлыгы белән тәүге яхшы юлларга ия була.

– Ул вакытта төзелеш технологияләре бөтенләй башка иде. Хәзер без асфальтсыз юлларны күз алдына да китермибез, ә ул чакта асфальт әле барлыкка гына килде. 1983 елда Кукмарада асфальт-бетон заводы һәм битум чыгару цехы ачылды, үз «КАМАЗ»ларыбыз булдырылды, квалификацияле хезмәткәрләр барлыкка килде, һәм без юлларга асфальт сала башладык, – дип искә ала Александр Герасимов. – Хәзер бу заводта асфальт-бетон җитештерү буенча чит ил линиясе көйләнгән, ул компонентларның нисбәтен автомат рәвештә билгели. 80 нче елларда исә безгә бу компонентларны якынча процентлар нисбәтендә экскаватор чүмече белән үлчәргә туры килде.

УРАП УЗУ ҖИҢЕЛ ТҮГЕЛ

Шул ук вакытта совет чорында булдырылган кайбер технологияләр заманча технологияләрдән һич калышмый. 2010 нчы еллар уртасына кадәр Кукмара заводында дистәләрчә ел хезмәт итәргә сәләтле материаллар җитештерелгән. 2010 нчы еллар башында районга «Татавтодор» генераль директоры Айрат Шәймиев килде һәм Кукмара юлларының әле 2000 нче елларда ук салынуын белгәч шаккатты. Юлларның сыйфаты белән бик канәгать калды.

Александр Герасимовның иң яраткан объектларыннан берсе – Кукмараны урап узу юлы.

– Кешеләр, ник трассаны турыдан гына төзеп булмый соң, дип бик еш сорау бирә. Ә эш шунда ки, «туры» юл салынасы җирдән күп кенә коммуникация – торбаүткәргечләр, газүткәргечләр уза, кайчак төзелеш вакытында бик иске каберлекләр һ.б. шундыйлар табыла. Боларның барысын да, бөтен төзелеш нормаларын һәм кагыйдәләрен саклап, ясалма корылма, юлүткәргеч һәм күперләр ярдәмендә урап үтәргә кирәк. Кукмараны урап узу юлында, мәсәлән, тимер юл аша юлүткәргеч төзергә туры килде. Әмма Татарстанның башка юл-төзелеш идарәләрендәге коллегаларыбыз ярдәмендә без бу трассаны 1,5 ел эчендә эшләп чыктык. Хәзер инде ул, әлбәттә, төзекләндерүгә мохтаҗ, юл өслегендә дулкын пәйдә булды. Ләкин әлеге трасса 20 елдан артык хезмәт итте.

КЕШЕЛӘР, НИК ТРАССАНЫ ТУРЫДАН ГЫНА ТӨЗЕП БУЛМЫЙ СОҢ, ДИП БИК ЕШ СОРАУ БИРӘ. Ә ЭШ ШУНДА КИ, «ТУРЫ» ЮЛ САЛЫНАСЫ ҖИРДӘН КҮП КЕНӘ КОММУНИКАЦИЯ– ТОРБАҮТКӘРГЕЧЛӘР, ГАЗҮТКӘРГЕЧЛӘР УЗА, КАЙЧАК ТӨЗЕЛЕШ ВАКЫТЫНДА БИК ИСКЕ КАБЕРЛЕКЛӘР Һ.Б. ШУНДЫЙЛАР ТАБЫЛА. БОЛАРНЫҢ БАРЫСЫН ДА ЯСАЛМА КОРЫЛМАЛАР, ЮЛҮТКӘРГЕЧЛӘР, КҮПЕРЛӘР ЯРДӘМЕНДӘ САК КЫНА УРАП УЗАРГА КИРӘК.

ЮЛ ТӨЗҮЧЕ – ГАИЛӘ ҺӨНӘРЕ

Александр Герасимов бу тармакта 45 ел хезмәт куя, күп төрле зур һәм кечкенә проектларны гамәлгә ашыруда катнаша. Күптән түгел ул пенсиягә чыга, әмма хәзер дә әлеге тармакның хәл-әхвәле белән кызыксынып тора. Юл төзекләндергән яки яңа юл салган җирләрдә «үз кеше»ләрен күрсә, туктарга, гәпләшеп алырга тырыша.

Бу һөнәргә биргән бер көненә дә үкенми ул, мәхәббәте шулкадәр көчле була ки, Александр Анатольевичның кызы Светлана да әтисе юлыннан китә.

КИЛЕ – РИЗЫКЛЫ БУЛУ

Руфия Фазылова

«Татарстан» журналы көнкүрештән төшеп калган шөгыльләрне барлауны дәвам итә. Бу юлы без киледә карабодай төйдек. Өлкән буын хәтерлидер, кабыклы карабодайны суда пешерәсең, аннан мичтә киптерәсең. Шуннан инде килегә салып төясең. Әле 1980 нче елларда да авылларда бу эш киң таралган булган. Бүген исә киле музей экспонатына әйләнде.

КУЛДАН-КУЛГА ЙӨРИ ТОРГАН ЭШ КОРАЛЫ

Әлки районының Карга авылында яшәүче Чулпания апа Фәттахованың балачагы, аннан соңгы гомере дә киле белән эшләп узган. Ни кызганыч, үзенең әлеге эш коралы сакланмаган. Күпме эзләп тә, авылда киле сакланып калган гаиләне тапмадык. Шуның өчен дә Чулпания апа белән Базарлы Матакта урнашкан С. М. Лисенков исемендәге тарих-туган якны өйрәнү музеена бардык.

Чулпания апага киләсе елга 85 яшь тула, күз тимәсен, үз яшен биреп булмый аңа. Көләч йөзле, сөйкемле бу апа Карга авылының остабикәсе. Дингә лаеклы ялга чыккач килгән. Мәрхүм җәмәгате Наил абый белән өч ул, бер кыз тәрбияләп үстергәннәр. Балаларының барысы да башлы-күзле, икесе Базарлы Матакта, берсе Чаллы шәһәрендә яши. Төпчек улы Илгизәр исә төп нигездә калган.

– Киленем Гөлназ белән егерме сигез ел бергә яшибез, – диде Чулпания апа. – Әйтергә дә куркам, бик матур торабыз. Тату гаилә дип йөриләр безне авылда. Оныкларга да рәхмәт, хөрмәт итәләр. Дөньялар тыныч булып, алга таба да шулай яшәргә язсын...

Әнә шундый изге теләктә Чулпания апа белән эшкә керештек. Алда әйтелгәнчә, киледә төю өчен карабодайны башта пешерергә, аннары киптерергә кирәк. Шунсыз аны кабыгыннан арындырып булмый. Музейда эшләүче кызларга рәхмәт, без килгәнче Әлки районының үзендә үстерелгән карабодайны әзерләп куйганнар иде. Әбекәй кабыклы карабодайны килегә салды. Һәм кисапны (карабодай төя торган эш коралы) алып төя башлады. Чират кызларга да җитте: карабодайның кабыгы бик җиңел генә купмый икән. Мин исә килене «өйрәнәм»: эче шоп-шома, түгәрәк. Баксаң, аны яндырып ясаганнар.

– Киле бөтен гаиләдә дә юк иде, – ди Чулпания апа. – Ул шулай кулдан-кулга йөри торган эш коралы булды. Һәр авылның балта осталары булган, көндәлек тормышта нәрсә кирәк, бары-

Фото: Илнар Әметбаев

сын да ясаганнар. Имән түмәренең эчен башта балта белән юнып, шул рәвешле тирән итеп чокыганнар. Аннан исә ышкылап җибәреп шомартканнар һәм яндырганнар. Бу инде ярылып китмәскә дә яхшы булган.

«ӘТИ ЯКЛАП КАЛДЫ...»

Киледә карабодай төйгән арада Чулпания апа балачак хатирәләре белән уртаклашты. Гаиләдә тугыз бала үсә алар. Бөек Ватан сугышы башлангач, яше олырак булганга, әтиләрен фронтка җибәрмиләр, хезмәт армиясенә алалар. Ленинград өлкәсендә хәрби заводта эшләп, күзләре дөм сукырая. Нәтиҗәдә, сигез бала атасын гаиләсе янына кайтарып җибәрәләр.

– Авыр заманалар иде ул, бездә генә түгел, бөтен иле белән, – диде Чулпания апа. – Кышын – бәрәңге, җәен исә умачлы кычыткан ашы белән тукландык. Сугыштан соң колхоз җирләренә күпләп тары утырта башладылар. Әнә шул тарыны киледә төеп, аннан аны он итеп тарттырып, тел йотарлык тәмле ризыклар – ипи, коймак, кыстыбый пешерә идек. Аның тәмлелеген сөйләп аңлата торган түгел... Әле дә шуларны уйласам, күзгә яшь килә.

Карабодай төйгән чакларны да бик яхшы хәтерли Чулпания апа. Тик ул соңрак, үсмерлек чорына туры килә. Тарыдан аермалы буларак, карабодай затлы ризык саналган, чөнки ул юк дәрәҗәсендә булган. Шуның өчен дә аеруча кадерле, тансык була ул.

– Карабодайның уңышы бик яхшы чыкмагандыр, – ди әбекәй. – Югыйсә аны да басуга чәчәләр иде. Күрәсең, үстерә белмәгәннәр. Үстергәч тә, аны кабыгыннан арындырып бирмиләр иде. Хәзерге кебек чиста карабодай сатып алу турында хыялланмадык та. Чиста карабодай 1970–1980 нче елларда гына кибетләргә кайта башлады. Анысы да авылларда түгел, шәһәрдә генә дип истә калган. Танышлык белән яки зур чиратлар торып кына алдылар.

Чулпания апаның күңелендә балачак бәйле гыйбрәтле бер истәлек яши. Ул аны бүген дә күз яшьләре белән искә ала.

...Әнисе үсмер кызга киледә төелгән тарыны мич башына менгерергә куша. Ул шулай эшли дә: тарыны иләп кенә чүлмәккә салып, мич башына куя. Кичен кызга әнисе тары боткасы пешерергә вәгъдә итә. Әнә шул мизгелне көтеп йөргән арада, Чулпания никтер мич башына менеп төшәргә уйлый. Ә кире төшкәндә, күлмәк итәге белән чүлмәкне эләктерә һәм... савыт идәнгә төшеп китә. Нәтиҗәдә тары идән буйлап чәчелә, ә чүлмәк чәлпәрәмә килеп ватыла. Үсмер кыз үкереп елый башлый...

– Әни эштән кайткач кыйнар дип бик курыктым, – ди Чулпания апа. – Калтырана-калтырана тарыны җыярга керештем. Аны ничек җыеп бетерәсең? Өстәвенә чүлмәк ватыклары да катышкан. Бәхетемә, ишектән әти килеп керде. «Әти, ялгыш булды...» дим. Ул мине кочаклап алды. Әнидән кул тидертмәде...

ҖИЛПУЧСЫЗ БУЛМЫЙ!

Әнә шулай күңелләр нечкәреп, әбекәйнең балачак истәлекләрен тыңлаган арада, кызлар карабодайны кабыгыннан төшерделәр. Ләкин эш әле аның белән генә бетми икән: чистартырга кирәк. Моның өчен Чулпания апа киледәге карабодайны иләккә салды. Бу иләк хикмәтле, без бүген куллана торганга охшамаган – тимердән ясалган ул. Кабыгыннан аерылган чиста карабодай бөртекләре әнә шул тимер иләк тишекләре аша җилпучка коелып бара икән. Бу яңа сүз кызларга аеруча кызык тоелды, бөтенләй ишеткәннәре юк бит. Ә элек җилпуч һәр гаиләдә булган, он иләргә, кайнар ипи куеп торырга – бөтен җирдә аны кулланганнар.

– Без карабодайны болай иләккә салмый идек, чөнки ул юк иде, – ди Чулпания апа. – Югыйсә калайны тишеп иләк ясау авыр эш булмагандыр да, анысын төгәл генә әйтә алмыйм. Без киледә төелгән тары, карабодайны җилпучка салып, чүбен очырта гына идек. Ишегалдына чыгасың да авыз белән өрәсең: кабык җиңел, очып китә. Калганын исә кул белән чистартып атасың. Әнә шулай яраклашасың инде, кем ничек булдыра ала.

...Бүген рәхәттә яшибез. «Әбидә кунакта» тапшыруын төшергән саен, шундый нәтиҗәгә киләм. Май атлыйсы, мич ягасы, су ташыйсы, кер юасы... юк. Ә бит әле өч-дүрт дистә ел элек кенә боларның барысын да хатын-кыз үзе башкарган, чөнки ирләр күбрәк эштә булган. Әйе, без бәхетле чор балалары, берүк шушы рәхәтебез кителә күрмәсен.

Халык әйтсә, хак әйтә:
Исәбенә күрә хисабы, килесенә күрә кисабы. Килегә салып су төймиләр.

Язманың видеоварианты да бар.

«СКИНМЕД» ЯШЬЛЕККӘ КАЙТАРА

«Социаль челтәрләрдәге фотоларда табигыйлек җитми», «Җиңелчә макияжлы гап-гади йөзләрне күрәсе килә», «Кабартылганлыгы күренеп торганнарына караганда, идеаль булмаган иреннәр яхшырак» – популяр блогерларның бу постларында берничә ел элек эстетик медицинага ныгып кереп урнашкан юнәлеш – табигыйлеккә йөз тоту чагылыш таба.

Дистәләрчә ел дәвамында камилләштерелеп эшләнгән инновацияле процедуралар кулланганда гына, организмга зыян китермичә, табигый матурлыкка мөмкин кадәр якынаеп була. Клиник тикшеренүләр максималь нәтиҗәлелек һәм куркынычсызлыкны гарантияли.

– Инновацияле һәм шул ук вакытта тиешенчә сертификацияләнгән ысуллар күп түгел, операциясез яшәртү кебек юнәлештә бигрәк тә. Косметология тармагында сыналган традицион алымнар бик күп һәм аларның кайберләре миңа, белгеч буларак, бик ошый иде. Франциядә миңа пикосекундлы лазер* эшен күрсәткәнче, – ди Казанның «СкинМед» косметология клиникасы директоры Гүзәл Галиева. – Мин аппаратның тире белән бәйле проблемаларны хәл итүдә нәтиҗәлелеген үземдә сынадым һәм пациентларыбызның бу процедуралардан файдалану мөмкинлеге һичшиксез булырга тиешлеген аңладым.

Бу бик җитди карар иде, чөнки аппарат кыйммәтле, хәзер бөтен Россиягә алар нибары сигез генә данә. Пикосекунд лазер куллану башка процедуралар белән ирешеп булмый торган нәтиҗә бирә.

Технологиянең тагын бер «суперсәләте» – пигментлы таплар һәм җөйләр белән көрәшүе.

– Безгә еш кына проблеманы башка ысуллар белән хәл итә алмаганнан соң килмәләр. Пикосекундлы лазер тире эчендәге күзәнәкләргә көчле фотомеханик йогынты ясый. Аның бер өстенлеге – биттәге карасу пигментлы таплар, уңышсыз/искергән татуаж яки татуировка кебек төрле эстетик кимчелекләрдән котылырга булышу, – ди Гүзәл Галиева. – Бу вакытта тиредә яңару, күп күләмдә коллаген барлыкка килү процесслары активлаша. Нәтиҗәдә, тиредә җиңелчә табигый ялтыравыклык пәйда була, аның сыгылмалылыгы, сузылучанлыгы арта, сәлперәйгәнлеге бетә, лифтинг ясала һәм җөйләр тартыла.

Башка бер операциясез технология – Альтера-терапия яшь белән бәйле кайбер үзгәрешләрне, мәсәлән, җәелеп киткән йөз рәвешен кире кайтарырга, борыннан ирен читенә киткән сырларны, муендагы сырларны бер (!) процедурада ук бетерергә мөмкинлек бирә**. Бу – дөньяда тукымаларның хәлен микрофокусланган (ягъни максималь куркынычсыз һәм нәтиҗәле) ультратавыш белән реаль вакытта күрсәтә торган бердәнбер процедура. Төп төгәл билгеләнгән тирәнлектә тиренең эчке катламнарын җылыту аша, яңа, дөрес коллаген һәм эластин синтезы башлана, бу исә бит тиресенең тартылуына һәм яшәрүенә китерә.

Альтера-терапиянең нәтиҗәсе теләсә кайсы яшьтә дә табигый булып күренә. Әлеге технологияне үз иткән күренекле шәхесләр арасында АКШ актрисасы Дженнифер Энистон, Россия алып баручысы һәм виджее Артур Цветков кебек шоу-бизнес йолдызлары бар.

– Бу процедуралар 30 яшьлек пациентларга да, 60 яшьлекләргә дә ярый. Иң мөһиме – организмнең хәлсезләнгән чагына туры килмәсен, ә рационда аксымнар булуы мөһим – алардан башка тиредә яңа коллаген ясала алмый. Калган очракларда Альтера-терапия куркынычсыз, нәтиҗәле*** һәм пациентның яшенә карамастан, кискен тыкшынуны таләп итми, – ди Гүзәл Галиева. – Сүз уңаеннан, быел без әлеге методикаларга хәләл сертификаты алдык, ул исә мондый ысулларның мөселман хатын-кызлар өчен дә рөхсәт ителгәнлеген раслый.

Процедурага кадәр

Процедурадан соң, 180 көн

Процедурага кадәр

Процедурадан соң, 450 көн

Процедурага кадәр



Процедурадан соң, 120 көн

Процедурага кадәр

Процедурадан соң, 90 көн

* *Пикосекунд лазер белән йөз тиресен тарттыру – тиренең өске катламнарына стимуллаштыргыч тәэсир ясый торган операциясез косметик процедура. Пикосекундлы лазер шулай ук бетчәләрдән соң калган җөйләрне, пигментлы тапларны, яра эзләрен, татуировкаларны бетерү өчен кулланыла.*

** *Альтера-терапия (Ultherapy®) – реаль вакыт режимында визуаллаштыру белән микрофокусланган ультратавыш ярдәмендә йөз тиресен тарттыру һәм сырларны киметү өчен кулланыла торган дөньяда бердәнбер операциясез технология.*

*** *Процедуралар алдыннан белгеч белән киңәшләшү таләп ителә.*

Фото «СкинМед»компаниясе тарафыннан бирелгән. РЕКЛАМА
ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

мәңгелек
кыйммәтләр /
игелекле
эшләр
акыллы
гамәлләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Газиз Гобәйдуллин **нинди** мирас калдырган

Кабан арты мәчете **кайчан** төзелгән

Кайсы авылда чын каһарманнар яши

Иң матур разведчиклар **кайда** яши

ТАТАРНЫҢ БЕРЕНЧЕ ТАРИХ ПРОФЕССОРЫ

Илдус Заһидуллин



Энциклопедик белемгә ия, тарих фәненнән татарлар арасында беренче профессор, фәнни хезмәтләре бүген дә әһәмиятен югалтмаган олуг галим. Сүз империя чорында Казан университетын тәмамлаган һәм совет тарих мәктәбенә яраклашып эзләнүләр алып барган, Сталин репрессиясе корбаны булган трагик шәхес – Газиз Гобәйдуллин турында бара. Быел татар җәмәгатьчелеге аның тууына 135 еллыкны билгеләп үтте. Кызганыч ки, әлегәчә аның язма мирасы XX йөз башы фикер ияләре арасында да иң аз фәнни әйләнешкә кертелгәннәр исәбендә кала бирә.

Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 922 2022 1100 еллыгы

ШӘКЕРТЛЕК ҺӘМ СТУДЕНТ ЕЛЛАРЫ

Газиз Гобәйдуллин 1887 елның 26 июнендә Казанда I гильдия сәүдәгәре, Ш.Мәрҗани шәкерте Салих Сабит улы гаиләсендә туа. Мул, җитеш тормышлы, патриархаль традицияләргә корылган татар гаиләсендә үсә. Яшьтән үк ауга йөрергә маһир була.

Сигез яшендә малайны кадим «Халидия» мәдрәсәсенә укырга бирәләр. Әтисе Салих улын гыйлемле шәкерт итеп тәрбияләү юлында акча кызганмый, әйтик, фарсы телен өйрәтергә репетитор ала, яшүсмер фарсы әдәбияты, бигрәк тә Сәгъди һәм Фирдәүси иҗаты белән кызыксынып китә. Шулай ук рус телен, тарих, фәлсәфә кебек фәннәрне, гарәп, төрек телләрен өйрәнә. Төрек теле аша Европа әдәбиятына күз сала: Жюль Верн, Вольтер, Руссо һ.б. язучыларның төрекчәгә тәрҗемә ителгән китапларын укый.

Газизнең өлгер характерлы шәхес булганын әйтеп үтү урынлы булыр. Гаиләдә җитез малайга «Тыр-тыр Вафа» дигән кушамат тагалар, ә татар яшьләре арасында ул радикаль рухлы, реформалар таләп иткән «әл-Ислах» хәрәкәтенең кызу канлы шәкерте, укучы яшьләрне туплаган «Шимбә» театр түгәрәгенең оештыручыларның берсе буларак танылa.

Зиһенле егет, әтисенең сәүдәгәр итү теләгенә каршы килеп, 1906 елда университетта уку теләге белән яна башлый, махсус укытучылар белән шөгыльләнеп, француз, алман, грек һәм латин телләрен һ.б. фәннәрне өйрәнә. Имтиханнарны уңышлы тапшыру һәм Казанның 3 нче гимназиясе аттестатын алу аңа 1909 елда Казан университетының юридик факультетына укырга керергә мөмкинлек бирә. Бер елдан соң ул, тарихчы профессорлар М.М.Хвостов һәм Н.Н.Фирсов киңәшен тотып, тарих-филология факультетына күчә. Бу күчү аның киләчәк язмышын билгеләгән зур вакыйга була.

Егет 1909 елны якын дусты Гафур Коләхмәтовның сеңлесе Суфияга гашыйк була, ләкин әтисе каршы чыккач, өйләнү фикереннән кайта. Газиз 1914 елны Казан сәүдәгәре Мөхәммәтшакир Казаковның кызы Рәбига туташка өйләнә һәм, гаилә башлыгы буларак, эшкә урнаша – «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә тарих укыта башлый.

Студент елларында тарихи темаларга каләм тибрәтүе фәнни-оештыру эше белән үрелеп бара. Аның турыдан-туры катнашында Ш.Мәрҗанинең тууына 100 ел тулу уңаеннан «Мәрҗани мәҗмугасы» әзерләнә. Шушы проект кысаларында Гобәйдуллин «Мәрҗани хатирәсе» (1914), «Мәрҗанинең голум, фөнүн вә сәнаигъка карашы» (1915), «Мәрҗанинең тарихи хезмәтләре» (1915) исемле историографик пландагы мәкаләләр яза һәм Шиһабетдин хәзрәтнең гыйльми эшчәнлегенә югары бәя бирә. Газиз, этисеннән үтенеп сорап, аның матди ярдәме белән шушы җыентыкны бастырып чыгаруга ирешә. Аның диплом эше XIII гасырның икенче яртысында Алтын Урдада булган, Евразия буйлап сәяхәт иткән итальян галиме Марко Поло турында языла һәм 1915 елда «Шура» журналында басыла.

Гобәйдулин 1916 елны университетны беренче дәрәҗә диплом белән тәмамлый.

Фотолар автордан алынды

ЯЗУЧЫ ҺӘМ ТӘНКЫЙТЬЧЕ

1905 ел азагыннан Казанда бер-бер артлы татарча газеталар басыла башлый. Публицистика һәм әдәби әсәрләр бастыру, фикер алышу һәм үстерү өчен мәйдан киңәя. Газизнең «Чын төш» исемле хикәясе 1907 елны «Казан мөхбире» газетасында дөнья күрә. Аның хикәяләре татар зыялыларын үз тирәсендә туплаган «Аң» журналында да басыла.

Бу әсәрләр матбугат битләрендә милләт киләчәге турында ачыктан-ачык сөйләшү йогынтысында барган бәхәсләрдә катнашу формасында, иҗтимагый фикергә йогынты ясау максатында язылган. Газизнең гыйльми әзерлеге теоретик темаларга алынырга мөмкинлек бирә. Аның милләткә биргән билгеләмәләре бүген дә үз әһәмиятен саклый: «Милләтнең асылы тарихи ганганәләргә (традицияләргә), хатирәләргә теркәлгән була, ягъни бер милләттән булган кешеләр бер-берсенең якынлыгын хис итә, һәркайсының бабасының бабалары вә нәселләре бер дошманга – дошман, бер дуска – дус була; бер җирдә торганга яисә бергә күчеп йөргәнгә халык тарихын җырлар кыяфәтендә күңелдә саклыйлар. Шулай итеп, бер милләткә хазир рухи бер тәгъриф бирәбез: милләт – тарихи ганганәләре бер булып, берлек хис иткән адәмнәрнең җыеныдыр». Яки: «Милләт – тарихи ганганәләре бер булып, үз араларында берлек хис кылынган, бер юл тарткан – бергә хәрәкәт иткән һәм бер даирәдәрәк яшәгән яисә тарихта күп вакыт бергә торган, асыл–телләре бер булган ифрат адәмнәрнең җәмгыятедер».

Газизнең тәнкыйть мәкаләләре Гаяз Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» (1911) повесте, Галимҗан Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» (1913) романы, Гафур Коләхмәтов, Сәгыйть Рәмиев әсәрләре басылу уңаеннан языла.

Әдәбият фәнен өйрәнүче галимнәр Гобәйдуллинның иҗтимагый фикерне үстерүдәге ролен әдәби сүзнең әһәмиятен тирәнтен аңлап иҗат иткәнлегеннән чыгып бәяли, аның юмор һәм сатира остасы булуын ассызыклый. Ул, чыннан да, татар әдәбиятына яңа темалар алып килгән язучы.

Аның «Юлдаш эзләгәндә» (1916) хикәясе иманны югалту темасына багышланган. Төп герой – гомере буе диндар булып яшәгән Ильяс ун ел элек Аллаһка ышанычын җуя; яшәү мәгънәсен эзләп китапларга, мәшһүр фәлсәфәчеләрнең әсәрләренә мөрәҗәгать итә; ахыр чиктә әлеге мәсьәләне һәр кеше үзе хәл итәчәк дигән фикергә килә. Автор, шул рәвешле, татар җәмгыятенә секуляризация процессы йогынтысында барлыкка килгән бер күренешне тасвирлый.

Язучының «Бер хыял» (1913) исемле фәлсәфи хикәясе җир йөзендә мәңгелек тынычлык, дуслык булган вакыттан соң җәнлекләр һәм кешеләр дөньясында башланган сугыш, үтереш турында сөйли. Автор тормышта газап чигү һәм явызлыкның булуы мәҗбүри түгел, алардан котылырга мөмкин, дигән фикер уздыра. Моның

Газиз Гобәйдуллин (султан беренче) һәм язучы Гафур Коләхмәтов (султан дүртенче) дуслары белән кымыз эчәргә баргач. 1913 ел.

өчен кеше явызлык кылмыйча, яхшылык кылып яшәргә тиеш, ягъни мәрхәмәтлелек мәңгелек кыйммәт дәрәҗәсендә тәкъдим ителә.

Газиз 1917 елгы инкыйлабка кадәр татар җәмәгатьчелегендә, нигездә, яшь язучы һәм тәнкыйтьче буларак кабул ителә. 40 тан артык әдәби әсәр яза, 1918-1919 елларда аның әдәби әсәрләре хикәяләр җыентыгында дөнья күрә.

КАЗАНДАГЫ ЭШЧӘНЛЕК

Университет дипломлы яшь белгечкә губерна хакимияте Казанда эшкә урнашырга мөмкинлек бирми. Шул сәбәпле Троицк шәһәрендә татар укытучылары әзерли торган уку йортларының берсендә укыта, биш сыйныфлы «Вазифа» исемле мәдрәсәдә мөдирлек итә.

1917 елгы Октябрь инкыйлабыннан соң Гобәйдуллин туган шәһәренә кайта һәм, тарих дәреслекләренә булган ихтыяҗны исәпкә алып, «Борынгы заман тарихы», «Диннәр тарихы», «Россия тарихы» һ.б. дәреслекләр язып бастыра.

Мөмкинлек туугач, 1919 елны Казан университетының тарих кафедрасына аспирантурага керә, Н.Ф.Катанов һәм Н.Н.Фирсовлар җитәкчелегендә гыйльми дәрәҗәсен күтәрү, белемен тирәнәйтү белән шөгыльләнә. Университет каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең даими әгъзасы итеп сайлана, аның рәисе урынбасары булып та эшли, шулай ук Кызыл Армиянең Казандагы пехота курсларында уку-укыту эшләре мөдиренең ярдәмчесе вазифасын башкара.

1921 елны аспирантураны уңышлы тәмамлагач, Көнчыгыш академиясендә, Көнчыгыш педагогика институтында һәм Татар коммунистик университетында тарих фәннәре укыта. Татар югары уку йорты дип уйланылган Көнчыгыш академиясен оештыручыларның берсе була. Бу елларда ул «Хәзәр каһанлыгының тарихи тәҗрибәсе» исемле зур гыйльми хезмәтен тәмамлый.

Югары квалификацияле белгечләргә кытлык заманында Гобәйдуллин Татарстан АССР Авыл хуҗалыгы белеме идарәсе рәисе урынбасары булып та эшли.

Аның тарихи хезмәтләре нигездә 1921 елда Мәгариф халык комиссариаты каршында оешкан Гыйльми үзәк хезмәткәре буларак язылган. Гыйльми үзәкнең күпсанлы бурычлары арасында иң мөһиме дип татар тарихын язу юнәлешен атарга кирәк. 1921–1925 елларда Газиз Гобәйдуллинның гыйльми эшчәнлеген шушы яссылыкта бәяләү мөһим.

Яңа совет тарих фәнендә академик М.Н.Покровскийның «сәүдә капиталы» турында теориясе өстенлек итә. 1920 нче елларның беренче яртысындагы сүз иреге һәм милли күтәрелеш шартларында М.Н. Покровский концепциясе рус булмаган халыкларның милли тарихларын язарга юл ача. Бу мөмкинлектән Академ үзәк җитәкчелеге, Михаил Худяков, Газиз Гобәйдуллин, Гали Рәхим, Җамал Вәлиди уңышлы файдалана. Татар милли тарихының һәм мәдәнияте тарихының матур үрнәкләре шушы галимнәр тарафыннан языла һәм алар киләчәк буын галимнәре өчен нигез ташына әверелә.

Концептуаль фундаменталь хезмәт «Татар әдәбияты тарихы» атарга кирәк. Бу хезмәтне Гобәйдуллин туганнан туганы (әниләре бертуган) – күренекле әдәбият галиме, тарихчы Гали Рәхим белән берлектә яза. Галимнәр татар мәдәни тарихын беренче булып Орхон-Енисей ташъязмаларыннан алып тикшерәләр. Әлеге фундаменталь хезмәт ике зур чорны колачлый: «Борынгы дәвер» һәм «Иске әдәбият» (XVII–XIX гасырлар). Авторлар борынгы төрки һәм Алтын Урда чорында язылган әсәрләр – Евразия киңлекләрен биләгән күпсанлы төрки халыкларның уртак язма мирасы дигән фикер үткәрә. Кызганыч, бу хезмәт әлегәчә кириллица белән бастырылганны көтеп ята.

1924 елда Гобәйдуллинның татар этногенезына багышланган «Борынгы болгарлар» һәм «Татарларның килеп чыгышы һәм Алтын Урда» исемле хезмәтләре дөнья күрә.

1922 елда Газиз Гобәйдуллин беренче булып милли мәктәпнең югары сыйныф укучылары өчен Европа тарихы традицияләренә нигезләнгән «Татар тарихы» исемле дәреслек бастыра. Анда күчмәннәрнең тормыш рәвеше һәм хуҗалык төзелеше, борынгы төркиләрнең мәдәнияте һәм язма традицияләре, Һун, Хәзәр каһанлыклары һәм Идел-Чулман Болгар дәүләте, Алтын Урда оешу, Казан, Әстерхан, Нугай һәм Себер «урдаларының» кыскача сәяси тарихы, икътисады һәм хуҗалык төзелеше, мәдәнияте бүлекләргә бүлеп бәян ителә. Революциягә кадәр Гобәйдуллин милләтен төркиләрнең бер өлеше, аларның дәвамчылары дип исемләсә, хәзер татар дип яза.

Галимнең фәнни эзләнү юнәлешләрен совет хакимияте билгеләгән елларда, М.Н.Покровскийның «сәүдә капиталы» турында теориясенә таянып, ул татарларда сый-

Газиз Гобәйдуллин һәм Гали Рәхим. 1925 ел.

ныфлар тарихы буенча берничә хезмәт яза. Сыйныфлар дип морзаларны, дин әһелләрен, йомышлы татарларны, сәүдәгәрләрне, дәүләт һәм алпавыт крестьяннарын бүлеп чыгарып, этрафлы рәвештә аларның социаль һәм хокукый хәлен, саннарын һәм урнашкан төбәкләрен бәян итә. Чынлыкта татарларның җирбиләүчеләре «чабаталы морзалар» булып, аларны рус алпавытлары белән янәшә куеп булмый. Мөселман руханиларын да сыйныф буларак бәяләү хата, алар татарларның интеллектуаль социаль төркемен тәшкил итә. Крепостной крестьяннар бик аз санда, аларны сыйныф итеп чыгару урынсыз була.

Гобәйдуллинның киң масштабта эзләнүләренең нәтиҗәсе буларак оешкан тагын бер фәнни юнәлеше дип татарларда сыйнфый көрәш тарихын марксизм-ленинизм күзлегеннән язуын атарга кирәк. Ул татарларның Степан Разин (1670–1671 еллар) һәм Емельян Пугачев (1773–1775 еллар) җитәкчелегендәге крестьян сугышларында катнашулары турында, шулай ук хакимияткә каршы башка чыгышларга багышланган мәкаләләр һәм китаплар бастыра.

Историография буенча фәнни юнәлешне дәвам итеп, Гобәйдуллин 1922–1925 елларда Каюм Насыйриның язма мирасын өйрәнү һәм күренекле татар мәгърифәтчесенең әсәрләрен җыентыкларда бастыру өлкәсендә җиң сызганып эшли.

1920 нче еллар уртасында Казанда кайбер тарихчыларны эзәрлекләү башлана. Сәүдәгәр улы, 1917–1918 елларда татар милли азатлык хәрәкәтендә актив катнашып, Милли Шура башкарма комитеты әгъзасы, Милләт мәҗлесе депутаты, Идел-Урал штатын гамәлгә кертү һәйәте әгъзасы буларак эшләгән шәхес буларак эзәрлекләү шаукымы татарлар арасыннан Гобәйдуллинга да кагыла.

БАКУ ЧОРЫ

Эшсез калгач, ул 1925 елда гаиләсе белән Бакуга күчеп китәргә мәҗбүр була. Биредә эшләгән вакыты – Газизнең галим буларак җитлеккән еллары. Галим, Казанда башлаган фәнни юнәлешен дәвам итеп, Азәрбайҗанда феодализм җәмгыяте һәм бу җәмгыятьтәге вакыфлар, ефәк җитештерү тарихы турында хезмәтләр яза. 1927 елда профессор гыйльми дәрәҗәсе алуга ирешә. Бер үк вакытта Үзбәкстан ССР Гыйльми үзәге белән хезмәттәшлек итә. Үзбәк телендә үзбәкләрнең килеп чыгышы турында хезмәтен тәмамлый. Аның Кабарда-Балкарда феодаль мөнәсәбәтләр тарихы турында фәнни хезмәт язганы да билгеле.

Бакуда Гобәйдуллин Азәрбайҗан Республикасында тарих фәнен һәм милли югары белем системасын оештыруга үзеннән зур өлеш кертә. Бүген дә аның Азәрбайҗан университетының Шәрык факультетын һәм Югары педагогика

«Шимбә» татар яшьләре түгәрәге әгъзалары. Арттагы рәттә (сулдан уңга) Газиз Гобәйдуллин, Шакир Мөхәммәдьяров. Алдагы рәттә: Зәйнәп Габитова, Гайшә Богданова, Х.Хәлим, Мәрьям Гобәйдуллина, Рабига Габитова. Казан, 1906 ел.

институтын оештыруда, европача методиканы үзләштергән чын белемле тарихчы кадрлар әзерләүдә ролен югары бәялиләр.

1928 елда Сәмәркәнд югары педагогика институты профессоры, 1930 елда Мәскәү университеты профессоры итеп сайлана, бу югары уку йортларында лекцияләр укый.

1931–1933 елларда Газиз Гобәйдуллин Азәрбайҗан Үзәк башкарма комитеты каршындагы фәнни-тикшеренү институтының тарих секциясе җитәкчесе булып эшли.

1934 елда Гобәйдуллин, Казанга кайтып, Марксизм-ленинизм фәнни тикшеренү институтында, Казан университетында эшли, бер елдан кабат Бакуга китә: Азәрбайҗан университетында Шәрык факультеты деканы, төрки-татар халыклары тарихы кафедрасы мөдире, Якын Көнчыгыш тарихы кафедрасы мөдире вазифаларын башкара.

1937 елда контреволюцион эшчәнлектә гаепләнеп кулга алына һәм атып үтерелә. Кулга алганда галимнең соңгы елларда язылган хезмәтләренең кульязмалары конфискацияләнә, чекистлар аларны югалта.

Исеме 1957 елда аклана.

Күренекле татар галименең 1989 елда Тел, әдәбият һәм тарих институты тарафыннан әзерләнгән, башлыча 1920 нче елларда язылган фәнни хезмәтләре тупланган «Тарихи сәхифәләр ачылганда» исемле сайланма әсәрләре җыентыгы дөнья күрә.

Сүз ахырында Газизнең сеңлесе – татар хатын-кызлары арасында беренче этнограф, ТАССРда музей эше белән актив шөгыльләнгән, экспонатлар туплаган, 1925 елдан Бакуда эшләгән Мәрьям Салих кызын (1892–1933) һәм шулай ук этнограф, татар аш-суы һәм борынгы тәңкәләр турында хезмәтләр авторы, репрессиягә эләккән энесе Габделкадыйр Салих улын (1888–1944) искә алу урынлы булыр. Гобәйдуллиннар өчесе дә татар гуманитар фәне үсеше өчен һәркайсы үз урынында тырышып хезмәт итә һәм бай гыйльми мирас калдыра.





922
2022
Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы



КАЗАНДА КАБАН АРТЫ МӘЧЕТЕ

Әлеге иман йорты, истәлекләргә караганда, күп гасырлар элек легендар Колмәмәт мәчете – шәһәрнең агачтан салынган беренче гыйбадәтханәсе урынында калкып чыккан. Аның төзелешенә рөхсәтне йөз ел элек Сталин үзе имзалаган дип сөйлиләр...

Кабан күле ярындагы мәчетнең тарихы риваятьләргә шулкадәр бай, әйтерсең лә, ул йөз ел гына түгел, мең еллар элек тә булган. Аклы-кызыллы манарасы булган бу мәчет, уңай килеп торганга түгел, бәлки, каршылыклар күп очраганга калкып чыккандыр кебек тоела. Дин әһелләрен илдән сөрелгән һәм чиркәү байлыклары тартып алынган большевиклар чорында мәчет төзү һәм ачу – бу илаһи көчләр катнашыннан башка мөмкин хәл түгелдер кебек. Гәрчә баштарак бөтен дөнья моңарга каршы кебек булса да.

Фото: Әскәр Сабиров

ШӘҺӘРНЕҢ «РУС» ӨЛЕШЕНДӘ БЕРЕНЧЕ МӘЧЕТ

Яңа мәчетне җирле мөселманнар олуг юбилей – Идел буе Болгар дәүләте тарафыннан ислам динен кабул итүнең 1000 еллыгына туры китерәләр. Урынын да дөрес сайлыйлар – истәлекләр буенча, монда, Кабан күле ярында, беренче агач мәчетне кайчандыр Болгардан килгән Кабанбәк кенәз фикердәше Колмәмәт имам төзеткән. Агач мәчет Явыз Иван Казанны алганчыга кадәр торган, дип сөйлиләр, мәчет яндырыла, әмма җирле мөселманнар әле бик озак вакытлар дога кылырга дип хәрабәләр урынына киләләр...

Кабан арты мәчете шәһәрнең «рус» өлешендә (калганнары барысы да татар бистәләрендә урнашкан) төзелгән беренче мөселман гыйбадәтханәсе булырга тиеш була. Сукно бистәсенең эшчеләр районында бу вакытта инде шактый татар кешесе яши, татар сәүдәгәрләре биредә кибетләр тота, ә инде дини йолаларны үтәргә урын булмый.

Мәчетнең проектын Казан архитекторы Анатолий Печников эшли, акча җыю оештырыла, ләкин төзелешне башларга Беренче бөтендөнья сугышы комачаулый. Аннан соң – революция, Гражданнар сугышы, соңрак большевиклар дингә каршы көрәш башлый. Мәчеткә илтүче юллар ябыла кебек тоела...

ҖИМЕРЕКЛӘР ФОНЫНДА ИМАН НУРЫ

1919 ел. Дәүләтнең диннән аерылуы турындагы декрет кабул ителүгә бер ел, большевиклар чиркәү милкен рәхәтләнеп кыра, христиан храмнарында изгеләрнең җәсәдләрен ачу буенча кампания башланып китә. Әлеге фонда Галимҗан Баруди җитәкчелегендәге Россия Диния нәзарәтенең Казанда яңа, исәп буенча 18 нче мәхәллә ачуга рөхсәт бирүе үзеңә үзең кул салуга тиң була. Шулай да кайбер нечкәлекләргә күз салырга кирәк. Ул чакта большевиклар беренче чиратта революциягә кадәр дәүләт статусына ия булган бердәнбер конфессия – православие гыйбадәтханәләренә каршы көрәшә, калган диннәргә әлегә вакыты җитми...

Мәчет төзелеше бары тик биш елдан соң гына башлана, чөнки илдә – сугыш, җимереклек, ачлык... һәм сугышчан атеизм. 1924 елга нәрсәләр үзгәрә соң? Илдә яңа икътисадый сәясәт хөкем сөрә, большевиклар шәхси инициативага ирек биреп, икътисадны торгызырга тырыша. Аларның чиркәүләргә мөнәсәбәте дә үзгәрә. Дингә каршы алып барылган көрәш совет хакимиятенең дошманнарын арттыра һәм сәясәтне йомшартырга мәҗбүр итә, бигрәк тә мөселман һәм яһүдиләргә карата, чөнки башка дин вәкилләрен дә үз якларына тарту мөһим була. Алмашка «яңа дини сәясәт» чоры килә. 1923 елның 16 августында ҮК генераль секретаре Иосиф Сталин хәтта губерна комитетларына чиркәүләрне ябуны һәм дингә бәйле кулга алуларны тыю турында күрсәтмә дә юллый.

Әлбәттә, Казан мөселманнары Кабан арты мәчетен салуга рөхсәтне Сталинның шәхсән үзеннән алмый, чөнки ул мондый эшләр белән вакланып тормый. Җирле хакимияткә килгәндә исә, икенче мәсьәлә: ТАССР ХКС рәисе Кәшшаф Мохтаров һәм хөкүмәт милли үзаңның үсүен хуплый, этник һәм конфессиональ тигезсезлекне бетерергә омтыла...

60 ЕЛДАН СОҢ

Халык акчалары һәм хакимиятнең кысылмавы үз эшен эшли. Нигез ташын салып, мәчетнең купшы манарасына ярымай беркеткәнгә кадәр ике ел вакыт үтә. Төзелеш материалларына кытлык та киртә була алмый: диварның бер өлешен янгын чыгып җимерелгән шәһәр театры урыныннан җыялар. 1926 елда мәчеттә беренче азан яңгырый...

Мөселманнар яңа иман йортын «Юбилей мәчете» дип атый. Тагын бер исеме – «Исламны кабул итүнең 1000 еллыгы». Мәчетнең архитектурасы да мондый исемне аклый кебек. Өч катлы манарасы гына да ни тора: һәр кат Казан мөселманнары тормышының өч чорын чагылдыра – исламны кабул иткәнгә кадәр, урта гасыр һәм хәзерге заман. Мәчет эшчеләр бистәсенең иске агач корылмалары өстеннән калкып тора. Ул Түбән Кабан күле ярының каршы ягы – татар йортларыннан һәм күрше урамнардан да яхшы күренә. Манара һәм фасадның бизәлешендә кулланылган көнчыгыш һәм Мавритания мотивлары мәчеткә кабатланмас үзгәлек өсти.

Мәхәлләнең имам-хатыйбы Борнай мәчете мулласының улы Абдулхалик Кулиев була. Ләкин аңа Кабан арты мәчете мөнбәреннән җомга вәгазьләрен озак укырга насыйп булмый. Кайбер мәгълүматлар буенча большевиклар мәчетне ачылуга ук диярлек ябалар. Икенче төрле мәгълүмат буенча – ул әле 1930 елга кадәр иман нуры тарата. Ул чакта дингә каршы көрәш чираттагы биек ноктасына җитә һәм мәчетне ТатҮБК Президиумы карары нигезендә ябалар.

Алга таба барысы да гадәттәгечә бара. Манарадан ярымайны алалар, кыйммәтлерәк саналган әйберләрне тараталар. Бинада берникадәр вакыт балалар бакчасы, соңрак мәктәп һәм ДОСААФ бүлеге урнаша. Бәхеткә, манараны җимермиләр – анысы өчен дә рәхмәт.

1991 елда – СССР җимерелә башлаган чорда мәчетне дин тотучыларга кире кайтаралар. Бүген биредә барысы да элеккечә: манара очында ярымай балкый, мөселманнар намазга җыела, мәдрәсә эшли.

Адресы: Казан, Һади Такташ ур., 26

Мөселманнар яңа иман йортын «Юбилей мәчете» дип атый. Тагын бер исеме – «Исламны кабул итүнең 1000 еллыгы».

Татарстан авылары

ЯҢА КЕНӘР: ЧЫН ИРЛӘР МОНДА ЯШИ

ЯҢА КЕНӘР

Һәр районның зур, атаклы авыллары бар. Арча районының Яңа Кенәр авылы әнә шундыйлар рәтендә. Заманында ул хәтта район үзәге булып торган. Бүген авыл ничек яши? Ни өчен борчыла? Нәрсәгә сөенә?

Руфия Фазылова

ЗАМАНЧА АВЫЛ

Яңа Кенәрдә 2100 кеше яши, 600 хуҗалык исәпләнә. Социаль объектлардан биредә барысы да бар. Авылларда бик сирәк очрый торган оешмалардан дарухәнә, зур сәүдә үзәге, көндезге стационарга кадәр эшли.

600 урынга исәпләнгән яңа мәктәп кенә ни тора! Белем үзәге күренекле авылдашлары – укытучы, Социалистик Хезмәт Герое Стелла Зәки кызы Габдрахманова исемен йөртә. Бүген биредә 270 укучы белем ала.

Урта мәктәп белән бергә, авылда тагын бер мәгариф учреждениесе – сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен интернат-мәктәп тә эшли. Биш районнан килгән 147 бала шунда яшәп, белем һәм тәрбия ала. Укытудан тыш, аларны биредә хезмәткә дә өйрәтәләр. Ял көннәрендә балаларны өйләренә алып китәләр.

Яңа Кенәрдә заманча мәдәният йорты да халыкка хезмәт күрсәтә. Узган ел аңа 20 миллион сумлык капиталь төзекләндерү үткәрелгән.

Фермер хуҗалыклары, агач эше белән шөгыльләнүче берничә эшкуар, ике шиномонтаж, дистәгә якын шәхси кибет – кыскасы, биредә халык ни белән генә шөгыльләнми. Шулай да авыл халкы эш урыннары аз дип борчыла, элегрәк күп булган. Баксаң, 2000 нче елларга кадәр Яңа Кенәрдә егермеләп (!) оешма исәпләнгән. МТС, Сельхозтехника кебек зур оешмалар ябылган. Шуңа күрә ирләрнең шактые читкә йөреп эшли. Казан белән Яңа Кенәр арасы – туксан чакрым, күпләр сменалы эш сайлап, башкалага барып хезмәт итә.



1
Зур штык-пычакны Мәскәүдә яшәүче әфганчы авылдашлары Ильяс Фазылҗанов ясатып кайткан.

2
Яңа мәчет Яңа Кенәрдә 2001 елда төзелде.

Авыл халкы участок хастаханәсен дә сагынып искә ала. Заманында анда катлаулы булмаган операцияләргә кадәр ясаганнар. Бер дигән табиблар эшләгән. Бөтен тирә-як авыллар дәваланырга Яңа Кенәргә йөргән. Шунда ук бәби тудыру йорты да булган. Тик 2000 нче елларда үзгәртеп корулар нәтиҗәсендә хастаханә эшләүдән туктаган. Бүген аның бинасы килгән кешеләргә вакытлы торак сыйфатында файдаланыла.

БАТЫРЛАРНЫҢ ИСЕМЕ – МӘҢГЕЛЕК

Яңа Кенәрдә бер һәйкәл игътибарны җәлеп итте. Мәктәпкә терәлеп үк тора ул. Әйтерсең, балаларны җил-давылдан саклый... Һәйкәл ике яклы. Бер ягы Бөек Ватан сугышында катнашкан авылдашлары хөрмәтенә эшләнгән. Икенче – яңарак ягы локаль сугышларда – Әфганстан, Чечня, Таҗикстан, Сүриядә катнашкан батыр егетләргә багышлана. Анысы әле 22 сентябрь көнне генә ачылган. Һәйкәлгә «локаль сугышларда, сугыш хәрәкәтләре һәм хәрби конфликтларда» катнашып, «хәрби бурычларын намус белән үтәгән ветераннарга» дип язылган. Яңа һәйкәлне Яңа Кенәр авылы егетләре тулысынча үз акчаларына ясаткан.

– Егетләр төрле сугышларда катнашкан авылдашларга һәйкәл ачу тәкъдиме белән чыкты, – диде Яңа Кенәр авыл җирлеге башлыгы Әгъзам Гайфуллин. – Киләсе елга үзсалым акчасына планга кертербез, дип сөйләшкән идек. Без планга керткәнче, егетләр аны эшләп тә куйды. Ул яктан Яңа Кенәр бик күп авылларга үрнәк – бик бердәм халык яши бездә. Сабан туе кебек бәйрәмнәрне, төрледән-төрле чараларны күтәреп алырга гына торалар. Күпме кирәк, шуның кадәр акчасын күчерәләр.

Авылда Рашат Салихҗанов турында берничә кешедән ишеттем. Ул 1982–1984 елларда 371 нче мотоукчылар полкы составында Әфганстанның Шинданд шәһәрендә хәрби хезмәттә булган. Туган ягына исән-сау әйләнеп кайткан. Бүген Рашат Салихҗанов Кенәр җирлегенә кергән авылларда яшәүче әфганчыларны бер учта тота. Үзмәшгульлек – агачтан төрле эшләнмәләр җитештерү белән шөгыльләнә. Һәйкәл кую турында сүз чыккач та, ул читтә яшәүче авылдаш дусларына, башка районнардагы әфганчыларга мөрәҗәгать итә. Эшне бик тиз тоталар. Ай ярым дигәндә һәйкәл әзер дә була.

– Һәйкәл ачылышын бер атна алдан, 22 сентябрьгә дип планлаштырган идек, – диде җирлек башлыгы. – Ә 21 сентябрь көнне исә илдә өлешчә мобилизация игълан ителде. Шулай туры килде. Баштарак аптырап та калсак та, планлаштырган чараны күчермәдек. Нәтиҗәдә һәйкәл ачу патриотик кичәгә әйләнде. Бу турыда хәтта «Беренче канал»дан да сөйләделәр.

Һәйкәл үзенчәлекле: аның бер ягына зур штык-пычак урнаштырылган. Аны бүген Мәскәүдә яшәүче әфганчы Ильяс Фазылҗановның Түбән Новгородтагы әфганчы дуслары ясап биргән. Һәйкәл янында өч зур таш тора, аларны да махсус кайтартканнар. Әфган, Чечня, Сүрияшул фаҗигаләрнең шомлы истәлеге.

Батырлар турында сүз чыккач, авыл җирлеге башлыгы бер сан әйтеп шаккатырды: мобилизацияләнгән егетләргә дип, халык 650 мең сум акча җыйган. Бу эш әле һаман дәвам итә икән.

– Җирлектән әлегә унтугыз егет өлешчә мобилизациягә әләкте, Яңа Кенәрдән генә дә унбер егетне озаттык, – диде Әгъзам Гайфуллин. – Акчаның бер өлеше егетләргә кием-салым сатып алырга тотылды. Әйе, дәүләт аларга бер кат кием бирә. Ләкин алар полигонга чыга, анда кар, яңгыр ява, димәк, юешләнәләр. Алмашка бер киемсез булмый. Иң беренче җылы резина итекләр, эчке киемнәр кирәк. Бияләй, плащ, балаклава, җылы оекбаш, рюкзак – кимендә егерме мең дигән сүз. Күп итеп медикаментлар сатып алдык. Әле менә егетләр гуманитар ярдәм җыярга, дип әйтә. Ничә кеше шул тәкъдим белән чыкты. Район администрациясенә шалтыратып, тәртибен белештек.

Авыл җирлеге башлыгы еш кына «егетләребез» дип сөйләшә. Һәр эштә дә башлап йөрүчеләр, ярдәм итүчеләр бар икән. Алар барысы да Яңа Кенәр егетләре. Аларның күбесе читтә яши. Җитәкче аларның исем-фамилияләрен атамады, чөнки үзләре теләми икән. Чөнки алар өчен туган авылыңа булышу – үзеңне күрсәтү түгел, ә гадәти хәл...

«АГАЧ ЭШЕ КҮҢЕЛГӘ ТЫНЫЧЛЫК БИРӘ»

Бу якларда гомер-гомергә балта осталары күп булган. Иң кызыгы – бүген дә авылда шул кәсепне дәвам итүче ир-атлар шактый. Төзелеш эшләрендә йөрүче ир-атлар күп, агачтан төрле җиһазлар ясау киң таралган. Каен агачыннан өстәл, урындык, карават, аш-су бүлмәсе кирәк-яраклары – барысын да ясыйлар. Авылның өч шәхси эшмәкәре Арча районын гына түгел, күршеләрне дә агач җиһазлар белән тәэмин итеп тора. Шундый булдыклыларның берсе – Азат Хәйруллин. Агач эшенә керешкәнче, кибетләр тоткан. Соңрак исә тынгысыз тормышын тынычракка алмаштырган. Авыл башында ул агач цехы янына зур гына йорт та салып куйган.

– 2013 елда шушы җирне сатып алып, цех ачтым, – диде Азат Хәйруллин. – Агач эшенә хирыслык кечкенәдән дип уйлыйм. Мәктәптә агач остаханәсе бар иде. Хезмәт дәресләрендә гел әнә шунда агачларны ышкылап, юнып, төрле әйберләр ясый идек. Шуңа күрә дә авыл малайларының күбесе бу шөгыльнең асылын белә.

3 Әзер булгач, такталарны ышкылыйлар, кисәләр, станокта бизәкләп чыгаралар.

4 – 2013 елда шушы җирне сатып алып, цех ачтым, – диде Азат Хәйруллин.

5 – Ике бабаем бар инде. Алар күптәннән монда эшли.

6
Тәскирә Лотфуллина сеңлесенең кызы Люция Әхмәтгәрәева янәшәсендә.

7
Авылдагы иң иске бина бүген кибет буларак хезмәт итә.

Җиһазлар өчен такта материалларын Азат Мари Эл Республикасыннан алып кайта икән. Киптерер өчен, аларны махсус җылыга – цехка алып кереп өяләр. Агач юеш булса, дөрес кипмәсә, җиһаз ярыла, шуның өчен дә махсус җайланма белән тактаның дымлылыгын тикшерәләр. Әзер булгач, такталарны ышкылыйлар, кисәләр, станокта бизәкләп чыгаралар.

– Ничә кеше эшли? – дим Азатка.

– Ике бабаем бар инде. Алар күптәннән монда эшли. Яшьләрне бу эшкә бик тартып булмый. Аларга күп акча кирәк.

Җәен цехта эш туктабрак тора – авыл кешесенең печән вакыты, башка эшләре бар. Көзен исә цех тулы куәтенә эшли башлый. Заказлар күп икән.

Җиһазларның бәяләре белән дә кызыксынам – артсыз утыргыч 1759 сум, артлы урындык 3500 сум, өстәл – зурлыгына карап – 7000 сумнан башлана. Зурая торган өстәлләр – 16–17 мең сум тирәсе. Җиһазларны төрле төсләргә буйыйлар. Халык ак, агач төсендәгеләрне яратып ала икән.

Буяу эшләрен Азат үзе башкара – моның өчен аерым бүлмә бар. Бүлмә җилләтелә. Урындыклар калын тукыма белән тышлана.

– Тукыманың төсен, бизәген заказ бирүче үзе сайлый, – диде Азат. – Гадәттә урындык белән бергә өстәлгә дә заказ бирәләр. Тулы бер комплект була.

– Сезнең җиһазлар ничә ел хезмәт итә? – дим.

– Урындык белән сугышмасалар, гомер буена җитә инде (көлә). Бу кәсебтә күп акча эшләп булмый, әлбәттә. Ләкин аның икенче ягы бар: яратып эшләсәң, күңелгә тынычлык бирә. Шуның өчен дә агач эшен ташламыйм.

АВЫЛНЫҢ АКЪӘБИСЕ

Авылларга баргач та, хөрмәткә лаек берәр өлкән кеше белән очрашырга тырышабыз. Алар белән аралашуы кызык: үткәннәрне хәтерлиләр, тарихны беләләр, һәр җөмләләре мәгънәле. Яңа Кенәрдә без әнә шундый Акъәби – Тәскирә Лотфуллина белән таныштык. Тиздән сиксән сигез яшен тутыра икән әбекәй.

– Шушы нигездә бабаем Габделфәт белән гомер иттек, – дип сүзен башлады ул. – Биш ел да җиде ай армиядә хезмәт итеп кайткан егет иде без өйләнешкәндә. Бик матур яшәдек. Бердәнбер кызыбыз Надияне дә бергә җирләдек... Бер елдан үзе дә дөнья куйды.

Әйе, картлык көнендә Тәскирә әби бик зур фаҗига кичергән: йөрәк өянәгеннән кызы вафат булган. Әни кеше кызы белән бүген дә бик горурлана. Надия апа күп еллар Яңа Кенәр мәктәбен җитәкләгән. Эшчән, киң күңелле мөгаллимәне хезмәттәшләре безнең алда да зур ихтирам белән искә алды.

– Надиябез эштән туктап биш кенә ай яшәп калды, – диде әбекәй. – Гел эш, балалар дип янып торды. Ике кызы калды, алар Казанда яши. Минем янга кайтып, ярдәм итеп торалар. Рәхмәт, бертуганнарымның балалары да ташламый. Социаль хезмәткәр билгеләделәр, бик булыша. Үземне ялгыз хис итмим. Менә аякларым гына начар йөри, егылган идем, шуннан рәте китте.

Тәскирә Лотфуллина Яңа Кенәр авылында туып үскән. Сугыш чоры баласы. Әтиләре сугыштан гарипләнеп кайткан.

– Мәктәптә яхшы укыдым, – дип дәвам итте ул. – Яңа Кенәрдә ун класс тәмамлагач, Казан авыл хуҗалыгы институтына укырга кердем. Тик торыр урын булмагач, кире авылга кайтып киттем.

– Яңа Кенәрдә шул чагында урта мәктәп бар идеме? – дим.

– Бар иде. 1924 елда бездә башлангыч мәктәп ачылган, ә 1932 елда ул җидееллыкка әйләнгән. 1936 елдан урта мәктәп буларак эшли башлаган. Мин сугыш башлангач укырга кердем. Укулар бер көнгә дә туктамады. Әйтәм бит, авыл зур, көчле иде. 1929 елда Яңа Кенәрдә «Красная звезда» колхозы оешкан. Шуннан соң тегү һәм киез итек басу артельләре, икмәк пешерү йорты, сәнәгать комбинаты ачылган. Шул чорларда балалар бакчасы да эшли башлаган. Сугыш башланмаса, халык ничек рәхәт яшисе булган да бит. Эх...

Авылга кайткач та, Тәскирә Лотфуллина колхозда эшләп ала, аннан соң интернат-мәктәпкә бухгалтер булып эшкә керә. Яңа Кенәрдә ул чагында ятимнәр, күп балалы гаиләләрдән булган балалар өчен интернат эшләгән. Анда 280 бала тәрбияләнә иде, дип искә төшерә Тәскирә әби.

– Интернатта берничә ел эшләгәч, авыл советына сәркатип итеп эшкә алдылар, – диде әбекәй. – Лаеклы ялга чыкканчы – утыз елдан артык шунда эшләдем. Эшнең күплеге! Ул чагында Яңа Кенәрдә утыз ике оешма бар иде. Барысының да документларын тәртипләп тотарга кирәк бит.

Яшьләрне өйләндерү, йортларны теркәү, ике айга бер сессия, айга ике утырыш уздыру һ.б. – барысы да аның аша уза. Компьютерфәлән юк, бөтен документларны кул белән тутырып, районга илтеп тапшырасы. Төн буе утырган вакытлары күп була аның. Авыл советында эшләү дәверендә авылдашлары хөрмәтен казана ул.

Тынгысыз ханым лаеклы ялга чыккач дин юлына баса. 1995 елда дин гыйлемен өйрәнү өчен авылда унике кешелек төркем оеша. Араларында Тәскирә апа да була. Гарәпчә өйрәнәләр, Коръән уку, мәет юу тәртипләрен үзләштерәләр. Шулай итеп әбекәй авылның хөрмәтле абыстаена әйләнә. Күп еллар ул шул вазыйфаны башкара.

– Безнең авыл динле булган, – дип сөйләде Тәскирә Лотфуллина. – Беренче мәчет 1828 елда төзелгән, диләр. Икенчесе 1860 елда сафка баскан. XX йөз башына авылда дүрт мәчет булган. Совет власте урнашкач, аларның барысы да юк ителгән. Ә мәчет бипалары мин белгәндә дә әле амбар, кибет, мәктәп булып хезмәт итте. Яңа мәчет Яңа Кенәрдә 2001 елда төзелде. Ике катлы, гаҗәп матур итеп эшләделәр аны. Аңа сөенгәннәребез... Авылыбызны динле итүдә Ирек хәзрәт Галиевнең роле бик зур. Унҗиде кешене Хаҗга алып барып кайтты ул. Бүгенгесе көндә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлаган абыстайлар мәчет бинасында балаларга, олыларга дин сабаклары укыта.

– Совет заманында авылда динне качып тоттылармы? – дим.

– Әйе. Ир-атлар гаетне зиратта, аерым йортларда укыды. Җомга намазына да җыелалар иде. Яңа Кенәрдә дин кануннары үтәлмиме дип, авыл советыннан гел сорап тордылар. «Юк» кына дип хисап тоттык...

...Зур авылларны санаулы сәгать эчендә йөреп чыгу мөмкин түгел. Язар, күрсәтер кешеләр күп була. Яңа Кенәрдә дә шулай: авылда гаҗәеп үзенчәлекле кешеләр яши. Мине исә аеруча Яңа Кенәрнең ир-атлары таң калдырды. Чын ир-ат булуларын алар сүз белән түгел, эш белән күрсәтә.

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

Люция Әхмәтгәрәева, лаеклы ялдагы мөгаллимә:

- Авылга XVII йөз ахырында Иске Кенәр авылыннан күченүчеләр нигез салган дип фаразлана. Революциягә кадәрге чыганакларда Бигәш, Мәмсә исемнәре белән дә билгеле. Авыл турында икенче бер риваять бар, без аны балалар белән төрле конференцияләрдә сөйли идек. Мәмсә авылыннан ерак түгел Ясангул бабай яшәгән. Аның тугыз улы булган. Һәм ул балаларын тирә-якны өйрәнергә җибәргән. Сулы урынга йорт салырбыз, дигән. Уларның берсе Яңа Кенәр урынында төпләнгән.

ГИПО – УҢЫШ СТРАТЕГИЯСЕ

27 ноябрьдә «Гамәли оптика дәүләт институты» Фәнни-җитештерү берләшмәсе» АҖ генераль директоры, дүрт дистә елга якын үз эшенә тугры булган Виллен Балоевка 60 яшь тула, хәзерге көндә предприятиенең уңышлы эшчәнлеге аның исеме белән тыгыз бәйләнгән.

ФӘН ҺӘМ ҖИТЕШТЕРҮ АЛДЫНГЫСЫ

Бүген Виллен Арнольдович җитәкчелегендәге «Гамәли оптика дәүләт институты» (ГИПО) Фәнни-җитештерү берләшмәсе илнең оборона тармагына йөз тотып, нәтиҗәле хезмәт куя: оптик-электрон прибор һәм системалар проектлый һәм ясый, төрле корал комплекслары составына керә торган эшләнмәләрнең конструкциясен эшли, сыный һәм җитештерә. Берләшмә үз өлкәсендә әйдәп баручы предприятиеләрнең берсе булып тора, мондый алдынгылыкка продукциянең югары сыйфаты, аны тәртипле рәвештә озатып җибәрү, тәҗрибә-конструкторлык эшләренең оператив үтәлеше ярдәмендә ирешелә.

Галимнәр беркайчан да тик тормый, ГИПО продукциясе исемлеге өр-яңа эшләнмәләр белән гел тулылана килә. Әйтик, хәзерге вакытта эшчәнлекнең яңа юнәлеше – ерак арага очучы һәм стратегик авиациягә караган ракеталы самолетлар, шулай ук пилотсыз авиация комплекслары өчен навигация системаларының астровизация җайланмасын төзү юнәлеше үзләштерелә. Әлеге тиңсез аппарат очкычларга йолдызлар ярдәмендә ориентлашырга һәм курсны тотрыклы рәвештә көйләп барырга мөмкинлек бирәчәк. Предприятие авиация комплексларының (вертолетлар һәм транспорт самолетлары, хәрби һәм литералы (аеруча мөһим) авиация самолетлары) саклагыч лазер станцияләре кебек яңа төр кораллар өчен табу һәм төбәү системасын эшләү өлкәсендә дә илдә алдынгылык яулады.

РУЛЬДӘ ЧЫН ОСТА БУЛГАНДА!

Теләсә кайсы предприятиенең уңышын билгеләгән төп нигезләрнең берсе – аның җитәкчелеге. Нәкъ менә рульгә басучы кеше. Бу яктан ГИПОда, һичшиксез, барысы да яхшы. Генераль директор – гади инженердан берләшмә җитәкчесенә кадәр күтәрелгән, шушы оешмада тәрбияләнгән үз кеше.

Виллен Арнольдовичның тормышы инде 37 ел тулысынча ГИПО белән бәйләнгән, бу – аңа язылган эш һәм ул анда чын оста! Ул төрле җитештерү проблемаларын чишүгә рациональ караш, эшкә сәләтлелек, җаваплылык, искиткеч идарә итү осталыгы белән аерылып тора. Әлбәттә, ул – югары төгәллеккә ия оптик-электрон аппаратура эшләүдә бай тәҗрибәсе булган уңышлы галим дә. Бу сыйфатлар 2018 елда Виллен Балоевка кайчандыр аны, КДУның физика факультетын тәмамлаган яшь белгечне, үз кочагына алган предприятиене җитәкләргә мөмкинлек бирә.

ИЛ ИМИНЛЕГЕ САГЫНДА

Виллен Арнольдович предприятие эшләнмәләренең төп уйлап табучыларыннан берсе һәм баш конструкторы булып тора. Мәсәлән, танкка каршы ракета комплекслары һәм ут белән идарә итү системалары өчен җылылыкка сизгер төбәгечләрне ясый ул. Җылылыкка сизгер төбәгечләр тәүлекнең һәр вакытында һәм теләсә нинди һава торышында куллану мөмкинлеге хисабына техниканың сугыш шартларындагы нәтиҗәлелеген арттырды.

Баш конструктор буларак, Виллен Балоев зенитлы ракета-туп комплексларын, танклар һәм бронялы машиналарны җиһазлау өчен өченче буын җылылык сизү каналларын эшләүне җитәкләде. Хәзерге вакытта дәүләт заказы буенча да ясала, экспортка да җибәрелә торган комплекслар әлеге югары төгәллекле җылылык сизү каналлары белән җиһазландырыла.

Генераль директор эре оборона предприятиесе белән җитәкчелек эшен һәм фәнни эшчәнлекне бик оста алып бара. Ул – техник фәннәр кандидаты, фәнни һәм укыту-методик хезмәтләр авторы. Аның уйлап табуларга 95 патенты һәм таныклыгы, электрон-исәпләү машиналарының файдалы модельләре һәм программалары бар, шулардан 23 патент җитештерүдә кулланыла.

Виллен Арнольдович Россия ракета-артиллерия фәннәре академиясе киңәшчесе, «Ростех» дәүләт корпорациясе составына керән

Фото: «ГИПО ФҖБ» АҖ; Татарстан Президентының матбугат хезмәте. РЕКЛАМА

«Швабе» АҖ Фәнни-техник советы әгъзасы булып тора. Шулай ук ул – КМТТУ-КАИның оптик-электрон системалар кафедрасы мөдире дә әле.

Илнең оборона сәләтен үстерүгә һәм ныгытуга керткән хезмәте өчен Виллен Арнольдович Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының югары дәүләт һәм хөкүмәт бүләкләренә лаек була.

ТӨП БАЙЛЫК – КЕШЕЛӘР

Теләсә нинди предприятиенең көндәшлектә төп өстенлеге – талантлы хезмәткәрләр, кызыксынучан зирәк акыл ияләре һәм алтын куллар. ГИПО ФҖБ генераль директоры моны бик яхшы аңлый.

Булганны җентекләп саклап, коллектив предприятие тормышындагы яңа традицияләрне үстерә, иҗади атмосфера тудырырга омтыла һәм уртак уңыш һәркемнең эшенә бәйле булган зур командада бар хезмәткәр дә үз өлешен тойсын өчен тырыша.

Белемле идарәче һәм стратег буларак, Виллен Арнольдович талантлы яшьләргә һәрьяклап ярдәм күрсәтә, югары квалификацияле фәнни-техник кадрлар әзерләүгә зур игътибар бирә.

Җитәкчелек ярдәме белән предприятие хезмәткәрләре, төрле дәрәҗәдәге һөнәри осталык конкурсларында катнашып, югары нәтиҗәләргә ирешә. Мондый бәйгеләр исемлегендә – «Ростех» дәүләт корпорациясенең, Россиянең яшь инженерлар берлегенең «Вектор», «Техноспецназ», «Технолидер» кебек дәрәҗәле конкурслары һәм махсус программалары.

«ГИПО Фәнни-тикшеренү берләшмәсе» АҖнең 37 хезмәткәре төрле елларда Россия Президенты стипендиясен ала. Предприятиенең 84 белгече «Ел инженеры» Бөтенроссия конкурсының лауреаты һәм җиңүчесе булып тора.

Предприятие киләчәккә ышаныч белән карый, әмма үткәннәр турында да онытмый: лаеклы ялда булган ветераннарга, социаль яклауга мохтаҗ гражданнарга социаль партнерлык системасы кысаларында ярдәм күрсәтә, республиканың мәдәни кыйммәтләрен торгызуда катнаша.

– Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 26 августында имзаланган Указы нигезендә Виллен Балоев **ДУСЛЫК ОРДЕНЫ** белән бүләкләнде.

– «Ел җитәкчесе-2018» республика конкурсы нәтиҗәләре буенча генераль директор **«ИННОВАЦИЯЛЕ ЭШЧӘНЛЕКТӘГЕ КАЗАНЫШЛАРЫ ӨЧЕН»** номинациясендә лауреат булды.

– 2008 елда аңа **«РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕНЕҢ АТКАЗАНГАН МАШИНА ТӨЗҮЧЕСЕ»** исеме бирелде.

– ГИПО ФҖБ авторлар коллективы составында ул **РОССИЯ ХӘРБИ-ТЕХНИК ХЕЗМӘТТӘШЛЕК БУЕНЧА ФЕДЕРАЛЬ ХЕЗМӘТЕНЕҢ «АЛТЫН ИДЕЯ» МИЛЛИ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЫ** (2007 ел) исемен яулый.

– «Корнет» танкка каршы үзйөрешле ракета комплексын төзүдә катнашкан өчен, аңа **ФӘН ҺӘМ ТЕХНИКА ӨЛКӘСЕНДӘ РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕ** һәм **ФӘН ҺӘМ ТЕХНИКА ӨЛКӘСЕНДӘ РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЫ** исеме бирелде (2002 ел).

ГИПО

Хөрмәтле Виллен Арнольдович!

Якынлашып килгән юбилеегыз уңаеннан «ГИПО Фәнни-җитештерү берләшмәсе» АҖ коллективының ихлас котлауларын кабул итегез!

Профессиональ белемегез, бай тәҗрибәгез, зирәк җитәкчелегегез һәм һәрдаим алга омтылу теләге Сезгә эшегездә югары уңышларга ирешергә мөмкинлек бирә, предприятиенең финанслар ягыннан тотрыклы эшләвенә ярдәм итә. Сезгә хас иҗади энергия һәм хезмәт сөючәнлек киләчәктә дә берләшмәбезне үсешкә илтер, дип ышанабыз.

Сезгә озын гомер, рухи һәм физик көч, нык сәламәтлек, бәхет һәм иминлек телибез! Алга таба да Сезне киң колачлы планнар һәм искиткеч җиңүләр генә көтсен! Сезгә һәркайда уңышлар юлдаш булсын!

«ГИПО ФҖБ» АҖ коллективы

2022 елның 1 октябрендә Яр Чаллы шәһәрендә Виллен Балоевны Дуслык ордены белән бүләкләделәр.

РУХЫ ҺӘМ СӘЛӘТЕ БУЕНЧА ЛИДЕР

Югары һөнәри осталык, бурычны төгәл билгели һәм аны хәл итү юлларын ачыклый белү сәләте – болар «Татэнерго» АҖ Директорлар советы рәисе Илдар Халиковка хас кайбер сыйфатлар гына.

Рәүзил Хаҗиев,
«Татэнерго» АҖ
генераль директоры

Узган ел уртасында Илдар Шәфкать улын акционерлык җәмгыятенең Директорлар советы рәисе итеп яңадан сайлау турындагы карар бертавыштан кабул ителде. Әлбәттә, башкача булуы мөмкин дә түгел иде. Күзгә күренеп торганны расларга гына кирәк булды: «Татэнерго» активларын модернизацияләү буенча киң колачлы барлык проектлар 2012 елдан бирле Директорлар советын Илдар Халиков системалы һәм нәтиҗәле җитәкләгән чорда тормышка ашырылды. Бик зур эш башкарылды, дип коллективның исенә төшердем мин ул вакытта, предприятие менеджменты Директорлар советыннан һәрвакыт кирәкле ярдәмне алып торды.

Әйе, Илдар Шәфкатович сүз белән түгел, чын эш-гамәлләр белән үзен күрсәтүче җитәкчеләр арасыннан. Республикада ул премьер-министр булып эшләгән чорда тормышка ашырылган масштаблы проектларны искә төшерү дә җитә. Универсиадага әзерлек кысаларында башкала юл челтәрен тулысынча реконструкцияләү: ул чакта ике катлы 11 транспорт чишелеше, 40 тан артык җәяүлеләр кичүе, 29 юл, «Казан Арена» стадионы төзелде, «Казан» халыкара аэропорты яңартылды, «Казан-2» тимер юл вокзалы ачылды, аэроэкспресс йөри башлады, Иннополиска нигез салынды һәм торак төзелеше күләмнәре кискен үсте – бу әле гамәлгә ашырылган проектларның кайберләре генә.

Төп бурычларны билгеләү һәм коллективны аларны эзлекле рәвештә гамәлгә ашыруга юнәлтә, туплый белү осталыгын Илдар Халиков бүген «Татэнерго» АҖнең Директорлар советын җитәкләгәндә дә тулысынча күрсәтә. Шәп оештыручы, көчле финансист буларак, ул Татарстанның энергетика тармагын югары темплар белән үстерүгә күп көч куя, чөнки моннан башка республиканың тотрыклы икътисадый һәм социаль үсеше мөмкин түгел. Һәм монда да нәтиҗәләр бик күркәм. Компания базарда бәя буенча көндәшлек итә алсын өчен, үз вакытында активларны кичекмәстән һәм тулысынча яңартуны күз уңында тоткан бердәнбер дөрес курс сайланган иде. Модернизацияләү планнары Россия Хөкүмәтендә хупланды, ә компаниянең һөнәри командасы аларны вакытында һәм сыйфатлы итеп тормышка ашыра алды.

2014 елдан Казандагы 1 нче һәм 2 нче Җылылык-электр үзәкләрендә технологик процесслар тулысынча цифрлаштырылган пар-газ җайланмалары файдалануга тапшырылды, башка проектлар да гамәлгә ашырыла. Илдар Халиков билгеләп үткәнчә, «соңгы ун елда чын-чынлап алга сикереш булды, компания тарафыннан яңа объектлар төзелешенә бер миллиард доллар акча кертелде. Бу – күп кенә кешеләрнең, бөтен «Татэнерго» АҖ коллективының казанышы». Планнарда – алга таба да энергия куәтләрен яңарту. Бу Татарстанда кулланучыларны ышанычлы, бәйсез һәм көндәшлеккә сәләтле энергия белән тәэмин итү, сәнәгать җитештерүе үсешенең ирешелгән темпларын саклау мөмкинлеге бирәчәк.

Ирешелгән уңышларда тукталып калу да, объектив авырлыкларга зарлану да «Татэнерго» АҖ Директорлар советы рәисе холкына хас түгел. Бу җәһәттән күптән түгел узган Директорлар советы утырышларының берсен мисалга китерергә була. Анда предприятиеләрне, социаль-көнкүреш объектларын һәм Татарстан халкын тотрыклы рәвештә җылылык белән тәэмин итү мәсьәләләре турында фикер алыштылар. Вазгыять җиңел түгел: торбаүткәргечләрнең бер өлеше таушалган, ә аларны алыштыру өчен акча җитми. Шуңа да карамастан, Илдар Шәфкатович катгый курс билгеләде: җылылык челтәрләрен модернизацияләү мәсьәләсен чишү юлларын эзләүне берничек тә туктатырга ярамый, федераль программа акчаларын җәлеп итү мөмкинлегеннән максималь рәвештә файдаланырга кирәк. Аның сүзләренә караганда, модернизацияләү генә, ахыр чиктә, тиешле тариф әйләнешен саклап калырга, кулланылган җылылык ресурслары өчен түләүләрне арттырмаска мөмкинлек бирәчәк. Алдагылары кебек үк, Директорлар советы рәисе билгеләгән бу бурыч та һичшиксез уңышлы хәл ителәчәгенә ышанам.

Хөрмәтле Илдар Шәфкатович!

Сезнең бөтен хезмәт юлыгыз – республикага, аның кешеләренә намуслы хезмәт итү үрнәге ул. Сезне чын күңелдән туган көнегез белән котлыйм! Киң колачлы бурычларны хәл итү юлында янәшәгездә һәрвакыт чын профессионаллар, фикердәшләр, көрәштәшләр атлавын телим!

Фото: «Татэнерго» АҖнең алынды, tatar-inform.ru. РЕКЛАМА

КӨЧЛЕ ЭНЕРГИЯЛЕ ШӘХЕС

Кулы тигән һәр нәрсәне яхшырак итәргә, гадәти юлдан атлау мөмкин булмаган авыр хәлләрдән чыгу ысулларын табарга, проблемага башкача караш ташларга омтылучы, һәм шул ук вакытта, мәсьәләнең асылын югалтмыйча, ахыргы максатның нәрсә икәнен истә тотып эш итүче җитәкчеләр бар. Масштаблы, барысын да киңрәк күрә, тирәнрәк уйлый белүче, кешелекле, үз энергиясе белән башкаларны да рухландыручы һәм кыю максатларга илһамландыручы. Илдар Шәфкать улын без нәкъ менә шундый буларак беләбез.

Рифнур Сөләйманов,
«Татэнергосбыт»
АҖ директоры

Безнең уртак эшчәнлегебез республиканың энергетика тармагына карый. 2012 елда мине «Татэнергосбыт» АҖ директоры итеп билгеләделәр, ә Илдар Шәфкать улы компаниянең Директорлар советын җитәкли иде. Һәр мәсьәләдә ул вазгыятьне дөрес бәяли һәм 5, 10, 15 елдан соң мәсьәләнең үсеш перспективасын күрә белә. Ул һәрвакыт безнең компаниянең һәм коллективның потенциалы зур булуын билгеләп үтте. Кайчак безнең алдыбызга әлеге шартларда тормышка ашырылуы мөмкин булмагандай тоелган кыю бурычлар куйды. Ләкин алар барысы да реаль булып чыкты. Ул заманча тренд, тенденцияләргә һәм дөньядагы иң яхшы тәҗрибәләргә игътибар итә. Аның ярдәме белән «Татэнергосбыт» АҖ клиентлар белән коммуникацияләр каналын актив үстерә һәм дистанцион сервислар кертә башлады. Кулланучыларның компания белән аралашуының уңайлылыгы һәрвакыт өстенлекле булды. Максатчан ориентир – тулысынча цифрлаштырылган офис һәм дистанцион хезмәт күрсәтүне кертү. Электрон документ әйләнеше, компания сайтындагы шәхси кабинет һәм аның мобиль версиясе бүген кулланучыга, офиска килеп йөрмичә генә, беренчел документларны алырга, бурычларны карап барырга һәм түләргә, мөрәҗәгать һәм хатлар юлларга мөмкинлек бирә.

Уртак хезмәтебез чорында «Татэнергосбыт» АҖ ике тапкыр «Россиянең иң яхшы энергия сату компаниясе» булды. 2012 елдан башлап, даими рәвештә РФ энергия сату компанияләренең нәтиҗәлелек рейтингында беренче урыннарны били. Боларның барысына да сайланган курсның дөреслеге, ярдәм күрсәтелү һәм коллективның тырыш хезмәте нәтиҗәсендәирешелде.

Илдар Шәфкать улының компания коллективына аерым игътибарын билгеләп үтәсе килә. Ул һәрвакыт кешеләрдә һөнәри осталыкны бәяли, хезмәткәрләрне күркәм эшләргә рухландыра белә. Теләсә кайсы вазгыятьтә, шартларда да кешелеклелек – аңа хас булган төп сыйфатларның берсе.

Хөрмәтле Илдар Шәфкатович!

Бөтен коллективыбыз һәм шәхсән үз исемемнән сезгә рәхмәтебезне белдерергә һәм туган көнегез белән котларга рөхсәт итегез!

Яңалыкка, нәтиҗәлелеккә омтылу, финансистларча төгәллек, идарә итә белү, аралашу осталыгы – Сезнең эш стиленә хас сыйфатлар. Әлеге сыйфатлар, актив тормыш позициясе, максатчанлык, ныклы характер белән бергә, мөһим мәсьәләләрне хәл итәргә, энергетика тармагын һәм гомумән республикабызны үстерү максатында күп кенә юнәлешләрне һәм проектларны тормышка ашырырга мөмкинлек бирә.

Һәр көнегез – иҗади энергия һәм ирешелгән нәтиҗәләрдән канәгатьлек хисенә, һәр елыгыз якты мизгелләргә, бәхетле минутларга һәм истәлекле вакыйгаларга бай булсын. Алда, һичшиксез, кыю максатлар, рухландыргыч яңа казанышлар көтеп торсын. Янәшәгездә тугры дуслар һәм фикердәшләр атласын, ә уңышлар һәм якыннарыгызның кайгыртучанлыгы бетмәс-төкәнмәс дәрт-дәрман һәм иҗат чыганагы булып калсын. Үзегезгә, якыннарыгыз һәм туганнарыгызга бәхет, сәламәтлек телим!

Фотолар «Татэнергосбыт» АҖннән алынды. РЕКЛАМА

УРТА ГАСЫРЛАРДАН КИЛГӘН МӘХӘББӘТ САБАКЛАРЫ (16+)

17 ноябрь, 18:30
Г. Кариев исем. Казан Татар яшь тамашачылар театры,
Казан, Петербург ур., 55б

Китап – иң яхшы бүләк. Башкортостан режиссеры Илсур Казакбаев, илебез һәм чит ил әдәбияты классиклары әсәрләре буенча яңа, кыю спектакльләрне сәхнәләштереп, әлеге афоризмга яңа мәгънә сала.

Октябрьдә Г. Кариев исемендәге Яшь тамашачылар театры сәхнәсендә ул Шекспирның «Ромео һәм Джульетта»сын куя. Казакбаев куйган пьесада төп темаларның берсе – буыннар конфликты. 400 ел эчендә берни үзгәрмәгән: балалар ата-ана ихтыярына каршы бара, әти-әниләр балаларын өйрәтүдән туймый. Урта гасыр Италиясенең Верона шәһәрендә яшәүче Джульеттага яратмаган кешесенә кияүгә биргәндә хәтта бер генә атна да вакыт бирмиләр. Әгәр гаилә бу карарыннан баш тартса, нәрсә булыр иде? Мондый хәлләрдә бүгенге яшүсмерләр һәм аларның ата-аналары нишләр иде икән? Әлеге сорауларга режиссер версиясендәге җавапларны 17 ноябрьдә ишетергә һәм күрергә мөмкин.

ГРИШКОВЕЦ ҮЗЕ РОЛЕНДӘ (18+)

«Дөрес, мин искә төшерә алмаган тормыш мизгелләре дә бар. Бу нинди дә булса кичәдән соң булырга мөмкин. Ләкин бераздан дусларың килә һәм кичәге бәйрәмдә булган вакыйгалар чылбырын торгызырга булыша. Һәм әлеге чылбырны торгызу еш кына кичәнең үзеннән әйбәтрәк һәм кызыклырак булып чыга», – дип яза Евгений Гришковец үзенең «Планета» китабында. Бу формула күпмедер дәрәҗәдә Гришковецның үз иҗатын сурәтли: көндәлек тормыштагы гадәти әйберләр аның сөйләвендә кызыклы һәм дулкынландыргыч вакыйгага әверелә, кәеф күтәрелә (беренче чиратта үзебезнеке), ә янәшәндәгеләрнең шатлык-кайгылары аңлашыларак төшә. Шундый үзенә тартып торган тылсымга ия Евгений Гришковец ноябрь аенда Казан һәм Чаллы тамашачылары каршында чыгыш ясаячак. Ике сәгатьлек «Монолог-концерт» программасына төрле елларда язылган текстлар кергән. Аларның кайберләрен беркемнең дә ишеткәне юк, дип хәбәр итә оештыручылар. «Монолог-концерт» – авторны тамашачыга максималь дәрәҗәдә якынайта. Гришковец сәхнәгә беренче тапкыр моноспектакль персонажы ролендә түгел, бәлки үзе буларак чыгачак.

21 ноябрь,
19:00 – 21:00
«Уникс» мәдәни-спорт комплексы
Казан, Профессор Нужин ур., 2 бина

БОЛГАНЧЫК ЕЛЛАР КҮРЕНЕШЕ (16+)

Нәрсә ул бәхет? Аңа ирешеп, аны табып буламы, әллә ул мәңгелек эзләнүме? Фәрит Бикчәнтәевнең «Болганчык еллар. Мөһаҗирләр» спектаклендә әлеге әйтелгән һәм әйтелмәгән сораулар кабатланып тора. Татар язучысы Мәхмүт Галәүнең романтетралогиясе мотивлары буенча куелган спектакльнең тулы версиясе ноябрь аенда Г. Камал исемендәге татар театры сәхнәсенә чыга. «Болганчык еллар» романының төп вакыйгасы – Идел буенда 1877 елда ачлык. «Мөһаҗирләр» романы 1897 елгы халык санын алу нәтиҗәләре турында сөйли: татар авылларын көчләп чукындыруга каршы крестьян фетнәләре билгеләп алган. Нужа, ачлык, курку төп геройларны чит җирләргә куа, ләкин анда, ундырышсыз һәм кырыс җирләрдә дә, алар хыялллана һәм бәхет өмет итә. Фәрит Бикчәнтәев куелышындагы «Болганчык еллар. Мөһаҗирләр» спектакле сезонның төп премьерасы гына түгел, режиссер иҗатында иң мөһим эшләрнең берсе булырга дәгъва итә.

12 ноябрь, 18:00
Г. Камал исем. Татар дәүләт Академия театры,
Казан, Татарстан ур., 1

афиша

Фото: kariev teatr.ru, tatar-inform.ru

«СКА-ФОЛК-РОК-БАРДАК» СТИЛЕНДӘГЕ КИЧӘ (12+)

Казанда рок-хәрәкәт ничек пәйда булган һәм үскән, ул үз тирәсендәге мәдәниятне формалаштыруга нинди йогынты ясаган, танылган музыкантларның язмышы нинди, Советлар Союзы чорында, 90 нчы елларда рокерлар нәрсә турында җырлаган, бүгенге заман җырчыларын нәрсә рухландыра – әлеге һәм башка сорауларга җавапларны, шулай ук төрле елларга караган җырларны 16 ноябрьдә Казанда, «Волга-Волга» студиясендә узачак кичәдә ишетергә мөмкин булачак. «Татарстан» журналы һәм «Волга-Волга» ВИА төрле буын рок-музыкантларын, журналист һәм блогерларны ансамбльнең 25 еллыгын билгеләп үтәргә чакыра.

– 90 нчы елларда актлар залы артындагы кысан бүлмәдә оешкан төркемебез совет чорын һәм яңа дәверне бәйләүче күпер булды. Казанда яшьләрне иҗатка рухландыручы төркемнәр бар иде. Бүген исә без яңа буынны рухландырабыз, дип ышанам. Шул ук вакытта без үзебез дә әле яхшы музыка иҗат итәргә сәләтле, – ди «Волга-Волга» ВИА сәнгать җитәкчесе һәм алыштыргысыз солисты Антон Салакаев.

Бүген төркем елына 150 дән артык концерт бирә, шул исәптән хәйрия кичәләрендә, фестивальләрдә катнаша, саундтрек һәм альбомнар яздыра. Стилистик юнәлешләрен музыкантлар «ска-фолк рок-бардак» дип билгели һәм аңа җиңел шәһәр романсы өсти.

Берничә ел элек төркемнең үз студиясе пәйда була. Салакаев киләчәктә аны яшь музыкаль төркемнәргә ярдәм итү буенча продюсерлык үзәге итеп күрә.

16 ноябрь, 19:00, «Волга-Волга» студиясе.
Кичә социаль челтәрләрдә онлайн-режимда трансляцияләнәчәк

БАШТАГЫ ҺӘМ ИДӘНДӘГЕ ШӘҺӘР (12+)

Мөгаен, Казанда яшәүче һәркемнең шәһәр үзәгендә кадерле урыны бардыр: Черек күл паркындагы эскәмия, Бауман урамына карап торган кафе, Кремль яр буенда роллер юлы... Ләкин күз алдына китерегез, боларның барысы да юкка чыкты, ди. Сез яраткан урыннарны нәрсә белән алыштырасыз? «Моң» театр мәйданчыгында оештырылган «Децентрализация» спектакле шушы хакта. Тамашачыларга районнар буенча командаларга бүленергә һәм периферияда (ягъни идәндә ясалган Казан картасында) югалган Татарстан урамы һәм Кремль урынына яңа истәлекле урыннар булдырырга тәкъдим ителә. Киров районында космодром булырга тиеш дип уйлыйсызмы? Бик шәп! Совет районында дендрарий? Бик әйбәт! Уен вакытында Казан – сезнең кулда.

12 ноябрь, 19:00,
«Моң» театр мәйданчыгы, Казан, Пушкин ур., 86, 2 кат

ИЛ ПОРТРЕТЫ – БУЯУЛАРДА (6+)

«Мин ул вакытта портрет яздым кебек, әмма аерым бер субъектны түгел, ә гомуми дөнья портретын – барысын да бер кыяфәттә. Бит-йөз түгел, тулаем кыяфәт, өстәвенә, куркыныч дәрәҗәдәге таныш булганны...», – диде әңгәмәләренең берсендә Россиянең атаклы рәссам-нонконформисты Олег Целков. Әлеге «битлексез кешелек» йөзе 1960 елда барлыкка килгән. Казан Кремле территориясендәге Манеж бинасында оештырылган күргәзмә совет сынлы сәнгате гөрләп торган чорга туры килгән алдагы 20 ел – «җепшеклек»тән «үзгәртеп коруларга» кадәрге вакытны үз эченә ала. Төрле авторларның 50 ләп эше кергән экспозиция рәсми һәм рәсми булмаган сәнгатьнең бергә яшәвен һәм каршылыгын чагылдыра. Бу контраст әлеге 20 еллыкның атмосферасын кемгәдер – беренче мәртәбә, ә кемгәдер яңадан яисә башкача тоярга мөмкинлек бирә.

2023 елның 26 февраленә кадәр,
«Манеж» күргәзмә залы,
Казан, Казан Кремле

АКЛЫ-КАРАЛЫ ЭТЮД (18+)

«Профессионаллар... бөтен басуны түгел, ә аларга кызык булганны гына төшерә. Мизгелне көтә. Бу иң мөһиме – шул мизгелне көтеп җиткерү, ул җитсен өчен тиешле вакытта тиешле урында булу. Күп тә кирәкми. Бер тапкыр гына эләгергә кирәк», – дип аңлата үзенең эш ысулын совет һәм Россия фотографы һәм фотожурналисты Владимир Лагранж. Аның Заманча сәнгать галереясында оештырылган фотосурәтләре күргәзмәсе 1960–1990 нчы еллардагы совет урамнарына һәм шул урамнардан атлаган кешеләргә багышлана.

«Лагранж урамнары» күргәзмәсе,
2022 елның 27 ноябренә кадәр,
Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музееның «Хәзинә» Милли сәнгать галереясы,
Казан, Казан Кремле

ШТИРЛИЦ, ӘЙ СЕЗНЕҢ КАЛУЫГЫЗНЫ ҮТЕНӘМ!

«Китап-club» ресторанында гадәти булмаган китапның гадәти булмаган тәкъдир итү кичәсе үтте. Татарстан китап нәшриятында разведчик Сәмра Бикмиева турында роман басылып чыкты. Кыю кыз 1940 нчы елларда Эчке эшләр халык комиссариатының (НКВД) тышкы разведкасында хезмәт итә һәм хәтта Европа илләре президентларының сәяси тормышы уртасында кайный.

Без барыбыз да балачакта разведчик, шпион һәм башка яшерен агентлар турында китаплар укырга һәм фильмнар карарга яраттык. Совет балаларының яраткан геройлары арасында чын разведчиклар да, уйлап чыгарылганнары да бар иде: Рихард Зорге, Грэм Грин, Иоганн Вайс, Розенберглар гаиләсе, Штирлиц, һәм хәтта агент-007 Джеймс Бонд та... Әмма янәшәбездә генә, Казанда, чын каһарман да яши икән бит ләбаса – СССР Эчке эшләр халык комиссариаты тышкы разведкасы яшерен агенты Сәмра Бикмиева ул. Агентурадагы кушаматы – «Красивая».

СЕРНЕ БЕРЕНЧЕ АЧУЧЫ

– Беренче булып әлеге «агент»ның серен Сәмра Сабир кызын 100 яшьлеге белән котларга килгән Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов ачты. Ул аның яшьлек хатирәләрен бик бирелеп тыңлады һәм менә шундый хатын-кызлар турында китаплар язарга кирәклеген искәртте, – дип сөйли «Красивая» романы авторы Татьяна Вафина. – Булачак китап өчен материалны Бикмиевлар гаиләсендәге тагын бер разведчик – Сәмра ханымның бертуганының кызы, отставкадагы полиция майоры Гөлсинә Галләмова да өстәде. Ул әле үсмер чагында ук, шул вакытта үзе бик мавыккан Шерлок Холмсның дедуктив методы ярдәмендә, апасының нинди дер яшерен серләре булуын исәпләп чыгара һәм шуларны ачу өчен юридик академиягә укырга керә.

РАЗВЕДЧИКЛАР ГАИЛӘСЕ

– Баштарак мине аның Ульяновск, Ижевск шифаханәләренә «барулары» сагайтты. Аннан ул безгә гел кыйбатлы һәм совет иленә хас булмаган бүләкләр алып кайтты. Гомере буе Казан госпиталендә гади шәфкать туташы булып эшләүче өчен бу гайре табигый иде. Үзенә дә модалы, матур, безнең кибетләрдә сатылмый торган кием-салым алып кайта, – дип сөйли Гөлсинә Рәүф кызы. – Үсә төшкәч, мин аның хезмәт кенәгәсендәге кайбер сәерлекләргә игътибар иттем. Нәкъ менә шифаханәләрдә «дәваланган» чагында аны эшеннән азат итәләр икән бит... Әмма хезмәт кенәгәсенә эштән чыгару турында боерык карандаш белән генә языла. Аннары ул кире үз госпиталенә әйләнеп кайта һәм киләсе «сәфәр»енә кадәр берни булмагандай рәхәтләнеп эшли. Һәм шундый сәерлекләр әледән-әле күп сораулар тудырса да, апа чакма ташыдай нык булды һәм 100 яше тулганчы үзенең яшерен тормышы турында авызын да ачмады. Бары тик бер гасыр чиген узып киткәч кенә, сер пәрдәсе бераз күтәрелде. Минем шикләнүләрем тулысынча акланды – ул чын разведчик булып чыкты!

КИТАП ГЕРОЕНЫҢ АВТОГРАФ-СЕССИЯСЕ

Китапны тәкъдир итү кичәсенә романның 101 яшьлек герое үзе дә килде! Автограф-сессия вакытында Сәмра Сабир кызы кунаклар сатып алган бөтен китапларга да култамгасын куеп бирде. Бу вакытта аның «коллегасы Штирлиц» турындагы фильмнан һәркемгә таныш үзәк өзгеч музыка яңгырап торды. Экранда исә һәр яңа легенда саен үзе җибәрелгән илгә туры китереп исемен үзгәрткән Красивая агентының «яшерен тормышы» сәхифәләре бер-берсен алыштырды...

Фото: Алсу Шакирова

Беренче булып әлеге «агент»ның серен Сәмра Сабир кызын 100 яшьлеге белән котларга килгән Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов ачты.

Кайсы илгә җибәрелүенә бәйле рәвештә, разведчик кыз өчен яңа легенда уйлап табыла, исеме дә үзгәрә: Самира, Сәмра, Светлана, Сонечка, Милена, Элишка...

Истәлеккә фото: китап авторы роман герое белән бергә.

Китапны тәкъдир итү кичәсенә романның 101 яшьлек герое үзе дә килде!

«Красивая» романы героеның автограф-сессиясе.

ТАТМЕДИА

shop.tatmedia.ru

ТАТМЕДИА ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРЫ ҺӘМ ОТКРЫТКАЛАРЫ — МАРКЕТПЛЕЙСЛАРДА

WILDBERRIES

KazanExpress

OZON

Я Маркет

«ТАТМЕДИА» АҖ. Адрес: 420066 Казан ш., Декабристлар ур., 2. ГРН 1071690057834

16+ Реклама